Шаһинур МОСТАФИН



# ХӘТЕР ЯКТЫСЫ

*(Документаль-публицистик язмалар)*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)—4
М 67

**Мостафин Шаһинур**

М 67 Хәтер яктысы: Документаль-публицистик язмалар.– Казан: Татар.кит.нәшр., 2004.– 191 б.

Китапка танылган әзтабар язучы Ш.Мостафинның дәһшәтле сугыш өермәләре аша үткән билгесез каһарманнарга яисә аз билгеле батырларга багышланган документаль язмалары туплап бирелде.

ISBN 5-298-01406-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

# БАТЫРЛАРНЫ БАРЛАР ЧАК!..

*(Кереш сүз урынына)*

...Инде менә ничәнче тәүлек йокысызлыктан җәфа чигәм. Бүген дә шулай. Аптырагач, торып, кунакханәдә үзем тукталган бүлмәнең тәрәзә капкачларын киереп ачып җибәрдем. Сызылып май таңы атып килә. Йөзне, тәнне иртәнге саф-җылы җил иркәли. Ә тәрәзәм каршындагы зур бакчада – Россия Саклану (Оборона) министрлыгының Үзәк архивы урнашкан изге урында үзәкләрне өзеп-өзеп сандугачлар сайрый...

Сандугачлар... Әллә алар да, минем кебек, йокысызлыктан җәфа чигәләрме? Әллә җырчы кошлар, Бөек Ватан сугышы чорында һәлак булганнарның якты истәлекләрен, олы рухларын биниһая кадерләп, аларга үзләренең кабатланмас сихри моңнарын багышлап, мәңгелек сакка басканнармы? Әллә сандугачлар яу кырыннан кайтмый калганнарның җаннарымы? Җырлары исә исәннәргә, безнең буынга әйтер сүзләреме, өн-авазларымы? Әллә безне – каһарман якташларыбыз эзләреннән меңнәрчә чакрым юллар үтеп, бирегә – Мәскәү өлкәсенең Подольск шәһәрендәге Үзәк архивка – баш күтәрми эшләргә килүчеләрне хуплап, шулай үзләренчә сәламлиләрме?..

Һай, телләрен-уйларын белсәң иде шул җырчы кошларның... Ә инде йокысызлыктан интегүемә килсәк, аның сәбәбе бер – архивта эзләнүләргә багышланган киеренке һәр көн нинди дә булса тетрәндерерлек хәлләр, сискәндерерлек фактлар белән очраштыра, шул чор вакыйгалары эченә өермәдәй-ташкындай бөтереп алып кереп китә, йокы-ялны, ашау-эчүне, бар дөньяны оныттыра... Әйе, дары исе сеңгән, чит-читләрен ялкын өткән, канга манчылган ул документлар җанга һич тә тынгылык бирмиләр. Күпме каһарманнар, үзләренә «икенче гомер» бүләк иткәнне көтеп, архив киштәләрендәге калын томнар аша сүзсез генә безгә карап торалар. Әрнү дә, өмет тә чагыла кебек аларның карашларында... Шушы архивта саклanучы, тарихи дөреслекне раслаучы дистә миллионнарча томнарга кергән гаять мөһим, бәһа биреп бетергесез кадерле ул документларның зур күпчелегенә әле эзләнүчеләрнең-тикшеренүчеләрнең

куллары бөтенләй кагылмаган. Әнә шул «айсберг-боз»ны аз гына булса да «эретү» – билгесез батырларны барлауда тыйнак кына үз өлешемне кертү нияте белән чираттагы ялым вакытында һәр елны диярлек киләм мин бу архивка. Ашкынып-дулкынланып киләм...

Архив... Иң элек шул искиткеч серле, тылсымлы, хикмәтле «мәгарә»гә беренчеләрдән булып юл күрсәткән остазларыбызга-рухташларыбызга карата ихлас рәхмәт сүзләребезне әйтеп, тирән хөрмәтебезне белдереп үтик әле. Менә алар: инде вафат булган өлкән каләмдәшләребездән – үтә дә нечкә күңелле, тынгысыз җанлы Гази Кашшаф, Самат Шакир, Зәки Әхмәтҗанов, Фәргать Нуруллин, Әмир Ганиев, галимнәрдән Җәмил Гыйльманов, Альберт Айнетдинов, исәннәрдән – бөтен гомерен шушы гаять кирәкле эшкә багышлап, Хәтер сагында уяу торучы Шамил Рәкыйпов, Рафаэль Мостафин, Мәрди Рафиков, Дамир Шәрәфетдинов Шәриф Байгильдин, Имам Хәсәнов, Чәчкә Заһирова, Әгъзам Җәләлиев, Нургали Булатов, Мәгъсүм Гәрәев, Эльмира Әдиятуллина, Дамир Гарифуллин... Бу шәхесләрнең һәркайсы турында озаклап, олылап сөйләргә була. Зур хәрефле әлеге Эзтабарлар безнең кебек сугыштан соң туган буын вәкилләренә дә «архив вирусы»н гомерлеккә «йоктырдылар». Арабыздан бик яшьләй киткән талантлы каләмдәшләребездән Газиз Кашапов-Үзиле, ялкын йөрәкле публицист – тарих фәннәре кандидаты Сәмигулла Хәйретдинов, милләтпәрвәр журналист-мөхәррир Мәхтүм Мостафин, исәннәрдән – әдибә Сәйдә Зыятдинова, каһарманнарыбызны эзләүдә һәм күп томлы «Хәтер Китабы»н чыгаруда аеруча нәтиҗәле эшләүче Анатолий Иванов, Михаил Черепанов, фидакарь эзтабарлардан Әхәт Садриев, Рәшит Миннегалиев, Гомәр Хаҗиев, Рифат Җәләлиев, Гомәр Мөбәрәкшин, Камил Арифуллов, Рашат Низамиев, Ирек Бәдертдинов, Рафис Могыйнов һ.б. бик күпләр Бөек Ватан сугышы елъязмасын тулыландыруда үзләреннән биниһая зур өлеш керттеләр. Алар, архивларда казынып, сугыш булган урыннарны аркылыга-буйга иңләп, шул дәһшәтле чорның тетрәндергеч сәхифәләрен ачтылар, моңарчы билгесез булган батырларны эзләп таптылар. Батырлар дигәннән, алар арасында Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгәннәр һәм ахыр чиктә әлеге олуг исемгә лаек булганнар аерым урын биләп тора...

Советлар Союзы Герое дигән иң югары дәрәҗәле исем СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1934 ел 16 апрель Карары нигезендә булдырыла. Шул ук елның 20 апрелендә бу мәртәбәле исем иң беренче итеп А.В.Ляпидевский, С.А.Леваневский, В.С.Молоков, Н.П.Ка-

манин, М.Т.Слепнев, М.В.Водопьянов, И.В.Доронин кебек аеруча тәвәккәл-батыр очучыларга бирелә. Тарихи язмалардан укып белгәнебезчә, 1934 елның 16 февралендә Чукот диңгезендә, бозлар арасына кысылып, «Челюскин» пароходы бата. Күренекле профессор О.Ю.Шмидт җитәкчелегендәге арктик экспедиция әгъзалары (экипаж белән бергә барлыгы 111 кеше) хәрәкәтләнүче боз өстендә, үтә дә кырыс поляр кыш хакимлегендә калалар. Челюскинчыларны эзләп табу һәм коткару эшенә исемнәре югарыда әйтеп үтелгән очучылар үзләре теләп алыналар... Ниһаять, 5 апрельдә А.В.Ляпидевский дрейфтагыларны табу бәхетенә ирешә һәм очкычы белән боз өстенә «кунаклап», беренче рейста ук унике кешене материкка исән-сау алып кайта. Аның фидакарьлеге башка очучыларны да канатландыра. 13 апрельдә инде челюскинчыларның барысын да коткаралар (алар арасында ике бала һәм җиде хатын-кыз да була)...

1934 елдан алып Бөек Ватан сугышы башланганчыга кадәрге чорда барлыгы 626 кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Араларында Татарстан Республикасында туып үскән төрле милләт вәкилләре, шул исәптән 9 татар да бар. (Кара: «Герои Советского Союза», М., «Воениздат», 1984, 28 бит.) Хәзер кайбер якташларыбыз белән якыннанрак танышып үтик әле.

Чирмешән районында туып үскән мордва егете *Павел Алексеевич Цаплинны* (1906–1937) тирән ихтирам хисләре белән иң беренче итеп телгә аласы килә.

...1936 елның 16 июлендә Испаниядә монархистик фашистлар фетнәсе башлана. Генерал Франко гаскәрләренә ярдәмгә итальян һәм немец фашистлары ашыга. Алар Испаниягә бихисап корал, хәрби кирәк-яраклар һәм тулы хәзерлектәге хәрби частьларын җибәрәләр.

Моңа җавап итеп бөтен дөньяда Испания патриотларына карата теләктәшлек хисе үсә бара. Әлеге республиканы саклау, кара көчләргә каршы тору өчен күп кенә илләрдән ирекleләр отрядлары килә. Совет ирекleләреннән дә 2065 кеше туплана, шуларның 351 е танкист була.

Капитан Цаплин, 1936 елгы Октябрь парадында (7 ноябрь) катнашканнан соң, Кызыл мәйданнан ук, үз теләге белән, Испаниягә китә. 20 ноябрьдән инде ул, танк ротасы командиры сыйфатында, Мадридны саклаучылар белән бергә, фетнәчеләргә каршы сугыша. Шул чорда яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен, кыю офицер СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1937 ел 2 гыйнварындагы Карары нигезендә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

1937 елның 13 февралендә франкочы гаскәрләрнең һөҗүмнәре туктатыла. Республикачылар үзләре контрһөҗүмгә күчә. Капитан Цаплинның танклары, тимер ташкын булып, дошман өстенә ыргыла. Җиңү арты җиңү яулаган мизгелләрнең берсендә, көтмәгәндә генә, рота командирының куәтле корыч машинасына снаряд килеп тия. Цаплин авыр яралана, әмма рота белән җитәкчелек итүне дәвам иттерә. Аның экипажы соңгы снаряд, соңгы патрон беткәнче сугыша. Аннары капитан танкны, дошман кулына калдырмас өчен, үзе шартлата һәм частена әйләнеп кайта... Ләкин яралары аңа озак яшәргә мөмкинлек бирми. Берничә көннән П.А.Цаплинның җәсәден, хәрбиләрчә зур хөрмәт күрсәтеп, Испаниянең Арчен шәһәре каберлегенә җирлиләр...

Интернациональ бурычны үтәгәндә күрсәткән зур каһарманлыгы өчен, СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1937 ел 27 июнь Карары нигезендә Мордва Афонькасы авылы егете Павел Алексеевич Цаплинга Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелә. Республикабызда иң беренче булып!..

Сүз уңаенда шунысын да әйтик: Татарстаннан читтә яшәгән милләттәшләребез дә сынатмый. Нәсел тамырлары белән республикабызның Биектау төбәгендәге Ямаширмә авылыннан булган, Донбасста туган *Гыйльфан Әбүбәкер улы Батыршинны* (1914–1947) гына алыйк. Ул 1938 елның җәендә, Приморье краеның Хасан күле янында, япон самурайларына каршы көрәштә үзенең исемен мәңгелек данга күмә.

...29 июльдә Япониянең Квантун армиясе гаскәриләре, чикне бозып, Заозерная һәм Безымянная биеклекләре районында безнең заставаларга һөҗүм итәләр. Башка сугышчан иптәшләре кебек, чик сакчысы Г.Батыршин да үзенең отделениесе белән самурайларга каршы батырларча көрәшә. Ахырдан ул авыр яраланган сигез сугышчыны һәм застава начальнигын дошман кулына төшүдән коткарып кала – аларның һәркайсын, берәм-берәм үз аркасына салып, күлнең икенче ягына чыгарып куя. Яшьлегендә оста йөзүче булуы, җитезлеге-тапкырлыгы әнә шул чакта бик тә ярдәм итә аңа. Японнар өзлексез ут яудырып торуга карамастан, яраланмый да... Халык бик белеп әйтә шул: батырдан пуля да курка!..

13 көн буе дәвам иткән сугышлар барышында японнар үзләренең бик күп солдатларын, офицерларын югалталар һәм 1938 елның 11 августында СССР белән вакытлы килешү төзергә мәҗбүр булалар.

Чик сакчыларыннан аеруча зур батырлык күрсәткән 22 кешегә, шул исәптән Гыйльфан Әбүбәкер улы Батыршинга, аның якын дусты

*Иван Давидович Чернопяткога* һәм алар хезмәт иткән застава начальнигы *Петр Федорович Терешкинга* СССР Югары Советы Президиумының 1938 ел 25 октябрь Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән мәртәбәле исем бирелә. Шул ук Указ белән әлеге мактаулы исемгә тагын бер милләттәшебез – Саратов өлкәсендә туып үскән пулеметчы егет *Кәрим Мусяк улы Яһудин* дә лаек була. Ул бер бәрелештә дошманның 60 лап солдатын һәм офицерын сафтан чыгара...

1939 елның 30 ноябрендә башланып 1940 елның 12 мартында тәгәлләнгән совет-фин сугышы вакытында да якташларыбыз сынатмыйлар. Шулар арасыннан төрле дәрәҗәдәге иң гаярь хәрбиләр – Казан шәһәреннән *М.В.Дмитриев, М.П.Кирпонос, А.М.Коняев, Д.Б.Строганов, А.А.Чупуренко,* Алабугадан *С.П.Спирьков,* Балтачтан *Х.И.Ибраһимов, Б.С.Рәхимов, Х.С.Сабиров,* Баулыдан *И. Д.Зиновьев,* Мамадыштан *Г.Я.Нигъмәтуллин,* Минзәләдән *Г.В.Вәзетдинов, Б.А.Винокуров,* Теләчедән *А.К.Ксенофонтов* Советлар Союзы Герое исеменә лаек булалар. Тугандаш Башкортстан Республикасында һәм Саратов өлкәсендә туып үскән милләттәшләребездән *С.Н.Майский* белән *И.М.Кудашев* та Алтын Йолдыз кавалерлары булалар...

1941–1945 елларда немец-фашист илбасарларына каршы 1418 көн дәвам иткән Бөек Ватан сугышы һәм Ерак Көнчыгышта Япониянең кораллы көчләрен, Квантун армиясен тар-мар итү өчен барган көрәш (1945 елның 9 августы – 2 сентябре) безнең ил өчен аеруча җитди сынау чоры була. Дошманны җиңү хакына күпмилләтле бердәм халкыбыз ким дигәндә 27 миллион кешесен корбан итә...

Дөресен генә әйткәндә, бу өлкәдә серлелек пәрдәсе тулысынча ачылмаган әле. И.В.Сталин 1946 елда, мәсәлән, «Правда» газетасы хәбәрчесенә биргән интервьюсында: «...немецлар белән сугыш вакытында, оккупация чорында һәм немец каторгасында Советлар Союзы үзенең җиде миллион кешесен югалтты»,– дип белдерә... Н.С.Хрущев исә 1961 елда Швеция премьер-министры Т.Эрландерга җибәргән хатында Бөек Ватан сугышы чорында һәлак булучыларның санын егерме миллион итеп күрсәтә... 1990 елда – М.С.Горбачев җитәкчелек иткән чорда – бу сан егерме җиде миллионга җитте...

Чит ил тикшеренүчеләренең әлеге мәсьәләгә карата үз карашлары бар. Американы социолог Н.Тимашевның 1948 елда ук игълан ителгән белдерүеннән күренгәнчә, СССР әлеге сугыш вакытында утыз җиде миллион ярым кешесен югалткан булып чыга. (Кара: «Родина» журналы, 1991 ел, 6–7 кушма сан, 139 бит.) Ә инде Мәс-

кәүгә килеп, бу мәсьәләне утыз ел буе өйрәнгән Англия галиме Ж.Эриксон: «...Икенче бөтендөнья сугышы Советлар Берлегенең кырык тугыз миллион кешесен алып китте»,– дип белдерә. Газиз ватаннарыннан куганда үтерелгән һәм төрмәләрдә, ГУЛАГ зинданнарында миллионлап кырылганнар саны бу исәпкә керми...

Биредә тагын: «Икенче бөтендөнья сугышында күпме татар һәлак булган?» – дигән урынлы-мөһим сорау да туарга мөмкин.

Заманында фашистлар «тырнагы»на эләгеп, әсирлекнең бөтен газапларын татыган һәм соңыннан, концлагерьдан качып, үзебезнекеләргә килеп кушылган туры-гадел сүзле солдат-әдип-рәссам Нәби ага Дәүли (1910 – 1989) бу хакта болай ди:

– Өч татарның икесе үлде. Ул чакта татар дүрт миллион ярым исәпләнә иде, кимендә ике миллион татар кырылды...

Шул уңайдан «Мәдәни җомга» газетасы үз фикерен әйтә:

– Ләкин Нәби ага ялгыша кебек,– ди ул.– Сугышка кадәр татар кимендә ун миллион булган, дигән фикер көннән-көн ныгый бара. Һәр татар авылы уртасындагы дүрт кырлы ташка уелган дүртәр-бишәр йөз кеше исемлегеннән чамалап, Урал, Себер, Урта Азия, Кырым, Татарстан, Россиядән китеп һәлак булганнарның саны биш миллионлап булырга мөмкин. Ягъни татар ирләренең җитмеш-сиксән проценты һәлак булган дигән сүз бу...

Әйе, сугышта үлгәннәрнең саны һаман да төгәл билгеле түгел әле. Ул каһарманнарның байтагы, үзләренең җәсәдләрен җир куенына иңдергәнне көтеп, дистәләрчә еллар дәвамында һаман ачык һавада, җил-яңгыр, кар-буран астында ята бирә. Шул уңайдан «Аргументы и факты» газетасы 2002 елда чыккан 18–19 нчы санында 12 биттә «ПОЧЕМУ НЕ ИЩЕМ ОСТАНКИ?..» дигән үтә гыйбрәтле мәкалә бастырды. Шул язманы биредә бернинди кыскартуларсыз китереп үтәсебез килә:

*«Почему до сих пор тысячи останков солдат времен Великой Отечественной не захоронены? Уверен, основная причина – экономическая. Сразу после освобождения территорий страны от немецкой оккупации в санитарных целях местных жителей организовывали производить массовые захоронения погибших бойцов. После каждого очищенного поля множество сумок и ведер наполнялись медальонами, личными вещами солдат, документами. Все это отправляли в военкоматы. Мы наивно полагали, что стоит нам найти списки фамилий, составленных по медальонам, мы сможем установить имена тех, кто по сей день считается пропавшим без вести.*

*Увы, ни в одном архиве вы не найдете этих списков. По свидетельству нескольких ветеранов – бывших военкомов – медальоны в то время скрытно уничтожались. Зачем? Семья погибшего на фронте получала ежемесячное пособие плюс дополнительные льготы. Семья же пропавшего без вести лишалась и того, и другого. В конце войны таковых было от 5 до 9 миллионов. То есть экономия на пособиях составляла минимум 300 млн. рублей в год. К 40-летию Победы государство не потратило «впустую» уже 13 миллиардов рублей. Скорее всего, именно поэтому ни Сталину, ни последующим руководителям Советского Союза было невыгодно признавать и публиковать истинную цифру потерь.*

Ю.СМИРНОВ,
*председатель правления*
*союза «Поисковых отрядов».*

Тирәнтен уйландыра, авыр уйларга чумдыра торган фаҗига бу. Ә бит мәшһүр генералиссимус А.В.Суворов: «Яу кырында үлгәннәрнең соңгысы күмелмичә торып, сугышны беткән дип санарга ярамый»,– дигән үтә хикмәтле сүзләр әйтеп калдырган. Димәк, сугыш әле һаман да дәвам итә!..

«Аргументы и факты» газетасының язуына караганда (№18 (1175), апрель, 2003), ветераннарга тиешле 464 мең сугышчан бүләк әле хәзер дә үзләренең ияләрен көтеп ята...

Әйе, безгә батырларыбызны барларга, санларга, данларга бик тә вакыт!..

Шулай да... Сугышта һәлак булганнарга багышлап, күп төбәкләрдә «Хәтер китаплары» чыгарылу, партизаннар хәрәкәтендә, дошманга каршы яшерен оешмалар эшчәнлегендә катнашучылар, шулай ук әсирлектә булган, коллыкка куылган кешеләр турында яңа мәгълүматлар табылу, мәңге кереп булмастай тоелган серле архив ишекләренең ачылуы күңелләрдә якты өметләр уята. Һәлак булганнар һәм чын батырлар турында Галиҗәнап Вакыт үз сүзен өздереп әйтәчәк әле...

* * *

Бөек Ватан сугышы елларында яу кырында, дошман тылында, диңгездә һәм күктә тиңдәшсез фидакарьлек үрнәкләре күрсәткән 11.633 кешегә Советлар Союзы Герое дигән олы исем бирелә. Ал-

тын Йолдызга ия булучылар арасында Татарстан уллары һәм кызлары да йөзәрләп санала.

Аларның тиңдәшсез, какшамас рухи ныклыгын, кыюлыгын-чыдамлыгын, Ватанга чиксез бирелгәнлеген күренекле хәрби эшлеклеләр дә югары бәяләделәр. Шулар арасыннан берничәсенең фикерләре белән танышып китик:

*Советлар Союзы Маршалы И.С.КОНЕВ: «...Татарстанда туган егетләр... арысланнар кебек сугышалар».*

*Советлар Союзы Маршалы Р.Я.МАЛИНОВСКИЙ: «...Мин, карт солдат буларак, сугыш кырларында татар сугышчыларын һәм офицерларын күп күрдем. Һәм аларның сугышта какшамас ныклык күрсәтүләренә һәм корыч ихтыярларына һәрвакыт сокланып киләм. Советлар Союзының бәйсезлеге өчен алып барыла торган бөек көрәштә татар халкы үзенең сугыш эшендә чыдам һәм батыр йөрәкле солдатлары белән бөтен армиябез каршында хөрмәт казанды».*

*Советлар Союзы Маршалы Л.А.ГОВОРОВ: «...Татар солдатларының сугышчан әзерлекләре иң югары бәягә лаеклы... Алар сугыш кырларында татар халкының иң яхшы сыйфатларын – Ватанга чиксез бирелгәнлек, дошманга аяусыз нәфрәт, җиңү бәрабәренә үлемнән курыкмау, батырлык, кыюлык, чыдамлык һәм теләсә нинди шартларга да түзү сыйфатларын гәүдәләндерәләр. Татар сугышчылары Совет Ватаны алдындагы хәрби бурычларын намус белән үтиләр...»*

Һәм менә шушындый сүзләрдән соң, биредә каршы якның фикерләрен турыдан-туры гәүдәләндерүче гап-гади немец ефрейторы Рудольф Вольтангның үзенең якыннарына язган хатыннан бары тик ике генә җөмлә китереп үтәсебез килә: «Монда безгә каршы бик күп татарлар сугыша. Мин хәтта төшемдә дә татар белән очрашмаска теләр идем...» («Батырлар китабы», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1945 ел, 13, 21, 22, 26 битләр.)

Инде белгәнебезчә, татар каһарманнары сугышның иң хәтәр урыннарында булганнар. 1948 елда «Известия» газетасының 16 гыйнвар санында басылган бер мәкаләдән күренгәнчә, немец танкларының һәм самолетларының иң зур күпчелеген милләттәшләребез юк иткән... Сугышның иң хәлиткеч операцияләрендә дә татар хәрби командирлары күпләп катнашкан һәм немец генералларының да байтагын безнең милләттәшләр әсир иткән.

Монда шулай ук әсирлеккә эләккән совет сугышчыларының бары тик 2 проценты чамасы гына татарлар икәнлеге дә искәртелә...

Россия Саклану министрлыгының Үзәк архивына чираттагы ба-

руымда мин әлеге саннар белән тагын да җентекләбрәк кызыксындым. Һәр кешегә-эзләнүчегә карата искиткеч ихтирамлы һәм игътибарлы архив хезмәткәрләре кулыбызга «Гриф секретности снят» дигән саллы гына китап китереп тоттырдылар. 1993 елда Мәскәүдә, «Воениздат» нәшриятында генерал-полковник, хәрби фәннәр кандидаты Г.Ф.Кривошеев җитәкчелегендә чыккан әлеге китапта СССР Кораллы Көчләренең сугыш елларындагы югалтулары турында тәфсилләп сөйләнелә. Гаҗәп, әммә факт: сугышның һәр тәүлегендә уртача 20.869 кешенең гомере өзелгән...

Таблицалардагы мәгълүматлардан күренгәнчә, чыннан да, әсирлеккә эләккән татарларның саны нибары 2,2 процент булган икән (340 бит). Әсир булган башка милләт вәкилләре турында да уйландырырлык саннар бар анда. (Әйтик, руслар – 48 процент, украиннар – 28,2, белоруслар – 7,5 процент...)

Шушы фактлар үзләре үк безнең милләттәшләребезнең яу кырында, чыннан да, «арысланнар кебек сугышуларын» ышандырырлык итеп раслыйлар. Әсирлеккә дә алар үз теләкләре белән төшмәгәннәр. «Тәмуг оясы»нда да сынатмаганнар. Әйтик, Советлар Союзы Геройларыннан Моабит төрмәсе тоткыны – легендар шагыйрь Муса Җәлил, Брест крепосте каһарманы Петр Гаврилов (керәшен татары), Ровно өлкәсе партизаннар берләшмәсенең шартлату төркеме командиры Николай Орлов (чын исеме – Гатаулла Минаев) иң авыр чакларда да коелып-югалып калмаулары белән бик күпләрне сокландырганнар. Аларның һәркайсы әсирлек газапларын татыган, әмма рухлары белән искиткеч көчле шәхесләр булып калганнар!

Әлеге каһарманнар – чын мәгънәсендә халкыбызның зур горурлыгы, рухи ныклыгы-мактанычы. Еллар үткән саен, шундый батырларның фидакарьлеге белән кызыксыну үсә-көчәя бара...

Сугыш елларында ук инде республикабызның танылган язучылары, журналистлары һәм галимнәре батырлар турында материаллар туплый башлыйлар, алар турында «Кызыл Татарстан», «Красная Татария» газеталарында, «Совет әдәбияты» журналында әдәби-публицистик язмалар бастыралар. Татарстан китап нәшриятында аерым җыентыклар булып та чыга ул әсәрләр. Төрле фронтларда татар телендә нәшер ителүче газеталарның хәрби хәбәрчеләре дә бу өлкәдә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр – каһарманнарыбыз турында йөзләгән очерк-зарисовкалар иҗат итәләр...

Соңыннан, шуларга нигезләнеп, сугыштан соң – 1945–1946

елларда – татар һәм рус телләрендә беренче тапкыр «Батырлар Китабы» («Книга Героев») дөнья күрә. Аны чыгаруда күренекле язучы Кави Нәҗми башлап йөри, төзүче-мөхәррире дә, кереш сүз авторы да үзе була. Алсу тышлыгына Алтын Йолдыз медале, лавр яфраклары, милли бизәкләр төшерелгән, батырларның рәсемнәре урнаштырылган һәм чорына күрә яхшы итеп бизәлгән әлеге китап (рәссамы – Байназар Альменов) 10 мең данәдә басыла. 224 битле I томга 56 Герой турында очерклар тупланып бирелә. Аларның авторлары арасында без Габдрахман Әпсәләмов, Гариф Галиев, Габдулла Гомәрев, Мәрьям Дибаева, Әхмәт Ерикәй, Бруно Зернит, Риза Ишморат, Газиз Иделле, Гази Кашшаф, Мәхмүт Максуд, Шәрәф Мөдәррис, Гамир Насрый, Мөхәммәт Садри, Гали Хуҗиев, Мәхмүт Хөсәен, Әхмәт Юныс кебек күренекле өлкән каләмдәшләребезне күрәбез.

«Батырлар Китабы»ның тагын да күләмлерәк II томы да хәзерләнгән була. Ләкин ул билгесез сәбәпләр аркасында үз укучысы кулына барып ирешми...

Әмма батырлар турындагы чын хакыйкать, кар астындагы кайнар чишмә кебек, барыбер үз юлын таба. 1963 елда Татарстан китап нәшриятында тарихчы эзтабар Л.И.Ханинның рус телендә «Герои Советского Союза – сыны Татарии» дигән калын гына китабы басылып чыга. 167 Герой турындагы очерк-зарисовкаларын туплап бирә ул биредә. 1966 елда әлеге китапның татарча басмасы да дөнья күрә – бу юлы инде каһарманнарның санын 171 кешегә җиткерә Леонид Иванович...

1982, 1984 һәм 1985 елларда Татарстан китап нәшрияты батыр якташларыбыздан 211 кеше турында рус телендә «Герои Советского Союза – наши земляки» дигән өч томлыкны укучылар игътибарына тәкъдим итә. 1990 елда исә әлеге томнар татар теленә тәрҗемә ителеп, «Советлар Союзы Геройлары – якташларыбыз» дигән исем астында 680 битле саллы гына китап булып басылып чыга. Аңа, 211 каһарман турындагы очерк-зарисовкалардан тыш, Татарстаннан читтә яшәүче батыр милләттәшләребездән 91 кеше турында кыскача мәгълүматлар кертелә, фотосурәтләре урнаштырыла. Бу өлкәдә тарих фәннәре кандидатлары Җ.И.Гыйльманов, А.К.Айнетдинов, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррир урынбасары Н.К.Габитов, эзтабар язучы Ш.Җ.Рәкыйпов, отставкадагы полковник С.Ә.Таһиров, СССР Саклану министрлыгы Үзәк архивы начальнигы урынбасары, полковник якташыбыз Ә.Х.Фәйзуллин үзләреннән аеруча зур өлеш кертәләр...

Бөек Җиңүнең 55 еллыгын лаеклы төстә каршылау һәм билгеләп үтү турында Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевның 1999 ел 11 май Указы һәм ТР Министрлар Кабинетының 1999 ел 20 август Карары батырларыбызны барлау юнәлешендә тагын бер әһәмиятле адым ясарга рухландырды. Татарстан китап нәшрияты, Республикабызның Язучылар оешмасы, Баш Архив идарәсе, «Татар энциклопедиясе» институты, Тарих институты, «Хәтер Китабы» нәшрияты, хәрби комиссариатлар, ветераннар советлары белән берлектә, «Батырлар Китабы»ның энциклопедик характердагы яңа басмасын хәзерләү эшенә ныклап тотынды. Төрле чыганаклардан эзләнә торгач, Советлар Союзы Геройларыннан барлыгы 378 кеше турында искиткеч кызыклы, бай мәгълүматлар тупланды. Аларның зур күпчелеге Татарстанда туган яисә биредә укыган, эшләгән, яшәгән. Республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребезне дә онытмадык. Нәтиҗәдә, батырларыбыз турында беренче мәртәбә тулы мәгълүматлы шундый уникаль басманы дөньяга чыгару мөмкинлеге туды. Бу юнәлештә элек нәшер ителгән китаплардан аермалы буларак, «Батырлар Китабы»ның яңасына Алтын Йолдызлы каһарманнарыбыз турында Россия Саклану министрлыгы Үзәк архивында сакланучы Бүләкләү кәгазьләрендәге язмаларның кыскача сөземтәсе кертелде (алар  татар һәм рус телләрендә янәшә бирелде), фоторәсемнәре урнаштырылды. Батырларыбыз турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүматлар алырга теләгән кешеләр өчен һәр сәхифә ахырында шул шәхесләргә кагылышлы махсус чыганаклар да күрсәтелде.

«Батырлар Китабы»нда 1945 елның 30 апрелендә төнге сәгать унберенче яртыда – рус М.А.Егоров белән грузин М.В.Кантариядән алда! – рейхстаг түбәсенә иң беренче булып 79 нчы укчы корпус Байрагын менгезеп кадаган татар егете, өлкән сержант Гази (Газетдин) Казыйхан улы Заһитов (1921—1953) турында да сәхифә бирелә. Үзәк архивта эшләгәндә өлкән эзтабар әдибебез Шамил ага Рәкыйпов тапкан каһарманыбыз ул! Хәер, бу тынгысыз язучы, искитмәле тарихи-документаль әсәрләр тудырып, бер үзе генә дә дистәләрчә батырларыбызга икенче гомер – мәңгелек яшәү бүләк итте. Аның каһарманнары арасында Алтын Йолдызлы очучы кызларыбыз Мәгубә Хөсәен кызы Сыртланова, Ольга (Ләйлә) Александровна Санфирова, легендар партизан Иван Константинович Кабушкин, татарлардан иң беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Әбүбәкер улы Батыршин, күренекле хәрби эшлекле, генерал-полковник Василий Николаевич Гордов, Бүләкләү кәгазендәге бер хәрефнең дөрес язылмавы арка-

сында үзенең Герой икәнлеген дә белмичә үлеп киткән Хәсән Заман улы Заманов, ил күләмендә Николай Сергеевич Орлов буларак билгеле татар егете Гатаулла Мирзаһит улы Минаев һ.б. бар...

Әйе, архивтагы эзләнүләр көтелмәгән ачышлар ясарга да этәрә. Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән якташларыбыз, милләттәшләребез бермә-бер күбрәк булган икән безнең. Архивта моңарчы тикшеренүчеләрнең куллары кагылмаган үтә җитди документлар белән танышканда шундый фикергә киләсең. Әйтик, Татарстанның Әлки районы Баллыкүл авылы егете – III Украина фронтының Николаевск ныгытылган районына караган 10 нчы аерым пулемет-артиллерия полкының пулемет расчеты командиры, гвардия сержанты Хафиз Зариф улы Зарипов (1906–1944), яу кырында күрсәткән тиңдәшсез батырлыклары өчен, Советлар Союзы Герое исеменә өч мәртәбә (!) тәкъдим ителә... Ут күршебез Башкортстанның Дәүләкән районындагы Мерәс авылында туган милләттәшебез Әсгать Әхмәтханиф улы Вафин (1924–1945) белән дә шундыйрак хәл була. 5 нче армиянең 159 нчы Витебск укчы дивизиясенең 597 нче артиллерия полкында башта корректировщик (дошман өненә кереп, безнең сугышчыларның утын үзенә юнәлттерүче), аннары разведка командиры булып хезмәт иткән әлеге каһарманны Советлар Союзы Герое исеменә лаек дип табып, аңа ике мәртәбә Бүләкләү кәгазе (Наградной лист) тутыралар... Әмма аларның фидакарьлеге – ни кызганыч! – тиешенчә бәяләнми...

Шундый ук сүзләрне Аксубай районының Козловка (Дмитриевка) авылында туган өлкән сержант Филипп Николаевич Мазилинга, Арча районының Носы авылы егете – капитан Әсгать Зиннәтулла улы Зиннәтуллинга, Кукмара районының Битләнгер (Аксыбы) авылыннан китеп, Карелия җирендә батырларча һәлак булган шигъри күңелле лейтенант Нух Идрис улы Идрисовка, Мамадыш районының Урта Кирмән авылында яшәгән разведчик Мәүләви Галимҗан улы Галимовка һәм тагын дистәләрчә якташларыбызга карата да әйтергә мөмкин. Алтын Йолдыз кавалеры булырга лаеклы бу затларга, кызганычка каршы, төрле дәрәҗәдәге орденнар гына бирелгән...

Әмма батырларны туган төбәкләрендә онытмыйлар. Әйтик, Нух Идрисовка 1988 елның 16 октябрендә, тууына нәкъ 70 ел тулган көндә, үз исемен йөрткән Түбән Өскебаш урта мәктәбе (Кукмара районы) каршында мәһабәт һәйкәл (бюст) куелды. Аның янәшәсендә Татарстанның Бөек Ватан сугышы чорындагы иң яшь Советлар Союзы Герое, Җиңү парадларында катнашкан гвардия полковнигы Са-

бир Әхтәмҗан улы Әхтәмовка да шундый ук һәйкәл торгызды якташлары.

Легендар полк улы, соңыннан Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган Камил Фаяз улы Шакировны да олылады якташлары. 1990 елның 9 маенда Зур Сәрдек авылына мәгърур һәйкәл булып кайтты ул. Кукмаралылар хәтеренә мәңгелеккә кайтты...

Мамадыш районында да бу юнәлештә мактауга лаек эзлекле эш алып барыла. Бирелә район хакимияте башлыгы булып Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин эшләгән чорда (бүгенге көндә ул – Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе.– *Ш.М.)* шәһәр үзәгендә «Хәтер» паркы булдырылды. Шул паркның нәкъ урта бер җирендә «Батырлар аллеясе»нә нигез салынып, анда Татарстанда туган милләттәшләребез арасыннан иң беренче Советлар Союзы Герое Гафият Ярмөхәммәт улы Нигъмәтуллинга, шулай ук Иван Тихонович Максимов, Михаил Кириллович Москвин, Михаил Андреевич Просвирнин кебек каһарманнарыбызга да һәйкәлләр куелды. Сугышта сигез улын – сигез лачынын югалткан тыл батыры Фатыйха апа Әхмәдиевага һәм, аның кебек, балаларын яу кырында җуйган барлык милләт аналарына, олы кайгыларын уртаклашып, аларга тирән хөрмәт билгесе итеп, ап-ак таштан символик һәйкәл салынды. Каһарманнарның исемнәре алтын хәрефләр белән мәрмәр плитәләргә язылды.

Аңардан соң район хакимияте җитәкчесе булган Фарук Ислам улы Идиатуллин, аның урынбасары Шамил Нурулла улы Хәсәнов, район хәрби комиссары – полковник Николай Николаевич Егоров, Мамадыш шәһәре башлыгы Илдус Габдулла улы Әхмәтов, районның баш архитекторы Рамил Минһаҗ улы Миннеханов һ.б. да бу юнәлештә эшне уңышлы дәвам иттерделәр. Бөек Җиңүнең 55 еллыгын тантаналы төстә билгеләп үткән көннәрдә бирелә, мәсәлән, мәшһүр композиторыбыз, бөтен дөньяны гизгән «Шүрәле» балеты авторы – матурлык хакына яшәгән, иҗат иткән һәм явыз көчләргә каршы көрәштә 29 яшендә яу кырында шәһит киткән Фәрит Заһидулла улы Яруллинга да һәйкәл торгызылды. Район үзәгендә, тиздән үз исеме биреләчәк музыка мәктәбе каршысында... Саный китсәң, күп инде мондый матур эшләр!..

Инде югарыда телгә алынган һәйкәлләрнең төп авторы – күренекле скульптор Әлфәрит Хәйрулла улы Әбдерәшитов (паспортында язылганча итеп әйтсәк – Альфрет Хайруллаевич Абдрашитов.– *Ш.М.*) турында берничә сүз. Каһарманнарыбызның олпат сыннарын ул үзенең хәләл җефете Луиза ханым, уллары Альберт һәм Гадел белән

берлектә иҗат итте. Гомумән, бу гаҗәеп тынгысыз, олы җанлы скульптор, сугыш һәм хезмәт батырларына багышлап, байтак төбәкләрдә күп кенә монументаль әсәрләр – һәйкәлләр торгызды, халкыбызның бөек батырлыгын, сыннарда җанландырып, киләсе гасырларда яшәячәк яңа буын кешеләренә җиткерү өчен үз-үзен аямыйча эшләде. Һәм бу – хәзер дә шулай...

* * *

...Архив бакчасында сандугачлар сайрый. Күзгә йокы керми. Яу кырыннан кайтмый калганнарның – ЯДРӘЛӘРНЕ ЭРЕТКӘН ЙӨРӘКЛӘРнең җаннарыдыр, өн-авазларыдыр кебек тоела алар миңа... Әнә шул халәт күңелгә һич тә тынгылык бирми. Батырлар үзләрен барлаганны көтә, җыр көтә...

Ашкынып-дулкынланып тагын архивка юл тотам. Чын Тарих белән очрашырга, Үлемсезлек чиген атлаган каһарманнар белән күрешергә, Үткән белән Киләчәк арасына мәңге җимерелмәслек изге күпер салырга...

Шунысы аеруча сөендерә: бу юлы безнең белән бергә архивта эшләргә яшь эзтабарлар да бара!.. Тынгысыз эзләнүләре, зур ачышлары өчен 2003 елда Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек булган «Ватан» («Отечество») иҗтимагый яшьләр оешмасында фидакарьләрчә эшләүче кызлар, егетләр алар... Димәк, буыннар чылбыры, хәтер дисбесе өзелми. Батырлык елъязмачылары, моңарчы билгесез булган гаҗәеп сәхифәләрне ачып, каһарманнарыбызның сафларын көчле рухлы яңа шәхесләр белән тагын да тулыландыра төшәрләр әле... Моңа мин тирәнтен ышанам!..

*Автор*

# ЯДРӘЛӘРНЕ ЭРЕТКӘН ЙӨРӘКЛӘР

...Ватан-Ана ягына очкан ядрәләрне күкрәгең белән каплау өчен генә дә бу дөньяга килүең – үзе зур Бәхет!

*Леонид Леонов,*
рус язучысы

...Сугылмаган арыш көлтәседәй
Ята Тарих архив киштәсендә...

*Рашат Низамиев,*
татар шагыйре

Инде тарих китапларыннан, газета-журналлардан укып белгәнебезчә, 1943 елның 23 февралендә – Кызыл Армиянең туган көнендә – Калинин фронтында актив һөҗүм хәрәкәтләре алып баручы 22 нче армия карамагындагы 91 нче укчы бригаданың икенче аерым батальоны рядовое – 19 яшьлек комсомолец Александр Матвеевич Матросов, Калинин өлкәсенең (хәзер Псков өлкәсенә керә.– *Ш.М.*) Великие Луки районындагы Чернушки авылы өчен барган сугышта, гранаталары һәм автоматында патроннары беткәч, үлемуклары сибүче дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән каплый – үз гомере бәрабәренә йөзләгән иптәшләрен котылгысыз үлемнән коткарып кала. Хәзер шунысы да төгәл билгеле – Үлемсезлеккә адымны Александр 11 сәгать 15 минутта ясый. Заманында легендар Зоя Космодемьянскаяны (1923–1941) җәзалаган 197 нче немец пехота дивизиясе башкисәрләренә каршы көрәштә батырларча һәлак була ул... Бертуган апасын кыю яклаган гаярь егет кебек!

СССР Югары Советы Президиумының 1943 елның 19 июнендә игълан ителгән Указы нигезендә А.М.Матросовка Советлар Союзы Герое исеме бирелә, ул хезмәт иткән укчы бригада исә 56 нчы гвардияче укчы дивизия карамагындагы А.Матросов исемендәге 254 нче гвардияче укчы полк итеп үзгәртелә. Александрның исеме часть сугышчыларының 1 ротасы исемлегенә мәңгелеккә кертелә...

Әнә шулай, А.М.Матросов үрнәгендә зур фидакарьлек үрнәге күрсәткән батырларны без дистәләрчә еллар дәва-

мында «матросовчылар» дип атап йөрттек. Архивларда катат эшләвебез, батырлар туган һәм һәлак булган урыннарга махсус экспедицияләр оештыруыбыз нәтиҗәсендә безгә шундый каһарманнардан 432 кешенең исем-фамилиясе мәгълүм булды. Шуларның 250гә якыны – утыз яшькә дә җитмәгән кешеләр. Якташыбыз Филипп Мазилинга исә (ул Татарстанның Аксубай районыннан) тиңдәшсез фидакарьлек үрнәге күрсәткәндә илле яшь тулган була!

Матросовчылар исемлегенә элеккеге СССР территориясендә яшәгән барлык милләт вәкилләре дә кергән диярлек. Араларында бер хатын-кыз (Римма Шерстнева) һәм ике малай (Миша Белуш белән Толя Комар) да бар.

Дошманның ут өермәләрен пехотачылар да, диңгезчеләр дә, танкистлар да, чик сакчылары да каплаган.

Берәмләп тә, икәүләшеп-өчәүләшеп тә...

Эзләнә торгач, тагын шундый дулкынландыргыч фактларга тап булдык: Бөек Ватан сугышы елларында А.Матросовка кадәр үк инде совет сугышчыларыннан илле сигез кеше күкрәкләре белән дошманның ут өермәләрен томалаган икән! Алар арасында якташыбызның – Бөгелмә шәһәре егетенең дә булуы күңелдә хаклы рәвештә горурлык хисләре уята.

## 1. Җырга күчкән гомер

...Алдыбызда – Татарстан АССРның Бөгелмә районында 1941 елның 15 августында оешкан 352 нче укчы дивизиянең командиры исеменә язылган политдонесение. Анда 1162 нче укчы полк сугышчысы – коммунист-сержант Әхмәт Мөхәммәтовның Смоленск өлкәсенең Груздево торак пункты янында 1942 елның 12 июле иртәсендә фашистларның позицияләренә сугышчан разведка ясаганда, күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплап, батырларча һәлак булуы турында әйтелә.

Легендар Александр Матросов күрсәткән тиңдәшсез батырлыктан җиде ай элек үлемсезлеккә атлаган әлеге каһарманның искиткеч фидакарьлеге турында тетрәнеп укыдым мин. Һәм аның турында мөмкин кадәр күбрәк белергә омтылдым. Архивларда кат-кат эшләү, эзләнү нәтиҗәсендә 1919 елда туган Әхмәт Мөхәммәтовка кагылышлы байтак документлар табылды.

Аларның беренчесе – Орша исемендәге Кызыл Байрак һәм Суворов орденлы 352 нче укчы дивизия сугышчыларының Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Председателе Г.А.Динмөхәммәтовка адресланган хаты. Билгеле булганча, 1943 елның 5 мартында «Правда» газетасында «Татар халкының фронтовик татарларга мөрәҗәгате» басылып чыга. Республикабыз хезмәт ияләре әлеге патриотик хатта үз сугышчыларына дошманны аяусыз тукмарга, тар-мар итәргә ныклы наказ бирәләр. Шул уңайдан дивизиянең барлык частьларында-подразделениеләрендә әлеге хатны ныклап өйрәнү оештырыла. Һәм ул сугышчылар күңелендә киң яклау таба, рәхимсез дошманга каршы үч-нәфрәт ялкынын тагын да көчлерәк дөрләтә. Күңелләрендә кайнаган уй-хисләрен белдереп, алар Татарстанга хат җибәрәләр:

*«...Фронтка киткәндә без фашист-илбасарларга каршы көрәштә сезнең дә, үзебезнең дә йөзгә кызыллык китермәскә сүз биргән идек. Бүген исә без, кадерле якташлар, сезгә шатланып рапорт бирәбез: беренче сугышлар алдыннан Татарстан хезмәт ияләре тапшырган Байракларны без мәңгелек данга күмдек.*

*Илебез йөрәге Мәскәүне – һәркемнең күңеленә үтә якын, сөекле, искиткеч гүзәл башкалабызны саклап калу, дошманга бирмәү өчен без, Кызыл Армиянең башка частьлары белән берлектә, батырларча көрәштек. 1941 елның салкын декабрь көннәрендә без ләгънәт төшкән фашистларны артка таба кудык. Алар бик нык каршылык күрсәттеләр. Әмма безнең омтылыш барысыннан да көчлерәк булып чыкты. Без, актив сугыш хәрәкәтләре ярдәмендә, Туган илебезне дошманнан азат итә-итә, алга таба юл алдык.*

*Сержант Әхмәт Мөхәммәтов үзенең гәүдәсе белән дошман дзоты амбразурасын каплады. Герой үлде, ләкин ул үзенең шушы каһарманлыгы-фидакарьлеге белән безнең частька җиңү яуларга ярдәм итте...»*

Әнә шулай, әлеге тарихи документта Ә.Мөхәммәтовның исеме беренче итеп зурлап телгә алына. (Хәзер бу хат Татарстан Республикасы Милли музееның Бөек Ватан сугышы фондында саклана.)

СССР Саклану министрлыгы Үзәк архивында табылган икенче документ та гаять кызыклы. 352 нче укчы дивизиянең «Вперед, на Запад!» дигән газетасында (1943 ел, 27 июнь саны) капитан Пискунов «Сержант Мөхәммәтов үзенең хәр-

би антын ничек үтәде?» дигән материал бастырган. Менә ул язма:

*«Яшь сугышчылар! Сержант Мөхәммәтовның кем икәнлеген беләсезме икән сез? Туган илебез дошманнары белән ул ничек көрәшкән? Изге хәрби антын ничек үтәгән?*

*Курку белмәс сержант безнең частьта хезмәт итте һәм ул аны мәңгелек данга күмде.*

*Туган ил сержант Мөхәммәтов өчен барысыннан да кадерлерәк иде. Фашист илбасарларга каршы көрәштә ул сигез мәртәбә яраланды. Әмма сигезендә дә, терелүгә, янәдан үз ротасына әйләнеп кайтты һәм дошманны аяусыз тукмавын дәвам итте.*

*Җәйге кыска төннәрнең берсендә, таң атканда, безнең солдатлар дошман позицияләренә сугышчан разведка ясадылар. Иң беренче рәттә коммунист Мөхәммәтов барды. Аның кыюлыгы, куркусызлыгы, тәвәккәллеге башкаларга да күчте – фашистларның көчле ут янгыры аша алга ыргылдылар. Көтмәгәндә моңарчы тын торган ут ноктасы телгә килде. Дзоттан – эре калибрлы пулеметтан аталар иде. Сугышчылар ятарга мәҗбүр булды. Шулчак сержант Мөхәммәтов, шуыша-шуыша дзотка якынрак килеп, гранаталар ыргытты һәм:*

*– Алга, иптәшләр! – дип кычкырып, торып басты. Аңа сугышчылардан Андрианов, Газадитов, Койкенов, Морозов кебек батыр йөрәклеләр иярде. Әмма ут өермәсе янәдан җанланды. Фашист ядрәләре сержант Мөхәммәтовның аяккулларын тишеп-яндырып үттеләр. Ул соңгы минутында, барлык көчен җыеп, күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын капларга өлгерде...*

*Сержант Мөхәммәтовның якты исеме, үлемсез батырлыгы безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр. Ватан-Анага биргән хәрби антына ахыргача тугры калган герой бит ул!»*

Тагын шундый бер факт да ачыкланды: ВКП(б) сафларына кандидат итеп коммунист иптәшләре тарафыннан бертавыштан кабул ителүенең икенче көнендә батырларча һәлак була Әхмәт Мөхәммәтов! Шул истәлекле көнне сержант Мөхәммәтов үзенең сугышчан иптәшләре алдында чыгыш ясап, Туган илебезне фашист илбасарлардан азат итү өчен соңгы сулышынача, ахыргы тамчы кайнар каны тамганчыга кадәр көрәшәчәге турында белдерә. Һәм комсомол сафларында тәрбияләнгән гаярь егет үз сүзендә нык тора да! Аңарчы да инде ул үзен тәвәккәл йөрәкле, куркусыз сугышчы, оста агитатор, ялкын йөрәкле пропагандист итеп таныткан була – архив доку-

ментлары әнә шул хакта сөйли. Үләренә берничә атна кала гына сержант Мөхәммәтов, бер төркем иптәшләре белән дошманның алгы сызыгына ясаган разведкалары өчен (алар фашистларның ике тубын, снарядлары белән бергә, кулга төшереп, безнең якка чыгалар), 5 нче армия командующие – Советлар Союзы Герое генерал-лейтенант И.И. Федюнинский приказы нигезендә «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән була... 12 июль иртәсендә дә ул үзенең изге бурычын тулысынча үти. Әнә шуңа күрә дә полк сугышчылары, яраткан командирларына багышлап, «Сержант Мөхәммәтов турында җыр» да иҗат иткәннәр. Минск исемендәге Кутузов орденлы 1162 нче укчы полкның сугышчан юлын яктырткан махсус альбомга бик матурлап язылган ул. Бу җырны шулай ук частьның политбүлек документлары арасында да, махсус листовкаларда да очраттым. Бөек Ватан сугышы тарихын җентекләп өйрәнүчеләр өчен дә кызыклы булыр дигән изге өмет белән, мин әлеге җырның текстын архивтан тулысынча язып алып кайттым һәм аны биредә шул килеш бирүне бик тә кирәк дип саныйм. Менә ул – солдатлар ут эчендә иҗат иткән искитмәле җыр (русчадан шагыйрь Рәниф Шәрипов тәрҗемәсендә бирелә):

Комсомол үстергән батырның күңелендә
Иленә, халкына тугрылык –
Сугышта чыныккан Мөхәммәтов-сержант
Дошманга ташлана ыргылып!

Илбасар тез чүкте, яудашлар үз итте –
Сугышта арыслан кебек Ул!
Гел үрнәк күрсәтеп, һәркемне ияртеп,
Җиңүгә юл ярган егет Ул!

Йөзләгән һөҗүмдә булдык без гел бергә,
Күзгә-күз очраттык үлемне...
Сигез кат үлде Ул, сигез кат терелде:
– Саклыйм,– дип,– яңадан Илемне!

Һөҗүмне туктатып, ут чәчә пулемет,
Чиныйлар ядрәләр очканда.
Тик баса бу шауны сержантның тавышы:
– Мәрхәмәт күрсәтмә дошманга!

Җиңүгә юл ачып, Мөхәммәтов-сержант
Дзотны каплады ыргылып...
Киселде яшь гомер, тик калды җырларда
Мәңгегә бу изге тугрылык!

*(1162 нче укчы полк фонды, 693214 тасвирлама, 2 эш, 29–30 битләр.)*

Әлеге җырны полк сугышчылары, фашистларны Туган илебездән куып чыгарып, дошманны үз өнендә тукмаганда да һәм, җиңүчеләр булып, туып үскән якларына кайтканда да телләреннән төшермәгәннәр. Җыр белән сугышчан Байрак янәшә йөргән! Әнә шулай, 23 яшьлек коммунист Әхмәт Мөхәммәтов, үлгәннән соң да, сугышчан иптәшләрен гел җиңүләргә әйдәп-рухландырып торган. Күңелләрдә дә мәңгегә җыр булып калган әлеге каһарман! Нинди бөек вә гыйбрәтле язмыш!

## 2. Әхмәт Мөхәммәтов адашы

Эзләнүләр барышында безгә тагын шундый ук исем-фамилия йөртүче икенче матросовчыга кагылышлы архив документларын табу бәхете дә насыйп булды. Анысы – Мамадыш һәм Кукмара районнарының уртак герое – Харьков исемендәге 299 нчы укчы дивизиянең 960 нчы укчы полкы разведчигы, 19 яшьлек комсомолец рядовой Әхмәт Мөхәммәтов (соңыннан ачыклавыбызча, аның тулы исем-фамилиясе Әхмәтгали Мөхәммәдиев булган. Әмма хәрби документларның һәммәсендә ул «Әхмәт Мөхәммәтов» яисә «Мөхәммәдов» диеп кыскартылып йөртелә.– *Ш. М.*).

1923 елның 3 июлендә туган егет, заманында әти-әнисе, туганнары белән Татарстаннан китеп, Донецк өлкәсендә шахтада эшләгән, яшь стахановчы буларак танылган. Фашистлар Донбасска басып кергәч, Әхмәт Мөхәммәтов биредәге яшерен оешманың иң актив әгъзаларының берсе булып әверелә. Гитлерчылар тарафыннан өч мәртәбә кулга алына, концлагерь газапларын, фашистларның рәхимсезлекләрен үз җилкәсендә нык татый. Тәвәккәл егет, әмәлен табып, әлеге үлем лагерьларыннан кача да, тиз арада үз теләге белән, Кызыл Армия сафларына баса. Сугышта ул разведчик сыйфатында нибары ике ай ярым вакыт була, күп кенә җитди хәрби операцияләрдә катнаша, яралана. Күрсәткән батырлыклары өчен башта III дәрәҗәле Дан ордены, аннары Ленин ордены белән бүләкләнә. Хөкүмәтебезнең ул чактагы иң югары бүләгенә ул 1944 елның 25 феврале төнендә Кировоград өлкәсенең Грузское авылы янында күрсәткән зур батырлыгы өчен лаек була. Үз гомерен корбан итеп – күкрәге белән дошманның ут өермәсен томалап – безнең разведчикларга югары командование тарафыннан куелган мөһим бурычның үз вакытында үтәлүен тәэмин итә ул...

Әлеге фидакарь җанның якты исеме, үлемсез батырлыгы меңнәр күңелендә яши. Халык теләген искә алып, Мамадыш районының Югары Ушмы, Кукмара районының Битләнгер (Аксыбы), Кировоград өлкәсенең Грузское авылларындагы һәм Донецк өлкәсенең Димитров шәһәрендәге урамнарга Әхмәтгали батыр исеме бирелде, истәлек билгеләре куелды. Әлеге кирәкле-мөһим чараларны тормышка ашыруда безнең «Хәтер яктысы» оешмасы әгъзалары башлап-оештырып йөрүчеләрдән булдылар. Танылган шагыйрь – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхмәт Гадел исә каһарман якташыбызга багышлап, күләмле шигъри әсәр иҗат итте. Күпләгән яшьләр оешмаларына да шул чорда Әхмәтгали батыр исеме бирелде.

1989 елның 1 сентябрендә исә – Батырларны Халыкара искә алу көнендә – Мамадыш районының «Ушмы» совхозында, Югары Ушмы урта мәктәбе каршындагы иркен мәйданда фидакарь разведчик Әхмәт Мөхәмmәтовка мәһабәт һәйкәл ачылды. (Аның авторы күренекле скульптор Әлфәрит Әбдерәшитов.) Әлеге тантанага каһарман якташыбызның СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче туганнары – Башкортстаннан Миннегали ага, Үзбәкстанның Фирганә өлкәсеннән Маһитап ханым, Мамадыш шәһәреннән Маһисәрвәр ханым, шул ук районның «Кама» урман хуҗалыгыннан Муллагали абый Мөхәммәдиевларны һәм Донецк өлкәсенең Димитров шәһәреннән «Эзләнү» группасы җитәкчесе – педагог, украинка Энгелина Вячеславовна Чуприна, Воронеждан гвардияче полковник, хәрби журналист Виктор Петрович Ожерельев, Кировоград өлкәсенең Грузское дигән молдован авылыннан Чапаев исемендәге күмәк хуҗалык рәисе урынбасары Николай Федорович Бескровный, Грузское авыл советы башкарма комитеты рәисе Александр Анатольевич Любенко иптәшләрне дә махсус чакырып китергән идек. Гаҗәеп олы бәйрәм – халыклар дуслыгы бәйрәме булып әверелде әлеге дулкынландыргыч очрашулар! Аларның һәркайсы кинотасмада һәм фоторәсемнәрдә чагылыш тапты. Сүз уңаенда шунысын да әйтик: заманында –1985 елның август азагында һәм сентябрь башында – безнең «Хәтер яктысы» экспедициясе (аның составында Әхмәтгали батырның бертуган энесе Миннегали ага, Югары Ушмы урта мәктәбенең эзтабарлар төркеме җитәкчесе – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган мөгаллим Фәрит Хәйруллин, уку алдынгысы Әлфия Мөхлисова, кинооператор – респуб-

ликабыз телестудиясенең кинопрограммалар буенча мөхәррире Камил Арифуллов бар иде.– *Ш.М.*), Донецк һәм Кировоград өлкәләрендә Ә.Мөхәммәдиевка бәйле урыннарда булып, андагы онытылмас очрашуларны да кинотасмага һәм фоторәсемгә төшереп алды. Менә шул бай материалларга таянып, без каһарман якташыбызга багышланган документаль фильм иҗат иттек һәм ул республикабыз телевидениесе тапшыруларында кат-кат күрсәтелде...

## 3. Матросовчылар күпме?

Эзләнүләр дәвам итә. Безгә хәзер Әхмәтгали Мөхәммәдиевның адашы Әхмәт Мөхәммәтовның фоторәсемен, туганнарын, сугышчан дусларын эзләп табасы, Бөгелмә шәһәрендә аның үлмәс батырлыгын, якты исемен мәңгеләштерәсе бар. (Эзләнүләр барышында тагын шундый кызыклы фактлар ачыкланды: заманында Ә.Мөхәммәтов хезмәт иткән 1162 нче укчы полкның партоешма секретаре күренекле шагыйрь Нур Баян булган, ә 352 нче укчы дивизиянең башында татар генералы Рәхим Сәхибгали улы Мәксүтов (1899– 1949) торган.)

Бөгелмәдәге 11 нче урта мәктәптә 352 нче укчы дивизиянең сугышчан Дан музее (җитәкчесе – дивизия ветераны, отставкадагы капитан Иван Саввович Закреничный) уңышлы гына эшләп килә. Шәһәрнең Михаил Калинин һәм Газинур Гафиятуллин урамнары кисешкән чатындагы иркен мәйданда дивизиянең данлы сугышчан юлын гәүдәләндергән мәһабәт монумент балкып тора. Тик хәзергә әле музейда да, монументта да Әхмәт Мөхәммәтов батырлыгы тиешенчә чагылдырылмаган. Чөнки әле монда да, А.Матросов – күкрәге белән дошманның ут ноктасын каплаган беренче Герой! Аңа кадәр шундый фидакарьлек күрсәтүченең булуы һич тә мөмкин хәл түгел! Булса, күптән язып чыгарлар иде, дигән фикер яшәп килгән.

Әмма үзгәрешләр, хәбәрдарлык заманасының саф җилләре архивларда моңа кадәр кеше кулы тигәнне көтеп, тузан җыеп яткан кадерле документларга ныклап кагылып үтте, аларның һәр битен ачып, хаксызга онытылган исемнәрне барларга, тарихи дөреслекне язарга мөмкинлек бирде.

Әйе, легендар Матросовка кадәр дә бик күпләр, Җиңү хакына, күкрәкләре белән дошманның ут ноктaларына ятканнар. Хәтта шунысын да әйтик: мондый фидакарьлек үрнәген иң беренче мәртәбә моннан күп еллар элек комсомо-

лец Пелевин күрсәтә. Ул 1919 елның июнендә «революция бишеге» Петроград янындагы Керестенево авылы тирәсендә генерал Юденичның акгвардиячеләренә каршы барган хәлиткеч бер көрәштә күкрәге белән дошманның ут өермәсен каплый... Башкортстанның Нуриман районындагы Иске Бөреч авылыннан ветеран педагог Габит ага Хәммәтнуровның безгә җибәргән хатыннан күренгәнчә, гражданнар сугышы чорында Быков фамилияле солдат та шундый батырлык үрнәге күрсәткән икән – әлеге факт Советлар Союзы Маршалы К.Е.Ворошиловның истәлекләрендә сакланып калган.

Тик мондый егетлек үз вакытында тиешенчә бәя алмаган, киң яктыртылмаган... Бүгенге көндә безгә А.Матросовка кадәр булган шундый фидакарьләрдән алты дистәгә якын кешенең исеме-фамилиясе яхшы билгеле. Эзләгән саен аларның тагын да күбрәк булачагына һич тә шигебез юк.

*(Безнең белешмә: Подольск шәһәрендәге Россия Саклану министрлыгы Үзәк архивында гына да биш миллиард (!) тарихи документ саклана. Илебезнең төрле төбәкләреннән үтенеч-сорау белән бирегә көн саен уртача 2500 хат килә. Әмма архив хезмәткәрләренең хат авторларына үз вакытында җавап бирергә мөмкинлекләре чикле. Дөрес, бер үтенеч-сорау да җавапсыз калдырылмый. Әмма аны күпчелек очракта айлар буе көтәргә туры килә. Чөнки эзләнү – теге яки бу фактны, тарихи дөреслекне ачыклау өчен – һәркемнән байтак вакыт һәм түземлелек сорый. Ә инде архивка үзең «казынырга» барсаң, бу мәсьәлә чагыштырмача җиңелрәк хәл ителә.)*

Җентекле эзләнүләр нәтиҗәсендә хәзер бездә сержант Әхмәт Мөхәммәтовның гвардияче комсомолец А.Матросовтан 225 көн алда күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплавы турында сөйләүче тарихи документлар бар. Тик аларда каһарман якташыбызны соңгы батырлыгы өчен бүләкләү турында бер сүз дә юк. Бу аңлашыла да: күкрәкләре белән фашистларның ут өермәләрен томалаган 400 дән артык сугышчының бары тик 169ына гына Советлар Союзы Герое исеме бирелгән, зур күпчелеге Ватаныбызның төрле дәрәҗәдәге орденнары белән бүләкләнгән. Кайберләренә исә сугыш ыгы-зыгысы аркасында, Бүләкләү кәгазьләре дә тутырылмаган. Мөгаен, Ә.Мөхәммәтов та шул исәпкә керәдер. Аннары бу вакытның әле сугышчан хәрәкәтләр алып баруда башлангыч чор икәнлеген дә истән чыгармаска ки-

рәк – ул чакта орден-медальләрне бик азлап кына биргәннәр. Шулай да без әле өметне өзмибез – архивларда эзләнүләрне дәвам иттерәбез... Бу өлкәдә безгә Ә.Мөхәммәтовның сугышчан дусларының, аны якыннан белүчеләрнең дә ярдәме бик кирәк. Каһарман якташыбызның сугышка кадәр булган тормышы да әлегә ачык билгеле түгел... Биредә тагын шунысын да искәртеп үтик: Үзәк архивта «казынганда» без Әхмәт Мөхәммәтовтан да алданрак зур каһарманлык үрнәге күрсәткән тагын бер шәхесне – республикабызның Мамадыш–Тәкәнеш–Кукмара төбәгендә туып үскән Сәмигулла Кәримуллинны эзләп таптык. Аның турында тулырак итеп соңыннанрак сөйләрбез...

## 4. Кем син, Матросов?

Соңгы вакытта ачыкланганча, А.Матросовның биографиясендә дә хәзерге көнгәчә «ак таплар» яшәп килгән икән. Эзтабарларның тынгысызлыгы нәтиҗәсендә матбугатта аның кайда туганлыгы һәм чын исем-фамилиясе хакында да яңа мәгълүматлар игълан ителде. Бу сүзләрне Башкортстанда яшәүче танылган журналист-эзтабар һәм язучы-публицист Рәүф Хәй улы Насыйровның «Совет Башкортостаны» газетасында (1988 ел, 228–230 һәм 263 саннар) басылган «Син кайдан, Матросов?» һәм шул ук газетаның 1989 елгы 258–260 саннарында дөнья күргән «Мине Матросов диеп атагыз...» дигән зур күләмле, дулкынландыргыч язмаларына, эзләнү-ачышларына карата әйтәм. Әлеге авторның Уфада «Китап» нәшриятында 1994 елда рус телендә дөнья күргән «Откуда ты родом, Матросов?» дигән күләмле документаль-тарихи әсәре дә каһарман турында чын хакыйкатьне ачу юнәлешендә күңел ышанырлык төпле дәлилләрдән тора. Чыннан да, моңарчы А.Матросовка кагылышлы төрле документларда һәм аның хакында язылган китапларда батырның туган җире итеп Украина, Днепропетровск шәһәре күрсәтелде. Әмма бу дөреслеккә туры килми икән. И.Легостаевның «Бросок в бессмертие» китабына кереш сүз язган генерал-полковник И.Медников та бу хакта: «...Матросовның балачагы турында нинди дә булса дөрес мәгълүматлар сакланмаган»,– дип, ачыктан-ачык аңлатып, искәртеп үтә. Тагын бер саллы дәлил: моннан байтак еллар элек «Правда» газетасында Мәскәү язучысы, тарих фәннәре кандидаты М.Шка-

даревичның, Днепропетровскига барып, А. Матросовның туган җирен ачыклау белән шөгыльләнүе турында хәбәр иткәләп иде. Әмма анда әдип-галим Матросовка кагылышлы берни дә таба алмый. Шәһәрдә хәтта Матросов атлы кешеләрнең бөтенләй булмавын ассызыклап әйтеп, ул әлеге фамилиянең уйлап чыгарылуы гына мөмкин дигән мөһим нәтиҗәгә килә. Мин үзем дә Үзәк архивта эшләгән вакытта А.Матросовны бүләкләүгә кагылышлы документлар белән җентекләп таныштым. Тик аларда да батырның туган җире күрсәтелмәгән иде... (Кара: 33 фонд, 682525 тасвирлама, 32 эш, 305–317 битләр.)

Ә кайдан, кем соң ул Александр Матросов? «...Башкортстанның Учалы районындагы Кунакбай авылында туып үскән ул,– дип яза Р.Насыйров.– Матросовның чын фамилиясе – Мөхәммәтҗанов. Исеме – Шакирҗан. Әтисе – Юныс. Әнисе – Мөслимә...» Ә ничек Матросов булып киткән соң Мөхәммәтҗанов? Аңа да җавап бар.

Гражданнар сугышыннан гарипләнеп кайткан, өстәвенә сукыр да булган, әмма бик җор сүзле, шаян табигатьле, хыялга бирелүчән, әкиятләр сөйләргә яратучы Юныс солдат гаиләсендә 1923 елда туа Шакирҗан. Әнисе үлгәч, әтисе Фәрхиямал исемле икенче хатынга өйләнә. Яшәү шартлары үтә авыр була аларның – иске генә мунчада көн күрәләр. Ашау-эчү ягы да бик такыр. Аптырагач, Шакирҗан 1934 елда, унбер яшендә, авылны ташлап читкә чыгып китә. Шуннан соңгы тормышы юлда, балалар йортларында, хезмәт колониясендә үтә. Безнең Казанда да калган аның эзләре...

Үтә фәкыйрьлектә яшәгән туган авылына кире кайтаруларыннан куркып, Шакирҗан үзенең туып үскән төбәген дә, чын исем-фамилиясен дә үзгәртергә мәҗбүр була. Кыскасы, матрос киеменә, матрос биюенә гашыйк егет Саша Матросовка әйләнә һәм соңыннан шул исем-фамилия белән бөтен дөньяга танылa...

Тарихта мондый гыйбрәтле мисаллар шактый. Актаныш районының Зөбәер авылында туган атаклы партизан – Советлар Союзы Герое Гатаулла Минаев, мәсәлән, ил күләмендә Николай Орлов буларак яхшы билгеле (бу хакта танылган эзтабар әдип Ш.Рәкыйповның «Мәтрүшкәләр һаман хуш исле» дигән кыйссасында бик җентекләп язылган). Саный китсәң, байтак алар – мондый асыл азаматлар!

Матросов-Мөхәммәтҗановка хәзер туган ягында музей

ачылган. Халык үз улын онытмый, зурлый һәм аны чын исем-фамилиясе белән атый. Галиҗәнап Тарих, әнә шулай, дөреслекне ярата, хакыйкатьне яңарта!..

## 5. Исемнәре кайтты дан булып...

Инде үзебезнең республикада туып үскән матросовчыларга – мөхәммәтҗановчыларга килсәк, аларның саны хәзер ике дистәдән артып китте. Каһарманнарның берсе – чуваш, дүртесе – урыс, калганнары – татар халкы вәкилләре. Аларның саны күбрәк тә булуы ихтимал. Эзләнүләр дәвам итә...

Эзләнүләр дигәннән, бу уңайдан Татарстандагы Кукмара районының матросовчы-шагыйрь Нух Идрисов исемендәге Түбән Өскебаш урта мәктәбен (директоры – Республикабызның атказанган укытучысы Әгъзәм Әгъмәл улы Гарипов) мактап телгә аласы килә. Биредә матросовчы-мөхәммәтҗановчы якташларыбызга багышланган музей бик яхшы эшләп килә. Каһарманнарның һәркайсына монда игътибар зурдан: ике катлы мәктәпнең иркен коридорлары да, якты класслар да аларга багышланган төсле рәсем-портретлар, сугыш эпизодлары, архив документлары, илнең төрле почмакларына оештырылган экспедиция материаллары белән баетылган. Телисең икән, мәктәпнең «Батырлык» кинофотостудиясендә шул фидакарь җаннарга багышланып эшләнгән документаль кинофильмнар белән танышырга, ишегалдында исә аларның мәгърур бюстларына карап сокланырга мөмкин...

Әйдәгез «Күкрәкләре белән дошманның ут өермәләрен томалап, Бөек Җиңү таңын якынайткан каһарманнарыбыз» дигән ялкынлы сүзләр язылган изге урынга тукталыйк. Менә алар – фидакарь җаннар:

1. Сәмигулла Гарифулла улы КӘРИМУЛЛИН – 21 нче гвардияче укчы дивизиянең 69 нчы гвардияче укчы полкы политругы. 1906 елның 30 (17) июлендә Казан губернасының Мамадыш өязендәге Югары Арбаш авылында туган (хәзер бу авыл Кукмара районына керә.– *Ш.М.*). 1942 елның 31 мартында Смоленск өлкәсенең Сычевка районындагы Холминка авылы янында безнең сугышчыларны гитлерчыларга каршы атакага күтәрә һәм, хәлиткеч җитди мизгелдә, коралдашларына җиңү яулауда булышу өчен, дошманның ут өермәсен күкрәге белән каплый.

2. Әхмәт Готуф улы МӨХӘММӘТОВ – 1941 елның августында Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә оешкан 352 нче укчы дивизиянең 1162 нче укчы полкы сержанты, ВКП(б) әгъзалыгына кандидат. 1919 елда туган. 1942 елның 12 июле иртәсендә Смоленск өлкәсенең Груздево авылы янында, фашистларның ут позицияләренә сугышчан разведка ясаганда, күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплый.

3. Александр Матвеевич МАТРОСОВ (чын исеме – Шакирҗан Юныс улы Мөхәммәтҗанов) – 56 нчы гвардияче укчы дивизиянең 254 нче укчы полкы рядовое, автоматчы, ВЛКСМ члены. 1923 елның 5 февралендә Башкортстанның Учалы районындагы Кунакбай авылында туган. 1943 елның 23 февралендә Псков өлкәсенең Великие Луки районындагы Чернушки авылы өчен барган сугышларда һәлак була. Күрсәткән тиңдәшсез батырлыгы өчен, СССР Югары Советы Президиумының 1943 елгы 19 июнь Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек була. А.М.Матросовның исеме үзе хезмәт иткән часть сугышчылары исемлегенә мәңгелеккә кертелә.

4. Афанасий Леонтьевич ПАНАРИН – 112 нче укчы дивизиянең танкка каршы ата торган артиллерия взводы командиры, лейтенант, ВЛКСМ әгъзасы. 1924 елда Татарстанның Баулы районындагы Кырым-Сарай авылында туган. 1943 елның 26 мартында Курск өлкәсенең Ефросимово авылын дошманнан азат иткәндә батырларча һәлак була – орудиесе сафтан чыккач һәм үзе авыр яралангач, күкрәгенә танк шартлаткыч граната кысып, дошман дзоты амбразурасына ташлана.

5. Сәйфулла Гайфулла улы ЙОСЫПОВ – диңгез пехотасының 143 нче аерым батальоны разведчигы, рядовой, ВКП(б) әгъзалыгына кандидат. 1912 елда Башкортстанның Чишмә районындагы Салих авылында туган. Милләте – татар. Заманында Казан, Уфа, Ленинград шәһәрләрендә эшләгән... 1943 елның 7 августында Новороссийск шәһәре янындагы Долгая тавында күкрәге белән дошманның ут өермәсен каплый. I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

6. Абдулла СӘЛИМОВ (хәрби документларда әтисенең исеме күрсәтелмәгән) – 248 нче укчы дивизиянең 902 нче укчы полкы рядовое, пулеметчы, ВЛКСМ әгъзасы. 1917 елда Казанда, Восстание урамындагы 23 йортта туган. 1943 елның 19 августында Ростов өлкәсенең Матвеево-Курганск районындагы Петрополье авылы янында һәлак була. Алек-

сандровка авылына күмелә. I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

7. Сәләхетдин Хәлиулла улы ВӘЛИУЛЛИН – 18 нче армия карамагындагы 255 нче диңгез пехотасы бригадасына караган 142 нче аерым укчы батальонның 2 нче ротасы парторгы, өлкән сержант, ВКП(б) әгъзасы. 1903 елда Татарстанның Тәтеш районындагы Келәш авылында туган. 1943 елның 15 сентябрендә Новороссийск шәһәре өчен барган сугышта һәлак була. I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

8. Мансур Али улы ВӘЛИУЛЛИН – 318 нче укчы дивизиянең 796 нчы укчы полкы өлкән сержанты, радиостанция начальнигы, ВКП(б) әгъзасы. 1915 елда Татарстанда туган. Әти-әнисе үлгәч, аны Бакуга балалар йортына җибәрәләр. Ул шунда тәрбияләнә, нефтьче булып эшли, шуннан фронтка китә. 1943 елның 15 сентябрендә Новороссийск янында күкрәге белән дошманның ут өермәсен каплый. Әмма исән кала – госпитальләрдә 8 ай дәваланып, яңадан сугышчан сафка баса. «Батырлык өчен» медале һәм Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Сугыштан соң, М.А.Вәлиуллин Әлмәт шәһәрендә яши, 1988 елда вафат була.

9. Арсентий Максимович КАРТАШОВ – 69 нчы гвардияче укчы дивизиянең 208 нче гвардияче укчы полкы рядовое, автоматчы, ВЛКСМ әгъзасы, милләте – чуваш. 1925 елда Татарстанның Буа районындагы Әлшәй авылында туган, 1943 елның 5 октябрендә Кировоград өлкәсендә Днепр буендагы Старое Липово авылы янында һәлак була.

10. Кәрим Исхак улы ИСХАКОВ – 69 нчы гвардияче укчы дивизиянең 208 нче укчы полкы рядовое, автоматчы, партиясез. 1911 елда Татарстанның Кызыл юл (хәзерге – Арча) районының Шушмабаш авылында туган. 1943 елның 5 октябрендә, чуваш егете Арсентий Карташов белән бергә, дошманның ут өермәсен томалап, Кировоград өлкәсенең Старое Липово авылы янында батырларча һәлак була.

11. Газинур Гафиятулла улы ГАФИЯТУЛЛИН – 37 нче укчы дивизиягә караган 20 нче укчы полкның отделение командиры, сержант, ВКП(б) әгъзалыгына кандидат. 1913 елның 14 гыйнварында Татарстанның элеккеге Шөгер (хәзерге Лениногорск) районының Сугышлы авылында туган. 1944 елның 14 гыйнварында Псков өлкәсенең Новосокольники районына караган Овсищи авылын алу өчен барган сугышта һәлак була, СССР Югары Советы Президиумының 1944

елгы 4 июнь Указы нигезендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

12. Котдус Габдрахман улы ГАБДРАХМАНОВ – 58 нче гвардияче укчы дивизиягә караган 175 нче гвардияче укчы полкның рота командиры, өлкән лейтенант, ВКП(б) әгъзасы. 1908 елда Татарстанның Бондюг эшчеләр поселогында (хәзерге Менделеевск шәһәрендә) туган. 1944 елның 8 февралендә Кировоград өлкәсенең Лелековка авылы янында һәлак була.

13. Әхмәтгали Мөхәммәди улы МӨХӘММӘДИЕВ (Әхмәт Мөхәммәтов) – 299 нчы укчы дивизиянең 960 нчы укчы полкы разведчигы, рядовой, ВЛКСМ әгъзасы. 1923 елның 3 июлендә туган. Нәсел-тамырлары Татарстанның Кукмара районындагы Битләнгер авылына һәм Мамадыш районының Югары Ушмы авылына барып тоташа. Сугышка хәтле Донецк өлкәсенең Красноармейск районындагы Димитров шәһәрендә яши, шахтада эшли. 1944 елның 25 феврале төнендә Кировоград өлкәсенең Грузское авылы янында һәлак була. Күрсәткән батырлыклары өчен Ленин ордены һәм III дәрәҗәле Дан ордены белән бүләкләнә.

14. Филипп Николаевич МАЗИЛИН – 161 нче ныгытылган районадагы 13 нче аерым пулемет-артиллерия батальонының 4 нче ротасында пулемет расчеты командиры, өлкән сержант. 1894 елны хәзерге Татарстанның Аксубай районындагы Козловка (Дмитриевка) авылында туган. 1944 елның 1 мартында Белоруссиянең Жлобин районына караган Мормаль авылы янында һәлак була: командиры – лейтенант Жуйков Николай Петрович белән берлектә, күкрәге белән дошманның ут өермәсен томалый. СССР Югары Советы Президиумының 1944 елгы 23 июль Указы нигезендә Ф.Н.Мазилин һәм Н.П.Жуйков иптәшләр Ленин ордены белән бүләкләнәләр.

15. Бари Гани улы ШӘВӘЛИЕВ – 31 нче гвардияче укчы дивизиягә караган 95 нче гвардияче укчы полкның 5 нче укчы ротасында отделение командиры, гвардия сержанты, ВЛКСМ әгъзасы. 1925 елда Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Түбән Тимерлек авылында туган. 1944 елның 23 июнендә Витебск өлкәсенең Орша районындагы Остров Юрьев (Осинторф) пункты өчен барган сугышларда ул, украин егете – гвардия лейтенанты Иван Абрамович Ильченко белән икәүләшеп, дошманның бер үк ут өермәсен күкрәкләре белән каплыйлар. I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләнәләр.

16. Нух Идрис улы ИДРИСОВ – 313 нче укчы дивизиянең 1070 нче укчы полкында автоматчылар взводы командиры, лейтенант, ВКП(б) әгъзасы. 1918 елның 16 октябрендә Татарстанның элекке Тәкәнеш (хәзерге Кукмара) районындагы Битләнгер (Аксыбы) авылында туган. 1944 елның 27 июлендә Карелиянең Суоярви районында һәлак була. Күрсәткән батырлыгы өчен I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

17. Николай Дмитриевич ЛИПАТОВ – 150 нче укчы дивизиягә караган 973 нче артиллерия полкының 6 нчы батареясе өлкән телефонисты, рядовой, ВКП(б) әгъзасы. 1916 елны Татарстанның Биектау районындагы Тимошкино авылында туган. 1944 елның 13 августында Польшаның Грабув авылы янында һәлак була. 1944 елның 26 октябрендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Н.Д.Липатовның исеме үзе хезмәт иткән часть сугышчылары исемлегенә мәңгелеккә кертелә.

18. Хафиз Зариф улы ЗАРИПОВ – 3 нче Украина фронтының Николаевск ныгытылган районына караган 10 нчы аерым пулемет-артиллерия полкының пулемет расчеты командиры, гвардия сержанты, ВКП(б) әгъзасы. 1906 елда Татарстанның Әлки районындагы Баллыкүл авылында туган. 1944 елның 22 августында Одесса өлкәсендә Днестр лиманын кичкәндә һәлак була. Сугышчан Кызыл Байрак, III дәрәҗәле Богдан Хмельницкий, I дәрәҗәле Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә.

19. Зариф Закир улы АЛИМОВ – 23 нче танк корпусы карамагындагы 56 нчы мотоукчы бригаданың 3 нче мотоукчы батальонында взвод командиры, лейтенант, ВКП(б) әгъзасы. 1921 елда Татарстанның Чүпрәле районындагы Яңа Кәкерле авылында туган. 1945 елның 31 гыйнварында Венгрияне фашист-илбасарлардан азат иткәндә, Веленце күле тирәсендәге Петэнд торак пункты янында һәлак була. 1945 елның 24 мартында аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

20. Алексей Петрович ИСАЕВ – 180 нче укчы дивизиягә караган 42 нче укчы полкның автоматчылар отделениесе командиры, сержант, ВКП(б) әгъзасы, рота парторгы. 1906 елны Татарстанның Югары Ослан районындагы Малая авылында туган. 1945 елның 22 гыйнварына каршы төндә Венгриянең башкаласы – Будапешт өчен барган сугышларда һәлак була. 1945 елның 28 апрелендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. А.П.Исаевның исеме үзе хезмәт иткән часть сугышчылары исемлегенә мәңгелеккә кертелә.

21. Нургали Сәләх улы АКМАЛЕТДИНОВ – 225 нче укчы дивизиянең 115 нче аерым разведка ротасы разведчигы, сержант, ВКП(б) әгъзасы. 1921 елда Татарстанның Буа районындагы Шәйморза авылында туган. 1945 елның 22 февралендә Германиянең Опельн районындагы Хельсбердорф торак пункты янында һәлак була.

22. Хәбибулла Хәмидулла улы ХӘМИДУЛЛИН – 334 нче укчы дивизиягә караган 112 нче укчы полк старшинасы. 1906 елда Казан губернасының Мамадыш өязенә керүче Зур Өске авылында туган. 1945 елның 18 мартында Көнчыгыш Пруссиядә һәлак була (кабере – хәзерге Калининград өлкәсенең Багратионовск районындагы Корнево авылында).

23. Әсгать Әхмәтхәниф улы ВАФИН – 5 нче армиянең 159 нчы Витебск укчы дивизиясе карамагындагы 597 нче артиллерия полкында разведка командиры. 1924 елның 22 декабрендә Башкортстанның Дәүләкән районындагы Мерәс авылында туган. 1945 елның апрелендә Көнчыгыш Пруссиядә барган хәлиткеч көчле сугышлар вакытында күкрәге белән дошманның ут өермәсен томалый.

24. Әгъмәлетдин Фәттах улы ФӘТТАХОВ – 293 нче укчы дивизиянең 1034 нче полкы автоматчысы, рядовой, ВЛКСМ әгъзасы. 1919 елда Татарстанның Мамадыш районындагы Урта Кирмән авылында туган. 1945 елның 18 августында Маньчжуриядә дошманның мөһим терәк пунктын штурм белән алганда батырларча һәлак була... Сүз уңаенда шунысын да әйтик: Әгъмәлетдин – 9 балалы ишле гаиләдә иң соңгысы. Бертуганнарыннан 7 абыйсы да Ватан-Ананы саклау өчен барган изге көрәштә газиз гомерләрен бирәләр...

* * *

...1945 елның августында Азия кыйтгасында сугышның соңгы утлы нокталарын күкрәкләре белән томалап, илебез күгендә Җиңү таңын балкытып аттырган каһарманнар арасында безнең якташыбызның да булуы күңелләрдә хаклы рәвештә горурлык хисләре уята. Укчы-автоматчы Әгъмәлетдин Фәттахов, Советлар Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский җитәкчелегендәге Забайкалье фронты гаскәрләре сафында, дошманның Квантун армиясенә каршы хәлиткеч-җитди һөҗүмнәрдә катнаша. Хинган-Мукден операциясе барышында 36 нчы армия сугышчылары японнарның җиңелмәс дип исәп-

ләнгән 6 мең кешелек Хайлар гарнизонын «тез чүктерәләр». Шул армиянең гади бер сугышчысы Әгъмәлетдин Фәттах улы Фәттахов, украин егете – 24 яшьлек ефрейтор Владимир Прокопьевич Бульба белән бергә, 18 августта дошман дзотының үлем уклары чәчүче амбразурасын күкрәге белән каплап, Үлемсезлеккә атлый...

19 августта инде япон гаскәрләре каршылык күрсәтүләрен тулысынча диярлек туктатып, безнекеләргә бирелергә мәҗбүр булалар... 2 сентябрьдә исә Икенче Бөтендөнья сугышына нокта куела – фашистлар Германиясеннән соң, милитаристик Япония дә үзенең җиңелүен берсүзсез таный...

Сүзебезне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: Әгъмәлетдин Фәттахов кебек фидакарьләребез бик күп безнең. Ялкынлы-кайнар йөрәкләре белән дошман ядрәләрен эреткән билгесез ул каһарманнарның да якты исемнәре тиздән, данга төрелеп, безнең арабызга кайтыр, күңелебез күкләрендә йолдызлардай балкыр! Галәм – ай-кояш, йолдызлары белән, халкыбыз исә үзенең батырлары белән матур бит...

## СИГЕЗ БИЗӘКЛЕ СӨЛГЕ

...Сөлге чигәм асыл җепләр белән,
Йөрәк хисем салып бу җырга...

*Хәлим Җәләлов,*
Татарстанның халык артисты,
шагыйрь

Борынгы Мамадыш шәһәренең төбәк тарихын чагылдыручы искиткеч бай музеенда булган кешеләр еш кына, бик озаклап, бер экспонат – бизәкләп чигелгән Сөлге янында тукталып, тирән уйларга чумып басып торалар. Чөнки ул – гадәти Сөлге түгел, ә Туган җиребезгә сигез каһарманны бүләк иткән изге Ананың өмет белән тулы күз нурларын, дәртле вә сагышлы илаһи җырларын, йөрәк җылысын, кайнар күз яшьләрен үзенә сеңдергән, эшчән вә хисчән халкыбызның йөз аклыгын, намусын, күңел байлыгын чагылдырган биниһая кадерле Сөлге. Легендар Фатыйха түти Әхмәдиева Сөлгесе. Сигез бизәкле Сөлге. Сигез бизәк – яшәргә дип бу җиһанга килеп тә, яу кырында гомерләре вакытсыз өзелгән сигез улы төсе...

## 1. Көтелмәгән очрашу

...Заманында миңа бу гаиләнең үтә гыйбрәтле язмышы һәм Фатыйха түтинең оныклары белән танышырга Мамадыш районындагы Урта Кирмән авылында яшәүче Габденур абзый Ибраһимов ярдәм иткән иде. Гадәтемчә, ял көннәренең берсендә, «Казан–Чаллы» автобусыннан төшеп, Урта Кирмән аша туып үскән авылым Арташка, газиз әниемнең, якыннарымның хәл-әхвәлләрен белергә дип ашкынып кайтканда, мине «Игенче» күмәк хуҗалыгы идарәсе урнашкан бина каршында – үткән сугышта һәлак булган якташларыбыз истәлегенә куелган һәйкәл янында – шул абзый туктатты.

Бөек Җиңүне бәйрәм иткән кояшлы матур бер көн иде. Уртача буйлы, чандыр гәүдәле Габденур абзыйның күзләре мөлдерәмә яшь белән тулган. Халык, яу кырында ятып калганнарны сагынып искә алып, Җиңү яулап, исән кайтканнарны, тылда фидакарь хезмәт күрсәткәннәрне хөрмәтләп, күптән инде өйләренә таралышкан булса да, әлеге ветеран солдат берүзе, Тукаебыз әйтмешли, «тик икәү без: уй да мин» дигәндәй, моңаеп басып тора иде.

Мине күргәч, Габденур абзыйның күз карашы ничектер яктырыбрак киткәндәй булды.

– Исән-саулыкмы, Шаһинур энем, озын гомерле булырсың әле, сине бүген иртән генә искә алган идек,– диде ул, күп эшләүдән яргаланып беткән сөялле кулларын миңа сузып.– Ишетеп-укып торам: сугыш булган байтак җирләрдә йөрисең, архивларда эшлисең... Моңарчы исемнәре дә билгеле булмаган бик күп батырларны дөньяга таныттың: нәселдәшләрен, якыннарын сөендердең... Рәхмәт үзеңә!.. Инде тыңла, минем дә гозерем бар сиңа: безнең Фәттах абзый белән Фатыйха түтинең сигез улы турында да язып чыксаң иде, вакыт табып. Аларның бит берсе дә сугыштан әйләнеп кайтмады...

Бу сүзләр мине сискәндереп-тетрәндереп җибәрде. Әйтерсең лә, көтмәгәндә, өстемә баштанаяк бер кисмәк кайнар су сиптеләр! Дөресен әйткәндә, әлеге каһарман якташларым турында шушы көнгәчә белмәвем өчен чиксез оят булып китте...

Көтелмәгән бу очрашу миңа эзләнүләр өчен көчле этәргеч бирде. Якташларымнан байтак кешеләр белән очрашып, күптөрле гуаһнамәләр (документлар) белән танышып, Фәттах абзый белән Фатыйха түти һәм аларның уллары – бер-

туган Фәттаховлар турында байтак материаллар тупладым, дүртесенең фоторәсемнәрен дә таптым (соңыннан, шул тонык-саргаеп беткән фотоларны файдаланып, танылган рәссам-график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Эрот Зарипов язмам геройларының рәсемнәрен дә ясады.– *Ш.М.*). Ни кызганыч, калган дүрт улының фоторәсемнәрен дә табу мөмкин булмады. Шулай да моннан күп еллар элек Фатыйха түти үз куллары белән тукыган, инде исеме телгә алынган, бәһа биреп бетергесез тарихи Сөлгене күрү бәхетенә дә ирештем. (Ул Сөлге Фатыйха түтинең оныгы, Габденур абзыйның бертуганы – Урта Кирмән авылында яшәүче Марзия апа Бикмурзина гаиләсендә иң кадерле ядкарь буларак сакланган икән.– *Ш.М.*)

Эзләнүләр барышында миңа Фәттаховлар гаиләсенә охшаган тагын берничә гаилә язмышы белән танышырга да туры килде. Биредә, Фәттаховлар турында тәфсилләп сөйли башлаганчы, укучыларыбызны кыскача гына шул гаиләләрнең берничәсе белән таныштырып үтәм.

## 2. Лысенколар

...Мәскәүдә, илебез Кораллы Көчләре Үзәк музеенда йөргәндә, 17 нче залда очраттым мин аларны. Очраттым һәм... фоторәсемнәреннән күзләремне һич кенә дә ала алмадым. Кеше ышанмаслык гаҗәеп факт: бер гаиләдән, бер ата белән ананың ун улы Бөек Ватан сугышына китеп, унысы да Җиңү яулап, исән-сау кайтканнар, батырлар булып кайтканнар! Черкасс өлкәсенең Корсунь-Шевченко районындагы Бровахи авылында туып үскән Феодосий, Петр, Степан, Михаил, Андрей, Николай, Александр, Иван, Павел, Василий Лысенколар алар! Әлеге ир-егетләр тыныч тормышта да үзләрен фидакарь җаннар итеп танытканнар. Араларында кемнәр генә юк аларның! Игенчеләр, терлекчеләр, төзүчеләр... Барысы да туып үскән җирләрендә ныклап төпләнеп калып, гаилә корып, балалар үстереп, күптармаклы меңьяшәр горур имән кебек, Лысенколар данын киләчәк гасырларга да илтәләр алар. Күмәк фоторәсемдә Җиңү көнендә авыл мәйданында төшкән бертуган Лысенколарның йөзләреннән, үзүзләрен тотышларыннан эчке бер горурлык, таза рух, җирнең, тормышның чын хуҗалары булу хисе бөркелеп тора – шуңа күрә аларга кат-кат карап сокланасың...

## 3. Степановлар

Сүз дә юк, Лысенколар – искиткеч бәхетле язмыш кешеләре! Гәрчә мондый күренеш үтә сирәк очраса да, сугыш алласы Марс аларның ишле гаиләсен ничектер аяган! Ә менә Степановлар гаиләсенә ул бетмәс-төкәнмәс авыр кайгылар китергән. Уйлап карагыз: Краснодар краеның Тимашевский районындагы Шкуропадский (Беренче Май) хуторында гомер итүче Епистиния Федоровна белән Михаил Николаевичның барлык уллары – тугызы да! – бик яшьләй һәлак була. Гражданнар сугышы елларында беренче уллары Александрны – 18 яшьлек якты күңелле, җырчы егетне – кызылармеецларның пушкаларын төзәтүдә булышканы өчен, 1918 елда акгвардиячеләр җәзалап-атып үтерәләр. Икенче уллары – 27 яшьлек Федор – 1939 елда япон самурайларына каршы Халхин-Гол елгасы буенда соңгы тамчы каны тамганчыга кадәр үз-үзен аямыйча сугыша. 1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышы фронтларында Федор, Павел, Василий, хәрби антларына ахыргача тугры калып, ил азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен, бер-бер артлы газиз гомерләрен бирәләр (бу вакытта аларның иң өлкәненә әле 35 яшь тә тулып өлгермәгән була). Иван белән Филиппка үз җилкәләрендә фашист әсирлеге газапларын татырга да, партизанлык итәргә дә туры килә. Төпчек уллары Александр исә (өлкән Степановлар тугызынчы балаларына да беренче малайларының исемен кушалар.– *Ш.М.*), 1943 елның 2 октябрендә дошманнарның контратакасын кире какканда, соңгы гранатасы белән үз-үзен һәм бер төркем фашистларны шартлатып, Днепр елгасы буенда һәлак була. Әлеге гаярь рус егетенә СССР Югары Советы Президиумының 1943 ел 25 октябрь Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән исем бирелә.

Яу кырыннан туып үскән нигезенә бары тик Николай гына әйләнеп кайта. Әмма аңа да озак яшәргә язмаган икән – сугыш җәрәхәтләреннән савыга алмыйча, бераздан ул да дөнья куя...

Музейда Епистиния Федоровнаның, аның рядовой һәм офицер улларының фоторәсемнәре янында шактый вакытлар уйланып басып тордым мин. Хәтеремдә тагын үзем ишеткән-белгән шундый ишле бер гаилә язмышын яңарттым.

## 4. Алексеевлар

Алар турында миңа иң элек күренекле чуваш язучысы Михаил Юхма сөйләгән иде... Чувашстан Республикасының Моргауш районындагы Изедеркино авылында туып үскән сигез бертуган Алексеевлар турында китап язуы турында да әйткән иде ул шул чакта. Соңыннан Михаил Николаевич миңа, биргән вәгъдәсендә торып, «Бертуган Алексеевлар урамы» дигән китабын, култамга салып, бүләк итеп җибәрде. Мәскәүдә «Советская Россия» нәшриятында «Язучы һәм тормыш» сериясендә чыккан иде ул...

Бик яратып, дулкынланып, бер тында укып чыктым мин әлеге китапны. Шуңадырмы бертуган Алексеевларның һәркайсының исеме хәтеремә тирән уелып калды.

Гади бер чуваш крестьяны гаиләсендә Татьяна Николаевна белән Алексей Илларионович сигез егет – сигез бөркет тәрбияләп үстерәләр. Дәһшәтле кырык беренче елда ил өстенә кара афәт булып фашист козгыннары ябырылгач, аларның сигезе дә Ватан-Ана язмышы хәл ителгән алгы сызыкка бер-бер артлы китеп бара.

Күп тә үтми, Алексеевлар йорты тәрәзәсен кара кайгы шакып уза – Иван исемле уллары фашистлар белән тигезсез көрәштә батырларча һәлак була... Днепрны кичкәндә, зур каһарманлык үрнәге күрсәтеп, Григорий исемле икенче уллары үлемсезлеккә атлый. Аңа СССР Югары Советы Президиумының 1943 ел 30 октябрь Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән олы исем бирелә... 1943 елда Егор исемле уллары Житомир янында, легендар Александр Матросов үрнәгендә зур фидакарьлек күрсәтеп, күкрәге белән дошманның ут өермәсен томалый, сугышчан иптәшләренә җиңүгә юл ача... 1944 елда исә яу кырында, мөһим бер биеклекне яулаганда, фашист ядрәсе Павелның гомерен кисә...

Бик авыр кичерәләр мондый олы кайгы-хәсрәтне өлкән Алексеевлар. Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан, күрсәткән батырлыклары өчен Георгий тәреләре белән бүләкләнгән Алексей Илларионовичны да аямый үлем. Карт солдатның йөрәге кинәт ябырылган авырлыкларны күтәрә алмый...

«Инде нишләргә, ничек гомер итәргә?» – дип торганда, Татьяна Николаевна янына фронттан бер-бер артлы уллары Фрол белән Родион кайтып төшәләр. Гәрчә авыр яралы булсалар да, аларны тере килеш күреп, чиксез сөенә Ана ке-

ше. Әмма куанычы озакка бармый аның – ике фронтовик улы да сугыш җәрәхәтләреннән яшьләй үлеп китәләр...

Бүгенге көндә бертуган Алексеевларның тик икесе – Александр белән Михаил гына исән. Сугышның башыннан алып ахырынача кадәр үткән, күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнгән бу ветераннар хәзер Чабаксар шәһәрендә яшиләр...

Шулай да Татьяна Николаевна чагыштырмача бәхетле кеше икән: ул, сугыштан соң исән кайткан уллары кадер-тәрбиясендә тагын 25 ел яшәп, 91 яшендә вафат була...

## 5. Фәттаховлар

Ә менә Татарстан Республикасының Мамадыш районындагы Урта Кирмән авылында гомер кичергән Фатыйха түти белән Фәттах ага Әхмәдиевларга һәм аларның сигез улларына мондый бәхет әз генә дә елмаймый. Гаҗәеп тирән драматизм белән сугарылган моңлы бу кыйссаны һич кенә дә тыныч сөйләп булмый...

...Дөрес, баштарак аларның да тормышлары түгәрәк, күңел күкләре аяз һәм кояшлы булган. Сабан тургайлы булган... Авылның иң булдыклы игенчесе, төзүчесе саналган Фәттах агай белән киндер тукымалар сугу остасы Фатыйха түтиләрнең ишле гаиләсе тирә-юньдә дан тоткан. Берсеннән-берсе уңган уллары белән бергәләп, гаилә башлыгы нарат бүрәнәләрдән күп тәрәзәле, алты почмаклы мәһабәт йорт та, каралты-куралар да торгызып куйган. Имана җирләре мулдан булгач, таза хәлле крестьяннар рәтендә йөргәннәр алар. Хезмәтчеләр тотмаганнар – һәр эшне үзләре кумәкләшеп башкарганнар. Кумәк тормышның матурлыгын белгәнгә, файдасын күргәнгә, чын күңелдән ышанып, колхозга да иң беренчеләрдән керәләр Фәттахныкылар, Фатыйханыкылар. Керәләр һәм бар күңелләрен-осталыкларын биреп эшли дә башлыйлар. Гомумән, һәр яңа башлангычны күтәреп алучылар һәм аны тормышка ашыруда янып-ялкынланып эшләүчеләр, башкаларны киләчәк тормышның тагын да матуррак булачагына инандыручылар, рухландыручылар бертуган Фәттаховлар була да инде. Шәхси үрнәк, үтемле сүз, рухландыргыч җыр – менә аларның төп таяныр көчләре! Тора-бара Фәттах агайны, гаделлеге, булдыклылыгы, тынгы-

сызлыгы өчен, яңа оешкан «Алга» колхозының баш тегермәнчесе итеп билгеләп куялар. Сынатмый ил агасы. Балалары да әти-әниләренең йөзләренә кызыллык китермиләр. Тырыш игенчеләр буларак таныталар алар үзләрен. Шуңа күрә көзен хезмәт көннәренә олавы-олавы белән иң күп ашлыкны да шушы ишле гаиләдәгеләр ала...

Ишле гаилә дигәннән, бераз чигенеш ясап, биредә аларның һәркайсы белән якыннанрак танышып үтәргә безгә Урта Кирмән авылыннан сугыш һәм хезмәт ветераны, авыл мулласы Мияссәр ага Әскәров, атказанган колхозчы Габделхак ага Әхмәтшин, биредәге урта мәктәпнең элеккеге һәм хәзерге директорлары Әлфәт ага Рафиков, Илдар Ибраһимов, мөхтәрәм укытучылардан Гөлфәридә Хәсәнова, Рәшидә Әүхәдиева, Рузилә Гатина, мәктәпнең төбәк тарихы музее җитәкчесе Ринат Хәйруллин, авыл советы башкарма комитетының җитәкчеләре Хөҗҗәт Абдуллин, Галимулла Вәлиуллин, Булат Хәсәнов, Казан шәһәреннән Хан Әхмәтов, Мөгътәсимовлар гаиләсе һәм башка бик күпләр бик теләп ярдәм иттеләр – мөмкинлектән файдаланып, аларга ихлас рәхмәтемне җиткерәсем килә.– *Ш.М.*)

Фатыйха түти белән Фәттах агайның иң олы уллары Исмәгыйль белән Ибраһим яшь Советлар властен саклап калу өчен, гражданнар сугышы фронтларында эчке һәм тышкы дошман белән бугазга-бугаз киләләр. Әлеге дәһшәтле көрәштә Исмәгыйль һәлак була. Ибраһим исә, кайнар канын түгә-түгә, абыйсының тәмамланмый калган эшләрен дәвам итеп, сугышны төгәлләп, туып үскән җирендә яңа тормыш төзергә ашкынып кайта. Бертуганнары Мөгътәсим, Мөхлисулла, Мәгъсүмҗан, Габделбарый, Мисбахетдин, Әгъмәлетдин белән бергәләп, Фәттаховлар данын Байрак кебек горур йөртә ул.

Авылда комсомол ячейкасы төзелгәч, аңа беренчеләрдән булып язылучылар-керүчеләр дә алар – Фәттахныкылар була. Уенын-чынын бергә кушып, «Фәттаховлар ячейкасы» дип тә йөртәләр бу беренче комсомолецларны. Урта Кирмән авыл советы башкарма комитетында сәркатиб булып эшләүче Мисбахетдин бер үк вакытта комсомол ячейкасы җитәкчесе вазифасын да җиренә җиткереп башкара. Соңрак ул, «Комсомол-яшьләр, самолетларга!» дигән чакыруга теләктәшлек белдереп, очучылыкка укырга китә һәм киләчәктә бар тормышын авиациягә бәйли...

Бөек Ватан сугышы башланганчы, гаиләдә 8 баланың икесе – Ибраһим белән Мөгътәсим генә гаилә корып өлгерә. Ибраһим авылда игенчелек белән шөгыльләнүен дәвам итә, ә Мөгътәсим башта Пермьдә, аннары Дон буендагы Ростов шәһәрендә шахтер булып эшли, үзен стахановчы буларак таныта. Хатыны Гамилә үлгәч, Исмәгыйль исемле улын, Нәсимә, Мәрьямбикә, Рәхимә исемле кызларын ияртеп, яңадан туган җиренә – Мамадышка әйләнеп кайта...

Сугыш уты кабынгач, бертуган Фәттаховлар бердәм рәвештә, үзләре теләп, яу кырына китәләр. Кайберләрен, бронь биреп, район хәрби комиссариатыннан кире борып та кайтаралар башта. Әмма алар үз сүзләрендә нык торалар. Мөгътәсим абыйны, мәсәлән, өч мәртәбә бораллар. Ә дүртенче баруында ул барыбер үз теләгенә ирешә...

Бертуган Фәттаховлар төрле фронтларда, төрле гаскәрләр составында дошманга каршы аяусыз көрәштә барысы да батырларча һәлак була. Мисбахетдин исемле очучы туганнары легендар капитан Гастелло үрнәгендә олы фидакарьлек күрсәтә: хәрби заданиене үтәп кайтканда, дошман снаряды тиеп самолетына ут капкач, хәрби очкычын фашистларның җанлы көчләре, техникасы өстенә юнәлтә...

Фәттах агай, бер-бер артлы килгән кара хәбәрләрне күтәрә алмыйча, вакытсыз дөнья куя. Ә Фатыйха түти, зур сабырлык белән, ниндидер бер могҗиза туып, улларының кайсы да булса исән-сау кайтыр дип көтә – күңел түрендәге өмет утын һаман да сүндерми. Әнә бит, төпчек улы Әгъмәлетдин дә: «Кадерле Әти-Әниемә – сагынганда карар өчен!» – дип җибәргән, кулына чәчәк бәйләме тотып төшкән фоторәсеменең артына:

...Иделләрне йөзәмен дә буйлыймын,
Киткән кошлар да бер кайта,
Кайтырмын дип уйлыймын! –

дип, шигъри сүзләр язган – үтә газиз-кадерле кешеләрен юатырга, рухландырырга тырышкан.

– ... Әбиебезнең иң соңгы ышанычы Әгъмәлетдин абый иде,– дип сөйли Фатыйха түтинең оныгы, Ибраһим абыйның кызы Марзия апа Бикмурзина.– Чөнки Җиңү көненнән соң да аннан хатлар килеп торды әле. Ерак Көнчыгышта хезмәт итә иде ул. 1945 елның сентябрь аенда аның белән элемтә өзелде...

Әгъмәлетдин абыйның японнарга каршы сугышканда батырларча һәлак булу хәбәрен очраклы рәвештә генә ишеткән идем. Шулай беркөнне, безнең Урта Кирмән авылында яшәүче Миңсылу түтигә ияреп, күршедәге Чытыр (Су-Елга) авылына – аның яңа гына сугыштан кайткан энесе Мәгъсүмҗан абый Юнысовларга мендек. Менә шул фронтовик үзара сөйләшеп утырганда, безнең Әгъмәлетдин абыйның да исемен зурлап телгә алды: «Якын дуслар идек... Японнар кулындагы мөһим бер биеклекне алганда, аларның ут чәчүче пулеметы авызына күкрәге белән ятып, аны томалап, безнең сугышчыларга җиңүгә юл ачты. Соңыннан, плащ-палаткасына төреп, салютлар биреп, олылап җирләдек үзен...»

Мин моны ишеткәч тә, йөгерепләр диярлек, әбиебез янына кайттым һәм күргән-белгәннәремне чәчми-түкми аңа сөйләп бирдем. Гаҗәеп сабыр булган әбиемнең күзләреннән мөлдерәп берничә бөртек яшь тамды. Соңгы яшьләре...

Икенче көнне әбием, Мәгъсүмҗан абый янына менәр өчен, иртән-иртүк яхшылап әзерләнә башлады. Саклап тоткан әйберләрен барлап, тәмле ризыклар пешерде, улларына дип атап җыйган чикләвекләрен янчыкка тутырды. Һәм бөрчекле ак күлмәген киеп, ак шәльяулыгын ябып, мине дә үзенә ияртеп, җәһәт-җәһәт атлап, Чытырга юл тотты.

– ...Улым, син миңа Әгъмәлетдинем кебек, шуңа күрә һәммәсен яшермичә сөйлә, мин инде карт кеше – барысын да күтәрәм,– диде әбием Мәгъсүмҗан абыйга...

Фронтовик дусты ялындырмады...

Ана төпчек улының соңгы батырлыгы шаһиты булган шул якташ солдат сөйләгәннәрне, бар дөньясын онытып, сәгатьләр буе тыңлап утырды. Күңелен борчыган күп кенә сорауларга тулы җаваплар алса да, тиз генә Мәгъсүмҗан абый яныннан китәсе килмәде аның... Авылыбызга без бары тик кичкырын гына кайттык. Әбиебез, үзенең аерылмас юлдашы булган өрәңге таягына таянып, бик әкрен генә, үзалдына уйланып һәм, вакыт-вакыт газиз улларының исемнәрен берәм-берәм телгә ала-ала: «Кайларда ятасыз сез хәзер, балакайларым?» – дип өзгәләнеп кайтты.

Сабыр савытлары тәмам тулып ташкан иде әбекәебезнең... Шуннан соң урын өстенә егылды ул. Мәрхәмәтле кешеләр бар бит әле дөньяда! – шундый авыр чакта аны ялгыз калдырмадылар. Бигрәк тә ирле-хатынлы Хәбибулла абзый белән Хәлимә апа Хәмидуллиннарны һич онытасыбыз юк!

Әбиебезне алар бөтенләйгә үз тәрбияләренә алып, картлык көнендә аңа хәлләреннән килгәнчә кадер-хөрмәт күрсәттеләр. Нәгыймә апа Әхтәмова, Дәрия апа Фатыйхова, Шәмсеямал апа Хафизова кебек өлкән яшьтәге авылдашларым әлеге эшчән, ярдәмчел, киң күңелле гаилә хакында хәзер дә исләре китеп сөйлиләр.

1945 елның ап-ак карлар яуган сигезенче (!) декабрендә әбиебезне соңгы юлга озатучылар да шул изге җаннар булды (урыннары оҗмахтадыр, шәт!). Балалары хакында көне-төне уйлап, авыр кайгы-хәсрәттән гомере киселгәндә, актык сулышларын алганда, аеруча өзгәләнде кадерле кешебез:

– ...Улларымны күрермен, дип өметләнгән идем... Кайтмадылар инде... Ләгънәт кенә төшсен инде бу йөзе кара сугышка, аны башлаучыларга!.. Минем кебек, чәчләре вакытсыз агарган аналарның... улларым кебек, чәчәктәй гомерләре иртә өзелгән балаларның... чиксез нәфрәте эзләп тапсын аларны! Эзләп тапсын... һәм без күргән-кичергәннәр өчен... үзләренә әз генә дә рәхәт күрсәтмәсен!.. Аллаһе Тәгалә аларга тиешле җәзаларын бирсен!.. Ә сез... гөлкәйләрем... сау-сәламәт булып... бәхетле-имин тормышта яшәгез!.. Миннән... хәер-фатиха сезгә!..

Әнә шундый сүзләр белән фани дөньядан мәңгелеккә күчте Әбиебез. Колак төбендә исә аның соңгы вакытта хәлсез тавышы белән еш кына көйли торган гыйбрәтле-моңлы җыры калды:

Иртән торып тышка чыксам,
Ай түгәрәк шикелле...
Үзем үлсәм, җаным кайтыр –
Ак күбәләк шикелле!..

Шуңадырмы, ак күбәләк күрсәм, җанымның бар тынычлыгы югала хәзер. Безнең хәл-әхвәлне белергә дип, кайгыртучан, ак күңелле әбиебез кайткандыр кебек тоела...

## 6. Җыр дәвам итә!..

Ә шулай да Фәттаховларның гомер җыры дәвам итә! Ни әйтсәң дә, нәсел тамырлары тирәнгә киткән аларның. Өлкән Фәттаховларга алмашка яшь буын дөньяга килгән. Ибраһим абзый улы Габденур... Габденур абый уллары Мисбахетдин (аңа бу исемне сугышта үлгән очучы абыйлары истәлегенә кушканнар.– *Ш.М.*) һәм Илшат... Илшат армия саф-

ларында хезмәт итеп кайтты. Озак еллар чик буенда һәм Эчке эшләр министрлыгы частьларында хезмәт иткән этисе Габденурга лаеклы алмаш ул. Үзен хәрби һәм сәяси хәзерлек отличнигы итеп таныткан... Ибраһим абзый кызы Марзия апа белән Гыйлемхан абый Бикмурзиннарның Хатыйп исемле улларына карата да шундый ук сүзләрне әйтәсе килә. Җырдагыча итеп әйткәндә, «...шинелен салса да, солдат гадәте калган» аңарда. Исемнәре мактаулылар рәтендә йөргән Мисбахетдин, Илшат кебек, Хатыйп та туган авылында эшкә калды, өйләнеп җибәрде. Хатыны Зөлфәрия белән Азат, Ирек исемле ике малай үстерәләр алар... Гомумән алганда, өлкән Бикмурзиннарның хәзер җиде балаларыннан (6 кыз, бер егет!) 14 оныклары бар! Нәсел агачы, әнә шулай, мәңге яшел, мәңге нур сибүдә!..

Мөгътәсим абзыйның Исмәгыйль исемле улы да Фәттаховлар нәселенә кер-тап төшермәгән. Озак еллар дәвамында Казандагы Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы заводларның берсендә тырышып эшләгән, үз һөнәренең чын остасы булып әверелгән. Югары разрядлы слесарь-җыючы, хезмәттәге батырлыгы-фидакарьлеге өчен, берничә мәртәбә хөкүмәтебез тарафыннан медальләр белән бүләкләнгән, күп тапкырлар «Социалистик ярышта җиңүче», «Бишьеллык ударнигы» дигән мактаулы исемнәргә лаек булган.

Ни кызганыч, Исмәгыйль абый белән күрешергә, сөйләшергә өлгерә алмый калдым – 1981 елда гүр иясе булган ул. Хәзер аның эшләрен ике кызы дәвам итә...

Исмәгыйль абыйның шәхси документлары белән танышканда, кызыклы бер фактка тап булдым. Аларның һәркайсында «Мөгътәсимов Исмәгыйль... Фәттах улы» дип язылган. Ничек инде «Фәттах улы»? Аның әтисе бит Мөгътәсим булган – туу турында таныклыгы да шуны раслый. Соңыннан ачыкланганча, Исмәгыйль абый Фәттах исемле бабасының һәм гражданнар сугышында һәлак булган адаш абыйсының (әтисенең бертуганы) якты истәлекләрен мәңгеләштерү өчен, аларның үзенчәлекле дәвамы булу өчен, махсус шулай эшләгән. Чыннан да, әтисе аңа үзенең яраткан бертуганы Исмәгыйль исемен кушкан икән, нигә дип ул да сөекле бабасының исемен тарихта калдырмаска тиеш?! Менә шулай итеп документларда «Мөгътәсимов Исмәгыйль Фәттах улы» барлыкка килә... Беренче Исмәгыйль 1895 елда туган, икенчесе – 1929 елда... Әнә шулай, бу нәселдәгеләрнең гаҗәеп гоме-

ре, сүнмичә-сүрелмичә, яңа төскә-рәвешкә кереп, еллар күкрәгендә балкып дәвам итә...

Нәсел дигәннән, безгә Мөгътәсим абыйның Мамадыш районындагы Югары Ушмы авылында яшәгән Нәсимә исемле кызы белән дә берничә мәртәбә очрашып сөйләшергә туры килде. Әйткәнебезчә, алар өч кыз туган булганнар. Әти-әниләре үлгәч, Мәрьямбикә белән Рәхимә исемле туганнарын балалар йортына тапшырганнар – хәзергә аларның язмышлары билгесез. Нәсимә апа аларны һәрчак сагынып яшәде. Әмма күрешү бәхетенә ирешә алмады. Инде ул – гүр иясе. Әнисе яшәгән нигездә хәзер улы Мидхәт Нургалимов гаиләсе белән гомер кичерә. Заманында ул Ерак Көнчыгыштагы хәрби авиачастьларның берсендә хезмәт итте, МИ-24 вертолетында очты. Исеме частьта гел мактаулылар рәтендә йөрде аның. Нәсимә апа улы яулаган бүләкләр белән гел горурланып яшәде...

Тагын шунысын да әйтик: Мидхәт өлкән туганы Әгъмәлетдин Фәттаховның гомер җыры өзелгән җирдә хәрби бурычын үтәде. Заманында шул героик җырны күтәреп алып, аны тиешенчә яңгырата алды ул. Кем белә, бәлкем, киләчәктә бирегә аның уллары, оныклары – Фәттаховлар нәселенә дан-мәдхия җырлаучы яңа буын вәкилләре килер. Әгъмәлетдин абыйларының тынгысыз рухы чакырып китерер бирегә аларны. Сугышчы итеп түгел, дәүләтләрне бер-берсенә якынайтучы, дуслаштыручы, бөек Илче итеп!

## 7. Батырлыкка – һәйкәл!..

*«Аналар һәм балалар... Аларның илаһи каһарманлыгын китапларда, кинофильмнарда, һәйкәлләрдә гәүдәләндерәсе, махсус музейларын оештырасы иде. Дөрес, бу юнәлештә кайбер эшләр башкарыла, анысын инкарь итеп булмый. Әйтик, илкүләм билгеле батырларга – ун бертуган Лысенколарга (Черкасс өлкәсе), тугыз бертуган Степановларга да (Краснодар крае), сигез бертуган Алексеевларга да (Чувашстан) туган җирләрендә һәйкәлләр куелган. Аналарына да, балаларына да... Фәттаховлар гаиләсе дә алардан бер дә ким түгел! Гамебез, хәтер көчебез җитәрме моңа, милли горурлыгыбыз калкып чыгармы? Ә теләк бик зурдан. Җиңү бәйрәменең чираттагы еллыгын билгеләп үткәндә яисә Хәтер һәм Кайгы көнендә (22 июнь) шул мәһабәт һәйкәл Урта Кир-*

*мән авылыннан Казан–Чаллы трактына чыгучы олы юл чатында торып бассын иде. Сигез солдат һәм Ана образлары бер Фәттаховлар гаиләсен генә түгел, ә яу кырында мәңгелеккә ятып калган меңләгән каһарман якташларыбызның һәм гаҗәеп сабыр, эшчән, мәрхәмәтле Аналарыбызның үлемсез Батырлыгын үзләренә берләштерер, калку итеп гәүдәләндерер иде...*

*Форсаттан файдаланып, республика-район җитәкчеләренә киң күңелле, ярдәмчел ватандашларыма мөрәҗәгать итәсем килә:*

*– Фатыйха түти белән аның сигез улы истәлеген мәңгеләштерү – бик тә кирәкле олуг бер эштер! Алар өчен «табыйк шундый бер җыр» – салыйк бер мәһабәт һәйкәл! Бу – исәннәргә кирәк! Үткәнен оныткан халыкның киләчәге дә юк... Уйлашыйк, киңәшләшик! Мөстәкыйльлегебез идеясе моннан отачак кына!*

*Һәйкәлнең проектын эшләү буенча иҗади бәйге (конкурс) игълан итү шул юнәлештә әһәмиятле бер адым булыр иде. Гомумән, бу кирәкле вә изге эштә Ватандар йөрәкле, милләтпәрвәр һәр кеше катнашсын, үзенең уйлары, фикерләре белән уртаклашсын иде. Чыннан да, әлеге һәйкәлне сез нинди итеп күрергә телисез? Бәлкем, ул язмабызның төп алиһәсе булган Анага багышланып, аның итәгенә сугышта һәлак булган сигез улының исемнәре дә язылыр. Яисә һәйкәл кырыена шул ук санда исемле агачлар да утыртылыр? Һәйкәлне, бәлкем, олы юл чатына түгел, ә авыл зираты белән мәчет янәшәсендәге иман нуры бөркелеп торган иркен мәйданга куяргадыр? Ни әйтсәң дә, Фатыйха түти белән Фәттах агайның рухларын да бик нык сөендерер иде әлеге рухи якынлык – туган туфрак җылысы! Кыскасы, биредә уйланырга урын бар...*

*...Кулыма заманында Фатыйха түти тукыган сигез бизәкле Сөлгене алам. Тирәнтен дулкынланып алам. Сигез бизәк – сигез улы төсе. Килер бер көн: Ананың олылыгын, күңеле пакьлеген, йөзе аклыгын, якты өметен-хыялларын гәүдәләндергән әлеге Сөлге һәйкәл ачыласы иртәдә биек колгада Байрак булып җилфердәр һәм Урта Кирмән авылында оештырылачак «Бертуган Фәттаховлар музее»нда яисә Мамадыш үзәгендәге төбәк тарихы музеенда иң түрдә кадерле ядкарь булып эленеп торыр. Тирәнтен ышанам: килер ул көн, тиздән килер!..»*

Әнә шулай дип язган идем мин республикабызда чыгучы иң күптиражлы «Татарстан яшьләре» газетасына...

## 8. Чыкты Кояш – сипте нурын!..

...Ниһаять, килде ул көн! 1997 елның 22 июне иртәсендә Мамадыш районы үзәгендә Фатыйха түти Әхмәдиевага һәм, аның кебек, балаларын яу кырына озатып та көтеп ала алмаган барлык милләт аналарына, олы кайгыларын уртаклашып, аларга тирән хөрмәт билгесе итеп, ап-ак таштан мәһабәт һәйкәл куелды! Символик һәйкәл!..

...Биредә, бераз чигенеш ясап, һәйкәлне эшләтү тарихына да кыскача тукталып үтик әле. Безнең Фәттаховлар гаиләсенә кагылышлы язмабыз Мамадыш районы хакимиятенең яңа башлыгы – Татарстан халык депутаты Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин кулына килеп эләккәч, ул аны эчке бер тетрәнү белән кат-кат укып чыга да җитди карарга килә: Фатыйха түтигә һәйкәлне, һичшиксез, эшләтергә кирәк!.. Һәм тиз арада! Шундый олы хезмәтне тиешле югарылыкта башкара алучы яхшы скульпторны да табарга кирәк!.. Район җитәкчесенең үтенечен безгә – Казанда яшәүче мамадышлыларның якташлык җәмгыяте җитәкчеләренә – хакимият башлыгы урынбасары Шамил Нурулла улы Хәсәнов җиткерде. Җәмгыятьнең март аенда булган киңәйтелгән утырышында әлеге мөһим мәсьәлә һәрьяклап җентекләп тикшерелде һәм зур яклау тапты. Скульпторлар арасыннан үзенең күпсанлы монументаль хезмәтләре, иҗади фикерләү осталыгы белән танылган Альфрет Хәйрулла улы Абдрашитовны сайлап алдык. Заманында ул татарлар арасыннан иң беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Батыршинга, легендар очучы Мәгүбә Сыртлановага, каһарман шагыйрь Нух Идрисовка, полк улы – Социалистик Хезмәт Герое Камил Шакировка, күренекле язучы Газиз Кашшаф-Үзилегә һәм тагын бик күпләргә һәйкәлләр койган һәм куйган кеше!

Бу юлы да Әлфәрит оста уллары белән иң элек һәйкәл куеласы паркны яхшылап карап кайтты. Аннары, районның талантлы яшь архитекторы Рамил Минһаҗ улы Миннеханов белән бергә, шул парктагы «Хәтер мәйданы»н халык күңелен җәлеп итәрлек өр-яңа төсмерләр-символлар белән баету чараларын күрделәр алар. Район хакимияте һәр яңа башлангычны күтәреп алып, аларны тормышка ашыру өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырды. Мәйдан-паркны үзгәртеп коруда ПМК-88 төзү оешмасы һәм шәһәр коммуналь хуҗалыгы эшчәннәре (җитәкчеләре –Фәргать Рәфгать улы Гаянов,

Салих Гасыйм улы Сәлахов иптәшләр) зур тырышлык-фидакарьлек үрнәкләре күрсәттеләр. Нәтиҗәдә шәһәрнең үзәге танымаслык булып үзгәрде, матурайды. Паркны яңа төр агачлар белән баетуда Мамадыш урман хуҗалыгы директоры Мансур Салих улы Хәсәнов һәм булдыклы баш урманчысы Илдус Газизҗан улы Мөхәммәтшин дә (һәр икесе дә – Татарстан Республикасының атказанган урманчылары!) үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр. Шәһәр башлыгы Илдус Габдулла улы Әхмәтов исә биредә һәр эшнең барышын даими игътибар үзәгендә тотты, өзеклеккә юл куймады...

Скульпторлар да үз сүзләрендә нык тордылар. 20 июнь көнне алар, Казаннан Ана һәйкәлен Мамадышка алып кайтып, 21 июньдә аны «Хәтер мәйданы»на бастырып та куйдылар.

...22 июнь иртәсендә – Хәтер һәм кайгы көнендә – әлеге һәйкәл янына районның төрле төбәкләреннән йөзләгән-меңләгән кеше җыелды. Алар арасында сугыш утларын кичкән ветераннар да, чал чәчле аналар да, тол хатыннар да бихисап иде...

Иртәнге сәгать 10. Ватанны саклаучыларны искә алу көненә багышланган җыен ачык дип игълан ителә. Без район хакимияте башлыгы Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин, Фатыйха түти Әхмәдиеваның оныгы – Марзия апа Бикмурзина, сугыш һәм хезмәт ветераннарыннан Любовь Ивановна Штягина, Дмитрий Дмитриевич Манунов белән берлектә, Ана һәйкәлендәге ак җәймәне сак кына җиргә төшерәбез...

Менә шушы мизгелдән башлап, Фатыйха түти Әхмәдиеваның икенче гомере – мәңгелек гомере (яңадан туу!) башланды инде. Шагыйрь җанлы скульптор Әлфәрит оста Ана образын бик яратып иҗат иткән. Сугышта сигез улын югалтса да, горурлыгын һәм сабырлыгын, матурлыгын һәм батырлыгын җуймаган мәгърур Ана безнең каршыда, хаҗга барырга җыенгандай, ап-ак киемнән басып тора. (Билгеле булганча, ак төс – салават күперендәге җиде төснең җыелмасы ул! Ананың да күңел төсмерләре, рухи халәте шундый ук төсләрдән тора: ал төс – мәхәббәт төсе, зәңгәр төс – өмет төсе, сары төс– сагыш төсе, кара төс – кайгы төсе, яшел төс – яшәү төсе!..)

Карашы еракка – сигезенче улы, соңгы өмете – Әгъмәлетдине ятып калган көнчыгышка төбәлгән аның. Ана инде улының ничек һәлак булуы турында аның җан дусты, полкташы Мәгъсүмҗан Юнысов авызыннан ишеткән. Авыр сагышлардан сыгылып төшмәгән горур ана сул кулы белән

соңгы улының ядрәләр тишкән кызыл йолдызлы пилоткасын (аны яу кырыннан Мәгъсүмҗан солдат алып кайткан була) күкрәгенә-йөрәгенә кысып тора. (Әгәр мөмкин булса, улларын-газизләрен мәрхәмәтсез үлем тырнагыннан йолып калу өчен, шул ядрәләр астына, үзе теләп, сигез мәртәбә утка керергә дә риза булыр иде Ана!) Уң кулында – болыннан яңа гына өзелгән саф чәчкәләр... (Хыялында гына булса да, улларының сугыш яланнары буйлап сибелгән биниһая кадерле каберләренә туган як гөлләрен куярга теләгән ул!)

Ананың Су-Елга болыны буйлап Урта Кирмәнгә кайтып килеше сурәтләнә һәйкәлдә. Чөеп бәйләгән чигүле ак яулыгын, озын ак күлмәге итәкләрен җилфердәтеп, ак күбәләк кебек оча ул болын түреннән. Киң күңеллеген, мәрхәмәтлеген чагылдырып, ачык китап рәвешендә ике якка урталай аерып тараган ап-ак чәчләре, колакларындагы асыл алкалары, иман билгесен – дисбене хәтерләткән муенсасы үзенә бик тә килешеп тора. Әмма Ана инде бу Җиһанны оныткан. Гәрчә җыйнак гәүдәсе әлегә фани дөньяда булса да, тынгысыз олы җаны инде күптәннән балалары янында – оҗмах түрендә...

Һәйкәл янындагы ак мәрмәр ташка Ананың (Фатыйха түтинең) алтын хәрефләр белән уеп язылган утлы сүзләре, гайрәтле-таләпчән ялкын телләре кебек, бәгырьләрне кат-кат көйдереп-телеп ала:

...Улларым сугыштан кайтмады,
Кайтты тик: «Көт!» – дигән хатлары...
Өзелеп көтәм мин һәр таңны –
Улларым әйләнеп кайтканны!!!

Яу кырларында шәһит киткән сигез улының уртак җавабы да бар әлеге мәрмәр ташта:

...Чыгар Кояш, сибәр нурын –
Бездән сәлам шул булыр!

Могҗиза дисәң, могҗиза! – Анага һәм аның каһарман улларына һәйкәл ачылган сәгатьләрдә, моңарчы ике көн буе берөзлексез сибәләп торган яңгыр болытларын таратып (Табигать-Ана да, үзенең газиз балаларын юксынып, шулай тын гына үкседе, күрәсең!), күк йөзендә кояш балкыды һәм, Хәтер җыены тәгәлләнгәнче, халыкны шифалы җылы нурлары белән коендырып торды...

Җыенда бик күп кешеләр чыгыш ясады. Шулар арасыннан иң тәэсирләндергәне, мөгаен, атаклы җырчы һәм таль-

янчы – Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты Фән Вәлиәхмәтовның тальян гармунда үзе уйнап-җырлап «Герман көе»н башкаруы булгандыр. Яу кырына киткән бертуган Фәттаховлар образын гәүдәләндереп җырлады ул әлеге үзәк өзгеч җырны:

...Биек икән тавыгыз,
Куе икән талыгыз...
Без китәбез, туганнарым,–
Бәхиллләшеп калыгыз...

Кояш чыга әйләнеп,
Ак болытка бәйләнеп...
Җиңү белән, сау-сәламәт
Кайтсак иде әйләнеп!

Юк шул, берсе дә әйләнеп кайта алмый туган нигезгә әлеге фидакарь җаннарның. Бары тик кара мөһерле кайгы кәгазьләре генә кайта бер-бер артлы...

Җыен барышында Фатыйха түти образын танылган табибә, һәвәскәр җырчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре – Арташ авылы кызы Сәҗидә Мостафина-Әхмәтгалиева (бертуган сеңелем.– *Ш.М.*) гәүдәләндерде. Аның башкаруындагы «Син кайтмадың» җыры (Сәхаб Урайский шигыре, Мансур Мозаффаров көе) беркемне дә битараф калдырмады, күзләрне һәм күңелләрне мөлдерәмә моң белән тутырды:

...Сандугачлар килде, аккош кайтты,
Син кайтмадың киткән җиреңнән.
Аккош китәр урман күлләреннән,
Син китмәссең минем күңелдән...

Дошман явын тар-мар иткән чакта,
Йөрәгеңнән кайнар кан тамды.
Үзең үлсәң, матур исемең калды,
Киң Ватанга даның таралды...

Гүяки Ана бу җырны үзенең һәр улына – бәгырь җимешләренә атап җырлый иде...

Укучыбыз ялгышмасын: бу көнне Хәтер җыены Фатыйха түти Әхмәдиева белән аның сигез улына гына багышлап үткәрелмәде. Районнан Бөек Ватан сугышына китеп, яу кырларында мәңгелеккә ятып калган солдат-офицерлардан 7 меңгә якын кешене тирән юксыну хисләре белән искә алдылар чыгыш ясаучылар. Алар арасында Татарстанның иң берен-

че Советлар Союзы Герое Гафият Ярмөхәммәт улы Нигъмәтуллинның кызы – матбугат ветераны Гөлия ханым Мөхәммәтҗанова да бар иде.

– ...Башка бик күпләр кебек, безгә дә әтиебезнең сугыштан әйләнеп кайтуын күрү бәхете насыйп булмады,– диде ул, авыр көрсенеп.– Шунысы аеруча аянычлы: 1945 елда, Җиңү таңы аткан бер вакытта, 8 майда (!) һәлак булды безнең кадерле-газиз кешебез. Гомер буе без аны сагыныпюксынып яшәдек. Инде менә хәзер, Аллага шөкер, районыбыз хакимияте җитәкчеләре тырышлыгы белән, әтиебез тиздән бирегә, шушы мәйданга, мәһабәт һәйкәл булып кайтып басачак! Бер аңа гына түгел, районыбыздан чыккан тагын өч батырга – Советлар Союзы Геройлары Иван Тихонович Максимовка, Михаил Кириллович Москвинга, Михаил Андреевич Просвирнинга да куелачак шундый бюст-һәйкәлләр. Ана һәйкәле янәшәсендә, аның уллары кебек, үзләренең лаеклы урыннарын алачаклар әлеге каһарманнар... Район җитәкчеләренең сугышта үлгәннәргә дә, исән кайткannарга да бер үк дәрәҗәдә игътибарлы-ихтирамлы булулары ифрат сөендерде безне – ихлас күңелдән рәхмәт аларга!..

Чыгыш ясаучылардан Казан кунагы – «Компрессормаш» заводының элеккеге генераль директоры, техник фәннәр докторы, академик Әхмәт Мөхетдин улы Галиев, Мамадыш районы хәрби комиссары – полковник Николай Николаевич Егоров, район хакимияте башлыгы урынбасары Шамил Нурулла улы Хәсәнов, Фатыйха түти Әхмәдиеваның оныгы – Марзия апа Бикмурзинаның да җыелган халыкка әйтер сүзләре тирән мәгънәле – күңелләрне кузгатырлык, хәтерләрне уятырлык иде.

– ... Безнең Фатыйха әбиебез һәйкәле янәшәсендәге ак мәрмәр ташта яу кырында шәһит киткән сигез абыемның да алтын хәрефләр белән язылган исемнәрен күрү мине аеруча тетрәндерде,– диде Марзия апа.– Гүяки аларның җаннары бүген, ерак юллар-еллар кичеп, әниләре янына кайтып, мәңге аерылмаслык булып, аңа сарылдылар! Шушы гаҗәеп вакыйганың истәлеге итеп, мин бүген, әлеге җыенда катнашучы барлык авылдашларым, туганнарым, балаларым, оныкларым исеменнән, район музеена Фатыйха әбиебезнең улларына багышлап тукыган-чиккән сигез бизәкле Сөлгесен бүләк итәм. Шунысын да искәртим: Әбиебезне гүргә иңдергән үтә кадерле Сөлге дә әле ул!

Сөлге димәктән, күренекле шагыйрә – Татарстан Җөмһүриятенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гөлшат ханым Зәйнашева, Анага һәм аның сигез улына багышлап, махсус баллада да иҗат итте. Шуннан бер-ике өзек китереп үтәсебез килә:

...Улларына ядкарь итеп Ана
Сөлге чиккән – сигез бизәкле.
Җаны бар шикелле ул Сөлгенең –
Бизәкләре өзә үзәкне...

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . ..
Җидегән йолдыз нигә күзләремә
Сигез йолдыз булып күренә?..
Йолдыз булып кайткандыр батырлар
Туган якның зәңгәр күгенә!..

Күренекле якташларыбыздан – танылган шагыйрь һәм композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхмәт Гадел исә аңа көй язды. Казан дәүләт педагогика университетының музыка факультеты доценты, Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев башкаруында аеруча тәэсирле яңгырый ул җыр!

Әнә шулай, аналар һәм балалар батырлыгы мәңге көйләп туялмаслык моңлы бер җыр булып, телләрдән телләргә, күңелләрдән күңелләргә күчеп йөри.

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 55 еллыгына багышлап, 2000 елның 8 маенда Татарстан Дәүләт Зур концерт залында уздырылган тантаналы утырышта ясаган чыгышында Җөмһүриятебез Илбашы М.Ш.Шәймиев Фатыйха апа кебек зур хәрефләр белән язылырга тиешле Аналарның, тылдагы «шинельсез солдатлар»ның рухи батырлыгын, күңелләренең эчке матурлыгын хәтерләребездә тагын бер мәртәбә яңартты.

*«...Һәркемгә дә туган йортына әйләнеп кайту насыйп булмады,– диде ул.– Күбәүләр, бик күбәүләр сугыш кырларында ятып калдылар. Бөтендөнья сугышының Кешелек дөньясына ничә миллиардка төшүен санарга мөмкин. Ләкин аналарның, тол хатыннарның йөрәкләрендә күпме төзәлмәгән яралар калуын санап бетереп буламы соң?*

*Авыр җимереклек, коллективлашу елларында сигез егет үстергән һәм сугыштан шуларның берсен дә көтеп ала алмаган Ананы күз алдына китерегез әле. Аның олы улы Исмәгыйль, әле тормышка чынлап торып аяк басарга да өлгермичә, гражданнар сугышында ук һәлак була. Улларының ниба-*

*ры икесе – Ибраһим белән Мөгътәсим генә Бөек Ватан сугышы башланганчы өйләнеп өлгерәләр. Әмма өлкәннәре дә, яшьләре дә үзләре теләп фронтка китәләр һәм шунда батырларча һәлак булалар. Өстәвенә Мисбахетдин Николай Гастелло батырлыгын кабатлый, Әгъмәлетдин исә, пулемет амбразурасын күкрәге белән каплап, Япония белән сугышның соңгы көнендә һәлак була... Боларның барысына да түзү өчен ана йөрәге нинди бетмәс-төкәнмәс көчкә ия булырга тиеш соң? Әмма Фатыйха апа Әхмәдиева, үзенә язган барлык газапларны кичереп, җитмәсә әле сугыш елларында үзенең бердәнбер кызын, аннары ирен дә югалтып, рухы сынмаган хәлдә кала алды... Мамадышлыларның шәһәр паркында аның хөрмәтенә Ана һәйкәлен торгызулары тикмәгә генә түгел...»*

Әлеге Ана һәйкәле турында хәзер башка мәмләкәтләрдә, кыйтгаларда яшәүчеләр дә яхшы беләләр. Заманында Фатыйха түти яшәгән төбәктә туып үскән күренекле журналист һәм язучы Нәзифә ханым Кәримова, аның хакындагы гыйбрәтле-дулкынландыргыч кыйссаны «Азатлык» радиосы аша киң җиһанга – күпсанлы тыңлаучыларга җиткерде инде. Ананың үлмәс рухы хәзер, әнә шулай, Ак күгәрчен кебек, тынычлык теләп, Җир шарын иңләп оча...

## «ЯШИСЕ КИЛӘ!..»

*(Яшь язучы Мөхәммәт Әхмәтгалиевның сугыш чоры көндәлекләре һәм фронт хатлары)*

Шагыйрь күңеле – сизгер барометр кебек бит ул! Никадәр генә оптимист булса да, Ватан солдаты – талантлы яшь язучы Мөхәммәт Әхмәтгалиев та сугыш дигән җәһәннәм уты эченнән исән-сау чыгачагына бик үк ышанып җитмәгәндер. Бигрәк тә, күз алдында якын дуслары-көрәштәшләре дошман ядрәләреннән, снаряд-мина кыйпылчыкларыннан кырылып торганда...

*«...Кичә көне буе снарядлар, миналар астында чокырларда яттык. Берничә кешене үтерде. Осколкалар белән яралanучылар күп,–* дип яза ул 1943 елның августында әнисе Өммегөлсем Кулиевага җибәргән иң соңгы хатларының берсендә.– *Мөгаен, бүген кич без дә сугышка керербез... Шулай, әнкәй, язганын күрербез... Менә акрын гына Кояш бата... Ул җылы Кояш минем өчен яңадан иртәгә чыгармы?*

*Белмим. Вакыт таба алсам, иртәгә сугыштан алган тәэсирләрем турында язармын...»*

27 августта язылган ошбу хатның газизләренә ахыргы хәбәре-сәламе булырын, мөгаен, Мөхәммәт үзе дә сизенгәндер. 28 августта инде ул – тынгысыз-ярсу йөрәгендә фашистларга каршы чиксез нәфрәт, якыннарына карата тиңсез мәхәббәт ялкыннары дөрләгән автоматчы егет – Калинин фронтындагы 83 нче укчы корпусның 124 нче бригадасы сугышчылары белән бергәләп, Смоленск өлкәсенең Мышково авылы янында дошманга каршы хәлиткеч һөҗүмгә күтәрелә. Һәм шунда, яу кырында, 23 яшьлек шагыйрь егет Үлемсезлеккә атлый. Күкрәге белән каплап, дошман ядрәләреннән рота командирын саклап кала ул. Яшендәй якты-кыска гомеренең соңгы минутларында да, үзе турында түгел, өлкән иптәше турында кайгырта Мөхәммәт...

* * *

Хәзер исә әлеге каһарман һәм аның эти-энисе, нәселнәсәбе белән якыннанрак танышып үтик. Мөхәммәт батырның бертуганнары: энесе – техник фәннәр докторы, профессор Ильяс әфәнде Әхмәтгалиев (1927–1993) һәм сеңлесе – озак еллар дәвамында Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләгән, республикабызның Журналистлар берлеге әгъзасы Мәрьям ханым Әхмәтгалиева хатирәләрендә аларның һәркайсы ачык чагылыш тапкан:

«...Этиебез – Ибраһим Җиһангәрәй улы Әхмәтгалиев (1888–1932), бик яшьләй ятим калып, 12 яшеннән байларга хезмәтче булып ялланган. Үтә тырышлыгы, булдыклылыгы, җитезлеге, тапкырлыгы нәтиҗәсендә, ул приказчик дәрәҗәсенә күтәрелә, Яңа бистәдә шаулап торган алма бакчасы уртасында үз йортын булдыра, 2 сыер асрый. Әмма бәхетле тормышлары 1932 елда җимерелә. Этиебез, бер атна урын өстендә ятып, үпкә шешеннән 44 яшендә вафат була. 38 яшенә дә җитмәгән эниебез – Өммегөлсем Габделвахит кызы Кулиева (1895–1984) 3 бала, кияүгә чыкмаган Зәйнәп исемле бертуган сеңелесе белән язмыш кочагында кала. Җитмәсә, этисе дә юк бит янәшәсендә – утлар-сулар кичкән, заманында Ишморатов дигән байларда приказчик булып эшләгән Габделвахит Йосыф улы да 1924 елда ук инде гүр иясе була... Шуннан соң инде эниебез, тормышның очын

очка ялгау өчен, тегү фабрикасына эшкә урнаша. Тора-бара абыебыз Мөхәммәт тә аның кул астына керә башлый. Укулар тәмамланып, җәйге каникулга туктау белән, күрше-тирәдә яшәүчеләрнең утыннарын кисеп-ярып, өеп куюда дисеңме, баржадан йөк бушатырга Бакалтайга йөрү дисеңме, өй эшләрендә булышу дисеңме – һәммәсен дә ялт иттереп куяр иде Мөхәммәт абыебыз. Без, яшьрәкләр исә, һәрвакыт аның кебек булырга тырыша идек.

Әниебезнең бертуган абыйсы – күренекле журналист, җырчы һәм җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Кулиев (1885–1937) һәм аның улы – танылган инженер, Казан һәм Уфа радиолары эшчәнлегенә нигез салучы, радио буенча татар телендә чыккан беренче китапның авторы Салих Кулиев (1908–1939), «халык дошманы» буларак, кулга алынып атылганчы, безнең гаиләгә хәйран ярдәм итеп тордылар. Алар «таш капчык»ка озатылгач та, әнинең әнисен – Латыйфа абыстайны тизрәк үзебезгә алу хәстәрен күрдек. Әбиебез газиз балаларының 1957 елда тулысынча аклануларын, ни кызганыч, ишетә-күрә алмады – дистрофиядән 1942 елның 1 маенда вафат булды...

Горурланып әйтә алабыз: Ибраһим һәм Салих Кулиевлар – Татарстан тарихында һәм, әлбәттә инде, абыебызның үсүендә-формалашуында якты эз калдырган затлы-ялкынлы шәхесләрдән иделәр...

Мөхәммәт абыебыз дигәннән, ул 1920 елның 20 гыйнварында Яңа бистәдә дөньяга килгән. Туу турындагы таныклыгына ни сәбәптәндер «туган көне – 21 февраль» дип язып куйганнар...

Яңа бистәдәге 13 нче татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, абыебыз 1938–1941 елларда Казан дәүләт педагогия институтының биология факультетында белем алды. Бөек Ватан сугышы башлангач, студент иптәшләре белән бергә, Кайбыч районында окоплар, танкка каршы траншеяләр казуда катнашты. Аннары Ленинградтан Казанга күчеп килгән хәрби заводларның берсендә станокчы булып эшли башлады...

Абыебызны сугышка 1942 елның 22 маенда – Калинин исемендәге шул заводта эшләгән җиреннән алдылар. Аны фронтка озату берничә көнгә сузылды. Казан вокзалы каршындагы бакча кырында көннәр буе поезд көтү. Армиягә алынган егетләр, ирләр, озатучылар – барысы бергә әле. Гармуннар. Йөрәк өзгеч җырлар. Әйтеп каласы сүзләр, истә калдырасы итеп караулар. Команда биреп, берәүләрне те-

зеп, барлап, вокзал эченә алып кереп китәләр. Озатучылар койма янында өзелеп кала – перронга керергә рөхсәт юк. Китәләр, яңалары килә. Халык бетми, мәйдан гөрли, җырлый, җылый... Абыйларны, көнозын торгач, иртәгә дип, кире кайтардылар. Тагын бер төн үз өебездә бергә куну шатлыгы...

Ниһаять, абыебызны армиягә озатып җибәрдек. Шул ук көнне аннан хәбәр дә килеп ирешә. Дөресрәге, блокнот битенә ашыгып кына язылган ул хат-записканы бер узгынчы өебезгә кертеп чыккан иде...

Шуннан соң да абыебыздан хат-хәбәрләр өзлексез килеп торды – бигрәк тә тынгысыз, кайгыртучан изге җан иде шул ул – кадерле, үтә якын кешебез! Хәтта кыска-кыска җөмләләреннән дә безне ничек кенә булса да борчымаска – тынычландыруга көчле омтылыш, күңел җылысы бөркелеп тора иде аның...

1943 елның август азагында дошман ядрәсеннән гомере киселгәнчегә хәтле Мөхәммәт абыебызның рухы, җаны гел безнең белән бергә булды. Хәер, хәзер дә ул безнең арада! Мөхәммәт абыебызның көндәлекләрен, сугыштан язган хатларын, шигырьләрен укып, фоторәсемнәренә карап, без аны һәр көнне күңелләребездә яңартабыз...

Абыебыз бик матур – бөдрә чәчле, уйчан кара күзле, таза-төз гәүдәле чын егет иде. Тавышы бик моңлы булып, җырларга да, биергә дә бик яратты. Өстәвенә үткен телле, тапкыр сүзле дә иде ул...

Беренче әдәби язмаларыннан күренгәнчә, абыебыз иҗат эше белән 1934 елдан шөгыльләнә башлый. Беренче шигырьләре 1935 елда «Мехчы», «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы битләрендә дөнья күрә, соңга таба «Шат балалык», «Алмаш», «Очкыннар», «Беренче көн» кебек күмәк җыентыкларда һәм альманахларда басылып чыга. Аның шигырьләре эчтәлек ягыннан бәхетле балачак, яшьлек ялкыны, илне саклау, котыпны җиңү кебек шул чор поэзиясе өчен характерлы темаларны яктырта. Мөхәммәт абыебызның шагыйрьлек сәләте бигрәк тә кече һәм урта яшьтәге балалар өчен язган шигырьләрендә («Ата һәм бала», «Балык тотканда», «Бишек җыры», «Үгез», «Сеңелем бәхете» һ.б.) ачык күренә.

1941 елда Мөхәммәт абыебыз үзенең шигырьләре тупланган беренче җыентыгын басмага әзерләгән иде, әмма сугыш башлану сәбәпле, әлеге китап чыкмый калды...

Шулай да, Җиңү таңы атканнан соң, без аның бу изге хыялын, якын дуслары ярдәмендә, уңышлы төстә тормышка ашырдык...»

* * *

Мөхәммәт Әхмәтгалиевның сугыш чоры көндәлекләрендә һәм фронттан язган кайбер хатларында – яшь язучының уй-кичерешләре, шул дәһшәтле чорга карата үз мөнәсәбәте-фикерләре...

Әлеге язмаларны тәртипкә салып, матбугат өчен әзерләүдә Мәрьям ханым белән Ильяс әфәнде Әхмәтгалиевларның булышлыгы зурдан булды. Хатлардагы, көндәлекләрдәге искәрмәләр исә И.Әхмәтгалиев (*И.Ә.*) тарафыннан бирелде.

*ХАТЛАРДАН, КӨНДӘЛЕКЛӘРДӘН ӨЗЕКЛӘР:*

*«...14 июнь, 1942 ел.*

Сөекле әнием, туганнарым! Сезгә ерактагы туганыгыздан кайнар сәлам! Үзебез әле дә карантинда ятабыз. Колхоз эшенә алып баралар.

Безне бүген озатачаклар. Кая – билгесез. Урнашкач, язармын. Инде ай булып килә, урнашмагач, сездән хәбәр алып булмый. Сагындырдыгыз. Адресымны алгач та, бик озын итеп русча хат языгыз, алай тиз йөри, ди...

*16 июнь, 1942 ел.*

...Улыгыз мундир киде, аякта – ботинка, обмоткалар, өстемдә –гимнастерка, чалбар, башымда – кызыл әйләнмәле фуражка. Чын пехота! Хәзер Алтайда, Бийск шәһәрендә, лагерьда. Бирედә өч ай булачакбыз, кече комсостав (сержант, старшина) хәзерлиләр. Мансур Җәләй дә минем белән бер ротада. Яңа бистә егете Мәгъсумов Ильяс та безнең белән. Әхмәт Моратов пулемет ротасында. Ашау – туярлык, землянкаларда урнаштык. Өйдән чыгып киткәннән бирле беренче тапкыр, салам тутырылган булса да, матраста, башны шундый ук мендәргә куеп, одеял ябынып йоклыйбыз. Лагерь Бий елгасы буенда, нарат урманында. Борчылмагыз, бәлки, өч ай эчендә сугыш та бетеп куяр әле. Дөнья күреп, хәрби төгәллеккә өйрәнеп кайтырбыз. Бүген адресымны язам

инде: г.Бийск, п/я 34/В-III. Алуга җавап язу – сезнең бурыч. Сагындырдыгыз шулкадәрле.

Әни, сәламәтлегең ничек, арыйсыңмы? Заводтан расчет алдыгызмы? Күпме тиде? Ничә кило бәрәңгелек? Дусларымны күрсәгез, барысына да сәлам. Адресым билгеле инде, язсыннар. Кызлар фронтка китмәделәрме? Ешрак языгыз, бүтән берни дә кирәкми. Бергәләп төшеп, карточкагызны җибәрегез. Гарәфи, Рифгать, Мәхмүтләрдән* хәбәрләр киләме? Әти белән әбинең каберлегенә кәз җәйдегезме? Хат көтеп, сәлам белән улыгыз!

*13 июль, 1942 ел.*

Үткән ялда ант кабул иттек. Хәзер чын сугышчылар инде. Безнең рота икенче тәүлек нарядта. Постта торабыз. Рәхәт инде, ике благодарность алдым. Менә шул. Минем өчен борчылмагыз.

*3 август, 1942 ел.*

Ерак Алтай тауларыннан сәлам! Утынның кыйммәтлеген ишетеп, бик борчылдым. Бу кышны да суыкта туңып чыгарсыз микән? Ничек кенә булса да, рәтләгез. Шәүкәткә, Равилнең әтисе Сәлах абыйга барыгыз. Утын булмаса, ташкүмер миче ясатып, күмер табарга тырышыгыз. Мәрьям, заводта ашау бик начармы, эш хакы күп тияме, азрак чыгып йөргәлисезме? Ильяс, синең экзаменнар беткәндер инде? Белгеләрең ничек?

Стипендия артмадымы? Колхозга җибәрмәделәрме? Бәрәңгеләрне утыйсызмы? Егетләргә сәлам, алардан хат көтәм. Бүген караул торабыз.

*11 сентябрь, 1942 ел.*

Хәерле иртәләр, минем кадерле әнием! Сәлам, сәлам барыгызга да! Үзем сау-сәламәт. Бүген иртүк санчастька бардык. Комиссиядән үттем. Хәзер мандатный комиссиягә барырга җыенабыз. Үтсәк, каядыр лейтенантлыкка укырга җибәрәселәр. Теләктә торыгыз инде...

Мандат комиссиясе булмады. Хәзер көндез унбердә по-

---

* Мәктәп дуслары: Гарәфи Хәсәнов – язучы; Рифгать Мөхәммәтҗанов – математик-программист; Мәхмүт Зарипов – галим, физика фәннәре докторы, профессор. Алар, 1941 елда гаепләнеп, илленче елларда акландылар. (*И.Ә.*)

езд белән Барнаулга китәбез. Юлдан да, барып җиткәч тә хат язармын. Сез, адресымны алгач та, шул ук көнне җавап язарсыз. Мәрьям, ни эшләр бетерәсең? Ильясның хат-хәбәре бармы?..

*22 сентябрь, 1942 ел.*

Сезгә ерак илләрдән, җылы йомшак җилләр аша, сагынычлы кайнар сәламнәремне күндереп калам. Үзем исән-сау. Лейтенант булырга укыйбыз. Ашау-эчү әйбәт, кием-салым яхшы, барысы да өр-яңадан. Тик сезне уйлап кына борчылам. Бик күптән хат алганым юк. Казан өстендә немец карчыгалары очмагандыр бит? Казаннан чыгып киткәнгә 4 ай булды бугай (ялгышмасам). Гомер уза бит, нинди үзгәрешләр булып узмады. Хәзер инде отделение командиры булдым...

*9 октябрь, 1942 ел.*

Исәнмесез! Исән-сау гына укып ятам, шөкер әлегә, эшләр әйбәт кенә. Ашау-эчү яхшы. Өс бөтен. Артык йөгертмиләр. Былчыраклары гына үзәккә үтә, хәер, мин Казанныкына күнеккән кеше...

*3 ноябрь, 1942 ел.*

Исәнмесез, кадерле туганнарым! Әни, сеңел, энекәш, Зәйнәп апа, сезгә туганнарча сәлам! Ильяс, синең 16сында дәрес арасында язган хатыңны – кичә, 19ында язганын бүген алдым. Шулай күбрәк яз.

Үземнең хәлләр беркөе, әйбәт кенә, дисәң дә була. Бияләй, бүрекле булдык. Сезнең өчен генә борчылам. Кышны ничек чыгарсыз икән? Мәрьям, сиңа кием тектердегезме әле? Аяк киемнәрең бармы? Энем, синең кыш кияргә нәрсәң бар? Минем пальтоны рәтләп булмасмы?

*8 ноябрь, 1942 ел.*

Бүген, ике хатыгызны алып, шулчаклы шатландым, әйтерсең лә сез керткән электр лампасы йөземне яктыртты. Мәрьямгә тегелгән кием мине җылытты. Сезгә җылы, якты булса, миңа да – якты. Тамагыгыз тук булса – мин дә тук.

Кичә сезгә, Рәшиткә, Җәвадка хат яздым. Бәйрәм көннәрен туганнардан, иптәшләрдән еракта үткәрү ямансу икән. Бүген, хатларыгызны алгач, кәеф-хәтерләр бөтенләй күтәрелеп китте. Ильяс, электрны чын-чынлап эксплуатировать итегез, электр миче табып, чәй кайнатыгыз, аш пешерегез.

Инде утын яки ташкүмер дә рәтли алсагыз, кышны дөбершатыр иттереп чыгар идегез... Татарлардан батальонда үзем генә. Ротабызда ойрот егете бар (алтайлы, казахка якын халык). Кичә аның белән җырлашып утырдык.

Мин кайгылы, мин кайгылы,
Мин кайгылы булганмын.
Әнкәемнең иң кайгылы
Көннәрендә туганмын.
Үзем җырлыйм, үзем җылыйм,
Үзем гөлчәчәк өзәм,
Хәсрәт күлләрендә йөзәм,
Яшьлегем белән түзәм.
Самавырларны кайната
Ак каен күмерләре,
Гөлгә кунган тузан кебек
Яшь егет гомерләре.
Уфтанма, күңел, уфтанма,
Уфтанган, димәсеннәр.
Уфтаныр көннәргә калган
Бу егет, димәсеннәр.
Ярның аргы яккаена
Дошман таяк ташлаган,
Без бәхетсезләргә каршы
Герман сугыш башлаган.
Алдылар, бәгырьләрем,
Калдыгыз, бәгырьләрем...
Герман границасында
Калмасын каберләрем!
Герман границасында
Ташлык түгел – гел таулык...
Исән булсак, бер кайтырбыз,
Кирәк исәнлек-саулык!..

Шулай бит, әни, язган булса, бер кайтып, шау-гөр килеп яшәрбез әле. Сиңа, әни, туганнарга саулык кына бирсен Ходай! Әни, син дә тегү машинаң төбендә, мине сагынганда, шул җырларны җырла. Балавыз гына сыкма. Күзләрең болай да кара бит. Чынлап әйтәм, минем өчен аз гына да борчылма, кайгырма. Хәлләрем әйбәт әле минем. Өс-баш бөтен, тамак тук. Мәрьям, син авырып йөрисең икән. Бирешмә!

Инде үз хәлләремә килгәндә, мин моңарчы отделение командиры булып тордым. Хәзер мине командирлыктан төшерделәр. Әни, син яшьләргә каты булма, дип язган идең. Менә шул каты булмавым өчен төшерделәр. Ярар, бу зур мәсьәлә түгел. Моңарчы да курсант идем, хәзер дә. Укып

бетерә алсак, лейтенант булырбыз барыбыз да. Менә шул үзем турында. Ашау-эчүне сорыйсыз. Иртән – 300 г икмәк, 25 г май, шикәр комы, аш, чәй. Көндез аш (итле йә колбасалы, йә ике селедка белән бәрәңге), ботка (йә бәрәңгедән, йә кишердән), компот. Кичкә дә җылы аш, чәй. Өс бөтен, әни, тамак тук, бер дә борчылма минем өчен...

*14 ноябрь, 1942 ел.*

...Мине тәбрик итәргә була. Бүген хәрби ант кабул иттек. (Миңа ике кат туры килде: беренчесе – Бийскида.) Хәзер менә, Такташны укып утырдым да, сиңа хатны дәвам итәм. Миндә Такташның җыентыгы һәм Г.М.-ның «1935»е генә бар (Галимҗан Мөхәммәтшин китабы.– *И.Ә.*) Бу – минем өчен бердәнбер татар дөньясы...

Англиянең Африкадагы кызу хәрәкәтләре турында укып шатланабыз. Бу – икенче фронтның башлануы түгел микән?

*22 ноябрь, 1942 ел.*

Хәерле көн сезгә, кадерле туганнарым! Әнием, сеңелем, энекәшем, Зәйнәп апа һәм барча туганнарым! Сезгә ерак-ерак илләргә барып адашкан, инде менә ярты елга якын туганнарын, иптәшләрен-дусларын күрми яшәүче улыгыз Мөхәммәттән кайнар сәлам. Шаулы, нурлы, тузанлы Казан каласыннан аерылганга, ялгышмасам, нәкъ ярты ел.

Әйе, инде күпме сулар агып,
Күпме-күпме җилләр искәндер,
Ничә төннәр әни ак түшәктә,
Мине уйлап, яшен түккәндер?
Күпме вакыт үтте, маңгаемнан
Үпкәнеңнән бирле соңгы кат,
Малаеңның кайнар мәхәббәтен
Сиңа илтсен, әнкәм, сәлам хат!..
Монда юк шул, күңел тулган чакта,
Күздән күреп, хәлне белүче,
Кар-буранда хәлдән тайган чакта:
«Туңгансыңдыр, улым»,– диюче...

Әйе, әнием, арысам да, туңсам да, сине уйлап, йөрәгемә хәл керә. Кайчан гына өйгә кайтырмын? Алны-ялны белми, сезне кадерләп, тәрбия итәрмен? Кайчан гына дөнья борчуларыннан, газап-кайгыларыннан башка сезне рәхәт кенә яшәтермен? Шул өметләр белән яшим, шуларны уйлап, күңелемне юатам мин, әнием!..

*13 декабрь, 1942 ел.*

...Иртәгә взвод командиры булырга өйрәнә башлыйбыз. Бүген якшәмбе көн, чаңгыда йөрдек, утын бушатырга бардык...

*21 декабрь, 1942 ел.*

...Берьюлы дүрт хат. Утын алгансыз икән, аңа бик шатландым. Җәвадтан да хат бар. Тиздән – чаңгы походына!

*1 гыйнвар, 1943 ел.*

Сеңелем, үзеңә генә дип язам, исәнме, кадерлем! Йомшак җилләр, Казанга кадәр исеп, чәчләреңне сыйпап, битеңнән үбеп, Яңа ел сәламнәремне, сеңелем, сиңа илтсен иде, дим. Әле генә кино карап кайттык. «Каин һәм Артем», әйбәт кенә. Бүген – ял. Яңа ел хөрмәтенә. Менә, парта артына утырып, тәмәке кабыздым (абый тартырга өйрәнгән икән, дип уйлама, сеңелем. Мин тартмыйм. Хәзер менә эч пошканнан гына). Төшемдә ябык йөзеңне, моңсу күзләреңне күрәм. Сагындым, сеңелем, шулкадәр сагындым!

Обедка барып кайттык. Тамак тук, ә җан? Тәнгә – азык, ә җанга – юк...

Сеңелем, бу сугышлар башлангач, үз-үзем белән ялгыз калып, үз-үземә урын таба алмый газапланган идем мин, очына чыга алмадым уйларымның. Ә менә хәзер өскә шинель кигәч, кулга мылтык алгач, мин үз урынымны таптым. Мин хәзер бәхетсез әниләрнең, синең кебек моңлы күзле сеңелләрнең гомерләрен саклаучы солдат булдым. Илдә кош та югалмый, диләр. Син дә, мин дә үз бәхетебезне табарбыз әле. Без аны көрәштә генә табарбыз. Тиздән, синең бәхетеңне яулап табар өчен, көнбатышка китәрмен, бәхетле җиңүчеләр арасында мин дә Казанга кайтырмын әле. Сеңелем, юрау-багуларга ышанам. Бәхетең, үз Кояшың табылыр, мин бәхетсез, миннән булмый, димә син. Була! – диген, булдырам! – диген. Кырыкка ярыл, тырыш. Халык арасына чык. Яхшы иптәшләр (егетләр арасыннан да) тап. Киемнәреңне кайгырт, киногa, театрга, танцыга йөрергә тырыш. Әмма үз дәрәҗәңне төшермә. Күңелеңне дә төшермә, авырлыкларны җиңеп чыгарга тырыш, аптырап торма. Сугыш озакка бармас, мин исән-сау кайтырмын. Син укуыңны дәвам итәрсең. Бергәләп әнине тәрбияләргә керешербез. Шулай, сеңелем, бәхет үзе килми, без аны яулап алырбыз. Сеңелем,

әнигә, Зәйнәп апага, Ильяска сәлам әйт. Миңа еш-еш хат яз. Бөтен серләреңне, борчуларыңны яшермичә яз, сеңелем! Битеңнән үбеп абыең.

*9 гыйнвар, 1943 ел.*
*(Дусты Җәвад Тәрҗемановка җибәрелгән хат.– И.Ә.)*

Кайнар сәлам сиңа, Җәвад, ерактагы дустың Мөхәммәттән! Туганнарга, дусларга, кызларга да миннән сәлам күндер!

Үзем исән-сау гына беркөе укып ятам. Өс-баш бөтен, тамак тук. «Ашау – байдан, үлем – Ходайдан»,– дип яши бирәм. Менә хәзер штабта телефон янында дневальный булып утырам. Берәү дә шалтыратмый. Инде төн. Кәеф әйбәт кенә. Чөнки бүген: «Сталинградтан немецларны 60 км га һәм Ленинградтан 50 км га куганнар!» – дигән җылы хәбәр килде. Йөрәкләрне җылытып, кәефләрне күтәреп җибәрде. Бүген көне дә бик җылы, тамчылар тама.

Түбәләрдән тамчы тама,
Тама бирсен.
Ялкынланып йөрәк яна,
Яна бирсен.
Тама торган тамчылар да
Кибәр микән?
Йөрәктәге ялкыннар да
Сүнәр микән?..

Кайчакта үлеп-үлеп шигырь язасы килә дә, вакыт булмый, йә тагын ни дә булса килеп чыга. Ә безнең яшьтәш, каләмдәш Шәрәф Мөдәррис Союзга алынган, ди инде. Шулай итеп, тамчы кебек кибәрбез микәнни?..

Взвод командирыбыз мәктәп директоры, әдәбият укытучысы булган. Кайчак аның белән гәпләшеп утырабыз да, авыр сулап: «Сугыш беткәч...» – дибез.

Әйе, сугыш беткәч, исән булсак, мәктәпләргә кайтып, шау-шулы, нурлы биналарда балалар белән гөр килеп гомер итәрбез.

Илһам килгәндә, каләм дә тибрәткәләрбез. Ә әнкәй өй түрендә тәсбих тартып утырыр... Юк, бу күңелнең нечкәрүе генә. Хәзер азмы-күпме үзгәрдем, кырысландым инде, дустым. Безнең алда – бөтен каты кырыслыгы, газаплары белән рәхимсез сугыш. Белмим, ул дәһшәтле упкыннан Тынычлык, Сәламәтлек ярына барып җитәрбезме, әллә – кара туфрак астынамы?

Юк, үлем куркытмый инде хәзер. Әгәр үлеп тә, әнием, туганнарым, дусларым бәхетле булсалар, минем генә гомерем берни түгел. Ә шулай да ЯШИСЕ КИЛӘ!..

*11 гыйнвар, 1943 ел.*

Шубенко дигән авылга кадәр 5 чакрым. Сырган чалбар, киез итекләр, телогрейка, шинель. Мылтык, көрәк, противогаз, ранец. Һөҗүм иттек, оборонада тордык. Авылга 2 чакрым калгач, таралып, кыска-кыска һөҗүм итү. Тездән кар, тирләп-пешеп чабасың да егыласың. Яту белән кар ашыйсың. Бил тиңентен кар булгач, авыр икән. Авылда кундык, җылы өйдә рәхәт шул. Беренче көнне чуашларда кундык. Тәтештән күчеп килгәннәр, татарлар да бар, диләр, күреп булмады үзләрен. Газеталардан укыгансыздыр – погоннар турында. Бәлки, безгә дә офицер погоннары эләгер. Тиздән фронтка китәрбез, диләр. Гвардейский частьларга рядовой итеп җибәрәселәр икән, имеш. Кем белә, бәлки, бу – буш сүзләр генәдер. Барыбер ул көннәр ерак түгелдер инде. *Әгәр кайта алмасам, онытмассыз, энем.* Әнине, Мәрьямне карау синңа кала. Өйдә хуҗа бул, олы хуҗа булырсың, энем. Хәер, исән калып кайтырмын төсле, өметемне бөтенләй җуймадым әле. Безнең урамга да бәйрәм килер, дип юанам. Син боларны, энем, башкаларга сөйләми тор, минем өчен кайгырмасыннар. Сәлам белән абыең (хат техникум адресына җибәрелгән.– *И.Ә.*).

*19 гыйнвар, 1943 ел.*

Әни, син минем русча язуыма үпкәлисең икән. Тизрәк барып җитсен дип, шулай язам бит, ачуланма. Моннан соң үзеңә татарча гына язармын. Син улыңа бөтен борчуларыңны әйтеп хат яз. Үз кулың белән язган хатларыңны, җылы сүзләреңне укыйсым килә. Комиссиядә булдыңмы? Нәрсә диделәр? Икенче группа бирделәрме? Җиңелрәк эшкә күчермәделәрме?

Әнкәй, эштән кайткан чакта,
Иңбашларың таладыр,
Уйлап газиз малаеңны,
Йокыларың каладыр.
Алтын погоннар тагып,
Атланып акбүз атка,
Сезнең янга кайтыр идем
Бер генә кич кунакка!..

Шулай, әни, исән йөреп, сау кайтсын дип, теләкләр теләсәң, бер әйләнеп кайтырмын әле мин сезнең янга. Бик күңелле итеп бәйрәм итәрбез, әни. Әлегә синнән үтенеп сорыйм, мине уйлап борчылма, әни. Минем өс – бөтен, тамак – тук. Сеңелем бик ябыккандыр инде, яшьли тормыш куа башлады. Күңелен күтәрергә тырышыгыз. Рәт булганда, кинога, театрга баргаласын. Әни, үз сәламәтлегеңне сакла. Моннан соң сиңа аерып хатлар язармын, үзең дә яз. Сәлам белән, битеңнән үбеп, улың. (Безнекеләр Ленинград блокадасын өзгәннәр, әйбәт хәбәр бит бу!)

*25 гыйнвар, 1943 ел.*

Кичә яңа киемнәр алдык. Бүген булмаса, иртәгә китәрбез. Витаминнар җитешми, грипп, цинга, ди врач. Миңа казармадан чыкмый ятарга кушты. Барысына да хат язасым килә. Әнигә дә...

*31 гыйнвар, 1943 ел.*

Исәннәрмесез! Юлдан язам, кичә кич киттек. Бүген Новосибирскига барып җитәбез. Үземнең хәл ярыйсы. Хәрби врач ялгышкан икән, цинга түгел, дарулар бирделәр. Ашый алам. Вагонда мич яна, җылы. Өйгә керермен, дип хыялланам.

*13–15 февраль, 1943 ел.*

*(Техникум адресына җибәрелгән хат.– И.Ә.)* Исәнме, кадерле энем! Әнигә, Мәрьямгә, Зәйнәп апага сәламнәремне күндерерсең. Менә тиздән Молотовка җитәбез. Казан дип хыялланган идем, булмады. Өйгә кереп чыгармын, дигән идем. Язган идем, укуны бетертмәделәр. Гвардия частьларына рядовой итеп җибәрделәр. Хәзер башкалага таба барабыз. 13 февральдә Молотовны уздык. Әле дә кая баруыбызны белмибез. Мәскәүгәдер, дип уйлыйм... Теплушка тормышына өйрәнеп барабыз...

Энем, ир булырга тырыш. Әнине, Мәрьямне кара, аларны кайгырт. Минем өчен борчылмасыннар. Сугышта бөтен кеше дә үлми бит, диген син аларга. Кайтуыма ышанам әле мин...

Әгәр дә кайта алмасам, бәлки, минем китабымны (шигырьләремне) чыгарырсыз? Сәлам белән абыең.

*20 февраль, 1943 ел.*

Исәнмесез, минем өчен кадерле туганнарым! Менә без бүген Рыбинск шәһәренә килеп җиттек. Шулай итеп, Мәс-

кәүгә дә кермәдек. Моннан соң кая китәрбез – белмим. Көнбатыш фронтка якынлашабыз.

*3 март, 1943 ел.*

Здравствуйте, мои дорогие! Кадерле әнием, сөекле сеңелем, энекәш һәм Зәйнәп апа – барыгызга да сәламемне күндерәм. Шулай ук барча туганнарга, иптәшләремә дә сәлам әйтегез. Менә, ниһаять, билгеләнгән частька барып җиттек. Фатирларга урнаштык. Ашау начар түгел. 900 г икмәк, башка ашау-эчү әйберләрен бирәләр. Бу часть – Сталинградта булган часть, хәзер ялда. Без автоматчик булырга өйрәнәбез... Минем адрес: ППС 1769, часть 48.

*7 март, 1943 ел.*

Исәннәрмесез, минем кадерле туганнарым! Үзебез «ерак тылдагы» (рота командиры шулай ди) бер авылда яшибез. Бирегә 2 мартта килеп җиттек. Авыл өендә. Өй җылы. Нар эшләдек. Бар да яшьләр, күбесе училищедан. Без – автоматчылар ротасында. Училищедагы кебек, строевой занятиеләр була. Урман, сазлыклар. Тездән кар эчендә йөреп, «кәккүкләр»не эзлибез. Сугышка март ахырында керербез төсле. Безнең рота резервта (запаста) булыр, дигән сүзләр дә бар. Ә хәзергә Великие Луки (цензорлар тарафыннан сызылган бу исем.– *И.Ә.*) тирәсендәге бер авылда яшибез. Немец чәүкәләре очып үткәлиләр. Төнлә, йортка чыксаң, еракта саңгырау гына туп тавышлары ишетелә. Рота командирыбыз әйбәт тә кеше инде. Укытучы булган, күпне күргән командир. Кичә автоматлар (ППШ) бирделәр. Хәзер кулыбызда бик көчле корал. Сездән тизрәк хат-хәбәр дә килеп җитсә, бик шат булыр идем. Бәлки әле, моннан киткәнче, хатыгызны алып өлгерермен. Үзегезне бик сагындым.

*14 март, 1943 ел.*

Добрый день, мои родные! Үзем исән-сау. Язган идем, бер авылда тордык, автоматчик булырга өйрәндек. Бүгенме, иртәгәме – ары китәрбез. Әлегә ярыйсы. Хәбәрләр килмәсә, иптәшем Чествов хатынына барып белешерсез (Уңъяк Болак, 17 нче йорт, 12 нче фатир, Григорьева Анна). Әлегә без аның белән бергә. Әнием, кайгырма минем өчен, елама, теләктә бул, көт мине, бик тә көт мине, әнием! Берәү дә көтмәгән кебек! Син бик-бик көтсәң, кайтмый калмам, әни!

Фрицларны гына кырып бетерик. Мин генә ничә «газраил»-не үзем белән йөртәм: автоматымның бер дискында гына 72 патрон! Бик гайрәтле нәрсә минем кулымда! Ә ачуым-нәфрәтем аннан да көчлерәк... Кайтырмын әле, әни, Алла боерса, берзаман!..

*18 март, 1943 ел.*

...Бүген иртән Ореховщина дигән авылга килдек. Бу – Смоленск өлкәсе. Смоленскидан 120 чакрым, фронт исә бездән 50 чакрымда. Бик арылды. Монда бераз ял итәсебез бугай. Яз җитә. Көндез кар эри. Төннәр салкын. Тамчы тама. Кояш исе килә. Егетләр бүген сыерчыклар күргәннәр. Яз килә шул. Берничә көннән унберенче ай китә инде минем өйдән чыгып китүемә. Их, кайчан өйдә булырмын икән мин? Тиздән безнең бакчада да алмагачлар, чияләр чәчәк атар, кошлар сайрар. Тәрәзәләрне ачып, яз исенә күмелеп уйланырсыз... Яратам мин үзебезнең тәрәзә алдында утыруны. Март кына әле дип тормас идем, ачып куяр идем хәзер үк тәрәзәмне...

*30 апрель, 1943 ел.*

Май бәйрәме котлы булсын, туганнарым! Сөекле әнием, сөекле сеңелем, энекәшем, Зәйнәп апа һәм барча туганнарым, сезгә сәлам. Шулай ук дустым Шәукәткә, Җәвадка, Рәшиткә, Барига, Идрискә сәлам әйтегез. Менә иртәгә бәйрәм. Җылы апрель кояшы. Чирәмнәр күренә. Салкынча җил... Бүген ике хат алдым, бу – бишенче хат инде. Сезнең саусәламәтлекне белеп куандым... Учак янына җыелып, үткәннәрне сагынып, өйне сөйләп хыялланабыз. Исән-сау кайтсак, яши белер идек, дибез. Бик сагынам өйне. Очып кына кайтыр идем. Бер генә кич булса да, сезнең белән шаулап торган самавыр артында утырып, кайнар бәрәңге ашар идем. Тиздән безнең бакча да чәчәкләр атар... Их, оныткanмын шул, бакчаны утынга кисеп яккансыз бит инде. Әнә кәккүк кычкыра: бер, ике, өч...

Минем дә гомерем бар микәнни? Эх, киләсе бәйрәмнәрне сезнең белән бергә тынычлыкта күреп булсын иде!..

*10 май, 1943 ел.*

...Кичә, 9 майда, миңа ике көнгә освобождение бирделәр. Ял итәм (автоматлар чистартабыз). Көн әйбәт. Нарат

урманы, чыршылар. Чәчәкләр, кошлар, кәккүкләр. Кошлар бәхетле, алар сугыш авырлыгын сизмиләр. Туганнарыннан аерылмыйлар. Тиздән бала чыгарырлар. Очыгыз, кошлар, туган шәһәремә, әниемә минем сагышымны сөйләгез. Әтием кабере өстендә сайрагыз...

*26 май, 1943 ел.*

Кадерле әнием, сөекле сеңелем, энекәшем, Зәйнәп апа, сезгә – барыгызга да – улыгыз Мөхәммәттән кайнар сәлам! Шулай ук барча туганнарга, дусларга сәлам әйтегез. Менә икенче елым китте инде, исән-сау әлегә. Хәзер без фронттан 15–17 км да. Окоплар эчендә читәннәр үрәбез. Һәр көн яңгыр ява. Казанда ничек? Ашау-эчү рәтләнә инде. Әйе, ел узды. 1943 елның маен күрермен дип, исән калырмын дип уйламаган идем. Киләсе язларны сезнең белән күрергә язсын инде...

*6 июнь, 1943 ел.*

Исәнме, кадерле әнкәем, саумы сез, сөекле сеңелем, энем, Зәйнәп апа һәм барча туганнарым! Сезгә ерак-ерак илләрдән искән йомшак җилләр аша сагынычлы сәламнәремне җибәрәм! Әйдә, ул шаян җилләр сезгә минем турыда сөйләсеннәр. Улыгыз Мөхәммәт бакча кебек матур урында әйбәт кенә яши, дисеннәр ул җилләр. Ул яшәгән урманда иртәсен-кичен кошлар сайрый, чылтырап чишмә ага, шаулап төрле гөлләр, кура, җир җиләкләре чәчәк ата, дисеннәр. Кәккүкләр, озын гомер теләп, туктаусыз кычкыралар, дисеннәр. Тик улыгыз гына сезне – әнкәсен, сеңелкәшен, энекәшен, туганнарын, дусларын, ямьле, тузанлы Казанын сагына, дисеннәр. Әйе, тамак – тук, өс – бөтен, баш өстендә шаулап снарядлар ярылмый, выжлап пулялар очмый, ә шулай да күңел тыныч түгел. Сезнең авыр тормышыгыз йөрәкне телә, әни, һич ярдәм итә алмыйм шул. Сугыш бетеп, тиздән исән-сау кайтып, сезне тәрбияләргә язсын иде... Сездән күптән хат алганым юк, бик сирәк язасыз, ахры. Яңа гына яңгыр явып үтте. Бүген төнлә штаб сакладым (нарядта идем), иртән, ашапэчкәч, иптәшем белән чишмә буенда йокладык. Обедтан соң менә үзебезнең землянкада утырабыз. Яңгырдан соң һава чыршы исе белән тулды. Мин Валентин Катаевның «Мария» дигән поэмасын укыдым. Әйбәт поэма. Менә инде ничәнче тапкыр безнең фронт газетасын («Алга – дошман өстенә!») укыйм. Анда Әхмәт Исхакның «Ант» дигән шигыре дә бар.

Бу газета миңа ялгыш кына килеп эләкте. «Ант»ны ятлап, сугышчылар алдында сөйләргә уйлыйм. Их, Тукай, Такташ һ.б. татар шагыйрьләренең әсәрләре кулга төшсә? Шулчаклы укыйсы, татар җырчыларын тыңлыйсы килә!.. Ильяс, син өйдәме? Сеңелкәш, Ильяс өйдә булмаса, син хат яз. Бәрәңге утырттыгызмы, үсәме? Барысын да языгыз.

*26 июнь, 1943 ел.*

Кадерле әнием, сөекле сеңелем, энекәшем, Зәйнәп апа, сезгә сагынычлы сәлам! Үзем сау-сәламәт. Сезнең 14 июньдә язган 2 хатыгызны өченче көн алып укыдым. Бу арада, таңнан торып, эшкә кадәр дә, эштән соң да йөрергә өйрәнәбез. Парадка хәзерләнәбез. Бүгенме-иртәгәме, безнең бригадага* Сугышчан Кызыл Байрак ордены бирәчәкләр. Сталинград төбендәге геройлыгы өчен. Без үзебезнең президент исемендәге фронтта. (Аңладыңмы, Ильяс?) Менә биш кубометр җир казыдык. Хәзер обед вакыты (карабодай ашы, тары боткасы, колбаса, 300 г икмәк). Менә шулай безнең тормыш, әлегә әйбәт. Сезнең бәрәңгеләр чыкканнар икән инде. Исәнлектә бергә-бергә ашарга язсын иде. Әни, һаман утын ташырга йөрисеңме әле? Их, язмыш, язмыш... Сеңелем, күңелеңне төшермә, тиздән сугыш бетәр, менә дигән итеп гомер итәрбез!

*10 июль, 1943 ел.*

Кадерле әнкәй, сөекле сеңелем, энекәш, Зәйнәп апа, сезгә сагынычлы сәлам! Үзем сау-сәламәт. Менә кичә сездән инде икенче хат (25.06) алдым. Җавап язарга йә вакыт юк, вакыт булса, карандаш юк. Әле менә иптәшем обед алырга китте, мин язарга утырдым. Сугыш озакка бармас. Гитлер тиздән капут булыр. Исән-сау булсам, әйләнеп кайтырмын да, тормышны рәтләрбез... Энекәш, экзаменнарыңны ничек бирдең? Син хәзер лагерьдадыр инде? Шәйхи Маннурның шигырьләрен алмадым. Юлда югалгандыр инде. Хәй Вахит Казандамы? Фронтта булганмы? А.Әхмәт безнең фронт газетасына («Вперед – на врага!») язгалый. Ул Казандамы? Алиштан хәбәр бармы? Җәвад Казанда эшлиме? Рәшит? Нигә хат язмыйлар? Мине оныткаңнардыр инде...

---

* 39 нчы армиянең 83 нче укчы корпусы составындагы 124 нче укчы бригада турында сүз бара (*И.Ә.*).

Без обедны ашап бетерә алмадык, тагын яңгыр коеп ява башлады. Бер җимерек өйдә ышыкландык, монда дистәдән артык бала-чага, хатын-кыз. Их, тормыш... Икмәкләре юк, тозлары юк. Кузгалактан аш пешерәләр. Шушындый тормышны күргәч, сез искә төшәсез дә, күңелем әллә нишләп китә. Әле дә ярый, авыр яшәсәгез дә, ерак тылда яшисез. Норма белән булса да, икмәк ашыйсыз. Ярар, шуның белән бетерәм. Тагын болытлар куера, яңгыр килә.

Сезгә фронтта булуым турында справка җибәрәм – кирәге чыгар...

*НКО СССР 3-отдельный батальон 124 стрелковой бригады. Часть строевая, 13 июля 1943 г. № 13/7 Действующая армия.*

*СПРАВКА*

*Выдана кр-цу Ахметгалееву Мухаммеду Ибрагимовичу в том, что он действительно находится в рядах РККА, воинской части 11087-а, Действующей армии. Выдана на предмет направления его матери Кулеевой Гульсум Вахитовне для предъявления ею местным властям.*

*К-р роты ст.лейтенант (Бочкорев).*

*14 июль, 1943 ел.*

*(«Сак-Сок бәете» көенә укыгыз.)*

Исәнме, әнкәй, саумы, сеңелем,
Сәлам, энекәш һәм Зәйнәп апа!
Сезгә, туганнар, ерак илләрдән
Искән җил белән сәлам җибәрәм.
Ел тулып узды өйдән киткәнгә,
Сезне күрмичә газап чиккәнгә.
Әнкәй, битеңнән суырып үптем,
Сездән аерылып, сугышка киттем.
Онытмам сине, әнкәй бәгырем,
Белмәгәнмен шул синең кадерең.
Окоплар казыйм, акрын җил исә,
Тирә-ягымда чәчәкләр үсә,
Кызарып кына җир җиләк пешә,
Туган илкәем исемә төшә.
Авыр көнегез борчый күңелемне,
Сагнып искә алам сөйгән сеңелемне.
Күз алдымда бит синең йөзләрең,
Коңгырт чәчләрең, моңсу күзләрең.
Таң белән торып, чәчең тара син,
Сагынган чакта айга кара син.

Мин дә айлардан сине эзләрмен,
Айдан елмаер яшьле күзләрең.
Күз яшең түкмә, сөекле сеңлем,
Исән-сау кайтыр абыең синең!
Безнең бакчада алма пешкәндә,
Зәңгәр офыкка томан төшкәндә,
Абыең кайтыр, кайтыр абыең!..

*21 июль, 1943 ел.*

Кадерле әнкәй, сөекле сеңелем, энекәш, Зәйнәп апа һәм туганнарым, сезгә улыгыз Мөхәммәттән сагынычлы сәлам! Үзем сау-сәламәт. Биш көн окоп казыдык. Ә бүген занятиеләр. Иртән тревога белән торгыздылар. Обедка чаклы «һөҗүм» иттек. Хәзергә менә граната өйрәнәбез. Көн кояшлы. Инде өченче көн һавалар әйбәт тора. Кура җиләкләре гөрләп үсәләр, җыеп ашыйбыз. Казанда килосы 200 сум, дип язалар икән. Сез җиләк-җимештән авыз итә алдыгызмы?

Бүген – 22 июль. Хатымны дәвам итәм. Менә бүген өйдән чыгып киткәнгә, якын туганнардан аерылганга бер ел да ике ай тулды. Бүген кич кузгалабыз. Язмыш безне кая илтеп ташлар? Киләчәктә безне нәрсә көтә? Бу – билгесез әлегә. Шомлы киләчәгем караңгы минем. Тик шул караңгы киләчәгемне яктыртып янучы өмет йолдызларым – әнием, сеңелем, энем генә миңа дәрт бирә, батырлык бирә...

Акрын гына томан күтәрелә,
Күкселләтеп урман итәген.
Утырам мин дымлы окобымда,
Сагышланып, хәбәр көтәмен.
Утырам мин дымлы окобымда.
Их, окобым шундый тар минем...
Күз яшьләрен түгеп, мине көткән
Саф күңелле сеңелем бар минем,
Хаты белән мине юатучы
Ачык йөзле энем бар минем.
Мин хат язам сезгә, туганнарым,
Кәгаземне куеп көрәккә.
Мин уйлыймын сезне, җылы хисләр
Дулкынлана минем йөрәктә.
Тирә-ягым кызыл балчык кына,
Казый-казый арып туктадым,
Һәм карадым газап белән үткән
Борылмалы сугыш сукмагын...

Без, 5–6 чакрым ары китеп, тагын тукталдык. Озакка түгел, диләр. Плащ-палаткадан шалаш кордык. Урманда. Өченче

көн инде тоташ яңгыр. Көз көнемени? Мондый җәйне беренче тапкыр күрәм. Палаткаларда автомат, граната һ.б. өйрәнәбез. Кичә ату кырында залп белән атарга өйрәндек. Бөтен рота берьюлы атканда, шундый яңгырый, колаклар тонып тора. Их, каһәр суккан Смоленщина җире... Яңгыр, сазлык. Шинельләр юеш, ботинкаларда – су. Ярый әле, тактикага чыкмыйбыз. Су эчендә түш белән шуарга туры килер иде. Исән-сау котылып чыгармы башлар бу җирләрдән? Соңгы көннәрдә сездән хат алганым юк. Ильяс лагерьдадыр инде? Мәрьям, син, эштән бик арып кайтсаң да, миңа хат яз. Әнием, син дә яз. Мондый яңгырлы, ямьсез көннәрдә бигрәк тә хат йөрәкне җылыта бит. Барысы турында да языгыз. Берсен дә яшермәгез. Шигырь язып карамакчы булган идем дә, фикерләрем тарала. Тупасландым...

Әни, сеңелем, минем өчен борчылмагыз. Ашау-эчү әйбәт. Әле сугыш кырыннан еракта. Тик туганнардан еракта булу гына авыр, бик уйланам.

Торган урыннан тагын 5–6 чакрым ары китеп, сазлыклы урманда туктадык. Инде икенче көн торабыз. Окоп казымыйбыз, өйрәнәбез. Тиздән китәрбез төсле, көннәр ямьсез, тоташ яңгыр булды. Бүген менә кояшлы, Ильясның дүрт хатын алдым. Аны өченче курска күчүе белән тәбрик итәм. Ул хәзер хәрби лагерьдадыр инде? Стипендиясен күтәрмәделәрме? (25 процентка?) Нәрсәләр яза? Бик каты өйрәтәләр, диме? Ашау-эчүләре ничек? Сеңелем, син яңа эшкә күчмәдеңме?

Без – каһәр төшкән сазлыклы, яңгырлы Смоленск өлкәсендә. Калинин фронты. (Минем «май» дип язган хатларымны «июнь» дип укыгыз. Мин нәкъ бер айга ялгышканмын.) Бүген Муссолининың төшерелүен ишеттек. Немецларның да җәйге һөҗүме туктатылды. Билгеле, хәлиткеч сугышлар алда әле. Ләкин озакка бармас инде. Әни, сеңелем, сугышның бетүен һәм минем кайтуымны сабырлык белән көтегез һәм теләктә булыгыз. Кояшлы көз иртәсендә, зәңгәрләнеп томан күтәрелгәндә, көлә-көлә кайтып килермен туган өемә. Керермен дә: «Менә, әни, менә, сеңелем, мин кайттым!» – диярмен. Ә син, әни, кара шомырт күзләреңнән яшьләр – шатлык яшьләре коя-коя, «Улым!» диярсең дә миңа ташланырсың. Сеңелем дә, җылыйҗылый, минем кочакка атылыр. Ә энекәш, тукта, болар җылап туйсыннар инде, дип, читтән карап торыр. Аннан соң, акрын гына килеп, олыларча калын тавыш белән: «Исәнме, абый, сәламәт кайттыңмы? Җәрәхәтләнмәдеңме?» – дияр. Әйе бит?..

*7 август, 1943 ел.*

Исәнме, минем өчен кадерле булган туганнарым! Әнием, сеңелем, энекәш, Зәйнәп апа һәм барча туганнарым, сезгә сагынычлы кайнар сәлам! Безнең Кызыл Армиянең Орел, Белгород шәһәрләрен алу шатлыгын сезнең белән уртаклашам. Үзем сау-сәламәт. Язган идем, безнең фронтта немец һөҗүмгә күчеп карады (безне тревога белән уяттылар). Безнекеләр немецны җибәрмәгәннәр. Әлегә тынычлык...

*13 август, 1943 ел.*

Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын...

*Такташ*

Бәлкем, көйгән сугыш кырларында
Ерткыч фашистларны кырырмын.
Сез бу хатны минем укыганда,
Бәлкем, каным агар чирәмгә,
Канлы калҗа эзләп, канат җилпеп,
Козгын очар минем тирәмдә,
Рәсемегезне сезнең, әнкәй бәгырем,
Соңгы тапкыр, бәлкем, үбәрмен.
Автоматтан, бәлкем, дошманнарга
Үлем ядрәләре сибәрмен,
Бәлкем, шулай булыр...
Ә бүген мин
Рәсемегезне алып кулыма,
Сагышланып карыйм һәм күз салам
Борылмалы тормыш юлыма.
Күз алдыма килә томан аша
Сабый чаклар, мәктәп еллары,
Айлы язгы кичләр, Кабан күле,
Бөдрә таллы Идел буйлары.
Их, Казаным, нурлы Казаным син,
Таныш миңа һәрбер сукмагың,
Күңелемне минем яктырталар
Йолдыз кебек якты утларың.
Их, Казаным, синнән туйган идем,
Хәзер менә шундый сагындым,
Былчырагың, чират, тузаның да
Минем өчен якын, ягымлы...
Казан, Казан, синдә калды әнкәй,
Туганнарым, якын дусларым.
Синдә калды кайнар мәхәббәтем,
Чия бакчам, җырчы кошларым.
Кайнар яшьләр белән күмәр идем
Синдә калган әткәй каберен.
Кайтырмынмы сиңа, күрә алырмынмы,
Их, Казаным минем, кадерлем!

Күктә болыт йөзә, шуңа кунып,
Очар идем Туган илемә,
Тик бер генә тапкыр карар идем
Әнкәемә, энем, сеңелемә...
Сез бу хатны минем укыганда,
Кайнар яшегезне түкмәгез,
Минем өчен теләк теләгез сез,
Мине уйлап газап чикмәгез.

Сезне үбеп улыгыз Мөхәммәт. *(Хәрәкәттәге армия.)*

P.S. Мөгаен, бүген сугышка керербез. Иртәдән бирле «катюшалар» җырлый, самолетлар оча, әле генә ике самолетны бәреп төшерделәр. Язганын күрербез, әнкәй. Күрешергә өметләнеп, улыгыз. *(Хат «Бөек Ватан сугышы геройлары – татарлар» исемле китап-брошюраның тышлыгына язылган.– И.Ә.)*

*14 август, 1943 ел.*

Хәерле иртәләр йә хәерле кичләр! Әнкәем, сеңелем, энекәшем, Зәйнәп апа, сезгә сагынычлы сәлам! Бүген көн шундый әйбәт, кояш, күктә бер генә болыт әсәре дә юк. Кичә иртән «катюшалар» җырлый башладылар. Күктә һава сугышлары булды. Безнең күз алдында 4 самолетны бәреп төшерделәр. Очучылары парашют белән сикерде. Безнекеләр кичә һөҗүмгә күчте һәм, немец оборонасын җимереп, берничә чакрым алга үттеләр. Безнең часть резервта. Һаман кузгалган юк.

Кичә кичен мунча кердек. «Антоша Рыбкин» дигән кино карадык. Кичә безнең яралы сугышчыларны алып киттеләр, аннан пленга эләккән фрицларны. Шулай, әни, без, әгәр дә безнең частьларга тыгызлык килсә генә, сугышка керәчәкбез. Яки аларны алга җибәрсәләр генә. Ә хәзергә алар артыннан барачакбыз. Тыныч булыгыз, язган булса, Берлинга җитеп, бөтен фрицларны кырып, исән кайтырбыз!..

*18 август, 1943 ел.*

Кадерле әнкәй, сөекле сеңелем, энекәшем, Зәйнәп апа, туганнарым, дусларым, сезгә сагынычлы сәлам. Үзем саусәламәт әле. Кичә алгы сызыктан берничә чакрымда гына булган бер урманга килеп туктадык. Безнең алгы частьлар һөҗүм итәләр. Без – резервта. Өстән снарядлар выжылдап очалар да 150–200 метр ары төшеп ярылалар. Яралылар бик күп. Гомумән, монда инде сугыш исе аңкый. Немец са-

молетлары баш өстеннән очып үтәләр. Шулай елдан артык йөри торгач, мин дә сугышка керәм бугай инде. Кичә комсомол билеты алдым (15 августта алындым).

*25 август, 1943 ел.*

Бүген көн болытлы. Мөгаен, яңгыр булыр. Ләкин җил исми. Тирән тынлык. Тик ара-тирә артиллерия генә аткалый. Һәм выжлап очкан снарядлар тавышы, таулар арасында яңгырап, саңгырау гына булып югала. Таучык астында, яшь тал куаклары арасында, чылтырап, көмеш кебек чишмә ага. Әлегә самолетлар очмый. Әле күптән түгел генә колбаса туралган дөге ашы ашап, шикәрләп чәй эчтек – бу завтрак, аннан почта килде. Миңа тагын ике хат (17 августта язылганнар). Көн болытлы, ә минем күңел күтәренке. Чөнки кичә 5 хат, бүген 2 хат алдым. Самолетлар очмый, безнең тирәдә миналар ярылмыйлар. Шушы күңелле иртәдә үземнең 1,5 метр тирәнлектәге окобымда утырып, сиңа, кадерле әнием, сөекле сеңелем, сиңа, энекәшем, Зәйнәп апа, сиңа сагынычлы сәламнәремне җибәрәм. Мин окопта үзем генә. Хәер, янымда мин кайчандыр пинцет һәм ланцет белән тунаган күптәнге дустым – бака сикергәли. Йөри бирсен, ул да җан иясе бит, аның да яшисе килә торгандыр. Чыннан да, безнең һәркайсыбызның да ЯШИСЕ КИЛӘ БИТ!..

*27 август, 1943 ел.*

Кадерле әнием, сеңелем, энекәшем, Зәйнәп апа, барча туганнарым, сезгә сагынычлы сәлам! Үзем исән-сау. Менә без тау битендә, чокырларда. Тауның теге ягында елгачык һәм немец. Нибары 700–800 м. Монда бүген иртүк патрон һәм мина ящиклары күтәреп килдек. Кичә төнлә безнең частьлар сугышка керделәр һәм берничә биеклекне алдылар. Мөгаен, бүген кич без дә сугышка керербез һәм үзебезнең автоматларны, гранаталарны сугыш кырында сынарбыз...

Үзегезнең хәлләр ничек? Ильяс, эшкә кермәдеңме әле? Мәрьям, авырмыйсыңмы, бәгырем? Әни, үзең беркөе эшләп йөрисеңме? Әйбер бәяләре төшмиме? Бәрәңгеләрегез үсәме? Барысы турында да языгыз. Энекәш, әнине борчымаска тырышыгыз. Минем өчен тыныч булыгыз. Хәзергә хушыгыз. Сезне бик каты үбеп улыгыз Мөхәммәт (*Хәрәкәттәге армия.*)»

* * *

Кадерле Укучыбыз! Бу – фидакарь җанлы, шигъри-нечкә күңелле Мөхәммәт Әхмәтгалиевның яу кырыннан якыннарына җибәргән соңгы хаты. 28 августта инде ул, бер төркем сугышчан дуслары, коралдашлары белән бергә, дошман ныгытмаларын кулга төшерү өчен җитди һөҗүмгә күтәрелә. Гитлерчыларны автомат уты белән «сыйлый-сыйлый», арысландай ярсып, Мөхәммәт һаман алга ыргыла. Инде биеклек алынды дигәндә генә, каяндыр, көтмәгәндә, дошман пулеметы телгә килә. Шул мизгелдә Мөхәммәт, янәшәсеннән генә йөгерүче рота командиры Бочкоревны күкрәге белән фашист ядрәләреннән каплап, аның белән бергә җиргә ава. Командир исән кала, ут ноктасы да тиз арада юк ителә, мөһим биеклек тә яулап алына. Әмма җиңү шатлыгын Мөхәммәт үзе генә күрә-тоя алмый инде...

Биология фәнен – Тереклек-Яшәү фәнен аеруча яраткан Мөхәммәт солдат, әнә шулай, кешелек дөньясына коточкыч афәт китерүчеләргә каршы тиңдәшсез көрәштә, туар таңнарыбыз кояшлы булсын өчен, яу кырында шәһит китә. Гәрчә яшисе бик килсә дә...

«ЯШИСЕ КИЛӘ!..» М.Әхмәтгалиевның хатларында, көндәлекләрендә бу сүзләр еш кабатлана. Әнә шул Яшәү хакына, ике дә уйлап тормыйча, ут эченә барып керә ул. Шагыйрь күңеле изге-хак эш өчен үлгәннән соң да яшәү бар икәнлеген бик яхшы тоя-сиземли...

«...ӘГӘР КАЙТА АЛМАСАМ, ОНЫТМАГЫЗ!» – диеп яза ул якыннарына фронттан җибәргән хатларының берсендә. Бу аның безгә – исәннәргә васыяте булып та яңгырый...

Россия Федерациясе Саклану министрлыгының Үзәк архивында эзләнүләр алып бару нәтиҗәсендә, М.Әхмәтгалиевның чал тарих елъязмасына мәңге балкыр ялкынлы хәрефләр белән язылган атаклы «Смоленск операциясе»ндә катнашуы ачыкланды. Әлеге операция 1943 елның 7 августыннан 2 октябрьгә хәтле дәвам итә. Совет командованиесе Көнбатыш фронтка һәм Калинин фронтының сулъяк канатына дошман армияләренең «Үзәк» группасын тар-мар итү һәм стратегик яктан зур әһәмияткә ия булган Смоленск шәһәрен кулга төшерү бурычын куя.

Генерал-фельдмаршал Гюнтер фон Клюге җитәкчелегендәге «Үзәк» группа немецларның 44 дивизиясен үзенә бер-

ләштерә (биредә барлыгы 850 меңнән артык сугышчы, 8800ләп туп һәм миномет, 500ләп танк һәм штурм туплары, 700ләп самолет исәпләнә).

Армия генералы В.Д.Соколовский җитәкчелегендәге Көнбатыш фронт, генерал-полковник А.И.Еременко җитәкчелегендәге Калинин фронтының сулъяк канатындагы гаскәрләр составына исә 1 млн. 253 мең сугышчы, 20.640 туп һәм минометлар, 1.436 танк һәм үзйөрешле орудиеләр, 1.100 самолет туплана. Менә шундый биниһая зур көч белән совет гаскәрләре дошманның «Көнчыгыш вал» дип исемләнгән үтә нык оборона сызыгының төп өлешенә биш урыннан һөҗүм итәргә тиеш булалар. Ә ул оборона сызыгы, 5–6 рәтле булып, 100–130 км эчкә сузылган. Фашистлар Велиж, Демидов, Духовщина, Смоленск, Ельня, Рославль шәһәрләрен үтеп кергесез кирмәннәргә (крепостьларга) әверелдергәннәр... (Кара: «Великая Отечественная война. 1941–1945» энциклопедиясе, М., «Советская энциклопедия» нәшрияты, 1985 ел, 658 бит.)

«Суворов-I», «Суворов-II» хәрби планнарын тормышка уңышлы ашыра барып, совет сугышчылары 7–20 август көннәрендә дошманның Спас-Деменск районындагы группировкасын тар-мар итәләр һәм 30–40 км эчкә үтеп керәләр. 28 август – 6 сентябрь көннәрендә, Ельня – Дорогобуж операциясе барышында, әлеге шәһәрләр басып алучылардан тулысынча азат ителә. Безнең гаскәрләр, Днепр елгасын кичеп чыгып, 35–40 км алга китәләр.

Духовщина–Демидов, Смоленск–Рославль операцияләре дә көткән өметләрне аклый. 16 сентябрьдә – Ярцево, 21 сентябрьдә – Демидов, 25 сентябрьдә Смоленск һәм Рославль шәһәрләре дошман кулыннан тартып алына. Совет гаскәрләре, 135–145 км эчкә үтеп, 2 октябрьдә Велиж, Рудня шәһәрләре янына һәм Проня елгасы ярына килеп чыгалар һәм шунда ныгып урнашалар...

Хәлиткеч «Смоленск операциясе» барышында безнең сугышчылар, дошманның 40 км киңлектәге оборона сызыгын өзеп, 200–250 км алга үтәләр, Калинин һәм Смоленск өлкәләренең күп кенә районнарын фашистлардан азат итәләр. Әлеге операция нәтиҗәсендә дошманны Белоруссиядән дә куу башлана.

Фашистларның 7 дивизиясе тулысынча тар-мар ителә, 14 дивизиясе авыр югалтуларга дучар була. Дошманга

Орел–Брянск группировкасындагы 16 дивизиясен Смоленск юнәлешенә ашыгыч төстә күчерергә туры килә. Шулай итеп, Көнбатыш фронт һәм Калинин фронты гаскәрләре фашистларның 55 дивизиясен үз кысаларында нык тоталар һәм моның белән совет сугышчыларына Курск янында 12 июль – 23 август көннәрендә контрһөҗүмне уңышлы тормышка ашыру өчен уңайлы шартлар тудыралар. Белүебезчә, тарихта тиңе булмаган Курск сугышы һәм Днепрны кичү вермахтның «умыртка сөяген сындыра». Фашистик Германия һәм аның союзниклары үзләре сугыш алып барган һәр төбәктә оборонага күчәргә мәҗбүр булалар. Бу исә икенче бөтендөнья сугышының алдагы барышына гаҗәеп көчле йогынты ясый. совет Армиясенең җиңүле адымнарын дошманның дагалы итекләре астында изелеп яткан илләрнең патриотлары да ишетеп, башларын күтәрәләр һәм бердәм рәвештә Каршылык хәрәкәте сафларына басалар...

Инде кыйссабызның төп каһарманы Мөхәммәт Әхмәтгалиевка килсәк, аның бу сугышта катнашуы – үзе зур батырлык. Гәрчә ул океаннан бер тамчы гына булса да, төптән уйлап карасак, олуг океанны шундый гади тамчылар яшәтә дә бит! Димәк, Ил кадәр Илне дә, иң кирәк чагында, бер кеше саклап кала ала! Рус халык әйтемен бераз үзгәртеп әйтсәк, «И один в поле воин!..»

Мөхәммәт солдатның яу кырында үз урыны, үз биеклеге булган. Һәм ул шул биеклектә фидакарьлек үрнәге күрсәтеп, сугышчан дуслары, якыннары, дуслары күңелендә бөек булып калган. Бу очракта «бөек» сүзен әйтүдән һич тә курыкмаска кирәк. Чөнки яу кырында Газраилнең күзенә туры карап үлгән һәр сугышчы бу сүзгә бик тә лаек. Бөек Ватан сугышында бары тик рухлары белән бөек булганнар гына җиңеп чыккан! Гәрчә тигезсез көрәштә һәлак булсалар да... Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин әйтмешли, «Үлемнәре белән үлемсезлек яулаган» мөхтәрәм шәхесләр алар!

Ә андый гаярь җаннар онытылмый. Мөхәммәт Әхмәтгалиевның да данлы исеме заманында үзе эшләгән предприятиедәге, Татарстан Язучылар берлеге һәм Татарстан китап нәшрияты биналарындагы мәрмәр такталарга алтын хәрефләр белән уеп язылган. Киләчәктә Казан дәүләт педагогика университетының биология факультеты бинасында куелачак «Хәтер» мемориалында да аның исеме лаеклы урынын алыр, шәт...

Сугыштан соң, М.Әхмәтгалиевның яшьлек дуслары Гарә-

фи Хәсәнов, Җәвад Тәрҗеманов, бертуганнары Мәрьям һәм Ильяс Әхмәтгалиевлар Мөхәммәтнең шигырь китапларын чыгару хәстәрен күрәләр. 1957–1960 еллар арасында Татарстан китап нәшриятында аның балаларга атап язылган «Балык тотканда», «Тегүче куян», «Елак батыр» дигән китаплары басыла. М.Әхмәтгалиевнең берничә шигыре «Татар поэзиясе антологиясе»нә (1956) һәм «Татар балалар антологиясе»нә (1980) дә кертелә.

Күренекле язучы һәм галим, Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе Җәвад Тәрҗеманов (1920 – 1995) сабакташы Мөхәммәтнең якты истәлеген мәңгеләштерү юнәлешендә аеруча нәтиҗәле эшли. 1966 елда ул Татарстан китап нәшриятында «Ян, йолдызым, ян!..» исемле китабын дөньяга чыгара. Әлеге китап аша без Казан шәһәренең данлыклы 13 нче мәктәбендә белем-тәрбия алып, республика-ил, дөнья күләмендә танылган шәхесләрдән Мәскәүдәге Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университеты җитәкчеләренең берсе – олуг галим Габделхак Галиуллин, физика-математика фәннәре докторы, атом энергиясе турында татарча язылган китаплар авторы Мәхмүт Зарипов, кибернетика буенча зур белгеч, профессор Ильяс Әхмәтгалиев, атказанган табиблар Фәрит Сафин, Һаҗәр Җаббарова, мөхтәрәм прокурор Равил Хәсәнов, әдәбият-сәнгать әһелләреннән СССРның халык рәссамы, академик Харис Якупов, Россия Федерациясенең халык рәссамы Лотфулла Фәттахов, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай премиясе лауреаты Ибраһим Гафуров, артист-драматург Сәлах Хөсни, язучылардан Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Гарәфи Хәсәнов, Җәвад Тәрҗеманов һәм башкаларның яшьлек елларындагы кызыклы һәм мавыктыргыч эшләре белән танышабыз. Шунысы аеруча сокландыра: әлеге яшүсмерләрнең һәркайсы мәктәптә укыганда шигырьләр яисә хикәяләр язган, шуның өстәвенә кайберәүләре рәсем ясарга да һәвәс булган. Аларның әдәбият түгәрәгенә исә иң элек Һади Такташ, аннары Фатих Кәрим җитәкчелек иткән! Яшь иҗатчылар янына кунакка Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Ләбиб Гыйльми, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни һ.б. еш килеп торганнар. Укучыларның җентекле тикшерүләрдән соң иң яхшы дип табылган шигырьләре һәм хикәяләре иң элек мәктәпнең «Әдәбиятчы» газетасына, аннары «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») жур-

налына һәм «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасына тәкъдим ителгән. Тора-бара яшь иҗатчылар Татарстан китап нәшриятында «Шат балалык» исемле шигырьләр һәм хикәяләр җыентыгын да бастырып чыгаруга ирешәләр. Аңа түгәрәк эшендә аеруча актив катнашучы Гарәфи Хәсәнов, Габделхак Галиуллин, Мәхмүт Зарипов, Җәвад Тәрҗеманов, Лотфулла Фәттахов, Һаҗәр Җаббарова, Нури Вафин, Фәрит Сафин, Равил Хәсәнов һәм, әлбәттә инде, бертуган Мөхәммәт һәм Ильяс Әхмәтгалиевларның иң әйбәт әсәрләре тупланып бирелә. Китапның редакторы кайчандыр шушы мәктәптә укып, Һ.Такташ түгәрәгенә йөргән Зәкия Садыйкова була.

1934 елның 25 июлендә Казанда Татарстан совет язучыларының беренче корылтае (съезды) ачыла. Анда 13 нче мәктәпнең ике укучысы – Габделхак Галиуллин белән Гарәфи Хәсәнов та мандатлы делегатлар булып катнашалар. Аларның шул олы җыенда ясаган чыгышларын башкалабызга кунак булып килгән атаклы язучы Максим Горький да зур игътибар белән тыңлый һәм шул уңайдан «Правда» газетасының 8 август санында күләмле мәкаләсен дә бастыра...

Хаклык өчен шунысын да әйтик: әлеге мәктәпнең иң талантлы укучылары арасында Мөхәммәт Әхмәтгалиевның үзгә урыны бар. Аны сыйныфташлары «Маяк» дип атап йөрткәннәр. Ә маяк, билгеле булганча, дөрес юл күрсәтүче, нур сибүче, күңелләрне җылытучы...

Әнә шуңа күрә дә инде Җәвад Тәрҗеманов та үз китабында сабакташ дустын бик еш телгә ала, аңа сүзләрдән һәйкәл коя, якты образын мәңгеләштереп куя. Ошбу мәҗмуганың тәүге битенә «Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган кадерле дустым шагыйрь Мөхәммәт Әхмәтгалиевка багышлыйм» дигән йөрәк түреннән ургылып чыккан ихлас сүзләрен язып, илаһи дуслыкка гомере буе тугры булачагын укучыларына да сиздерә автор...

1992 елның июнь аенда Мәскәүдә СССР язучыларының IX (соңгы) съезды булып үтте. Анда Татарстанның бер төркем әдипләре белән бергә, делегатлар буларак, Җәвад Тәрҗеманов һәм мин дә катнаштым. Мәскәүгә баручы «Татарстан» поездында безнең урыннар бер купега туры килде. Менә шунда без аның белән иркенләп, күңелләр булганчы сөйләштек. Ни хикмәттер, сүз күбрәк яу кырында ятып калган каһарман язучылар турында барды. Җәвад ага сыйныфташы Мөхәммәт Әхмәтгалиевны кат-кат телгә алды:

– Искиткеч талантлы, әкияти асыл егет иде! Әгәр дә ул бүген исән булса, үзен балалар әдәбиятын әйдәп баручы чын каләм әһеле, халык шагыйре итеп танытыр иде. Бари Рәхмәтләр, Шәүкәт Галиевлар, Илдар Юзеевлар, Роберт Миңнуллиннар кебек!..

Аннары ул Мөхәммәт дустына багышлап яңа әсәр яза башлавы турында сөйләде... Һәм ул әсәр – «Ахирәт дустым турында баллада...» диеп исемләнгән документаль композиция-либретто – М.Әхмәтгалиевның тууына 75 ел тулган чорда «Ялкын» журналының 1995 елгы апрель – май саннарында дөнья күрде. Тик – ни кызганыч! – Җәвад ага аның басылып чыкканын үзе генә күрә алмады – кинәт вафат булды...

Үзенең үләсен алдан сизенгәндәй, ул без эшләгән «Казан утлары» журналы редакциясенә соңгы килүләренең берсендә:

– Әле минем сине Мөхәммәтнең бертуган сеңелесе – искиткеч матур күңелле, кешелекле Мәрьям ханым Әхмәтгалиева белән якыннанрак таныштырасым килә,– дигән иде.– Сабакташымның бай архивын, фоторәсемнәрен, хатларын, көндәлекләрен, басылып чыкмаган әсәрләрен бик кадерләп саклый ул. Энесе Ильяс та шундый мөхтәрәм шәхес иде, урыны оҗмахның түрендә булсын, амин! Киләчәктә, шулардан файдаланып, бәлкем, Мөхәммәт Әхмәтгалиев турында күләмле әсәр язарсың. Сизеп-күреп торам бит, син безнең фронтовик язучыларга карата һич кенә дә битараф түгелсең...

«Бирим дисә колына – чыгарып куяр юлына» дигәндәй, без Мәрьям ханымнар фатирына барырга җыенган арада, көннәрдән бер көнне редакциябез ишеген ул үзе шакыды. Чыннан да, сөйкемле-нурлы ханым икән. Күптәнге танышлардай, аның белән уртак телне тиз таптык. Бераздан Мәрьям ханым безнең алга машинкада басылган бер көлтә язмалар китереп салды:

– Болары – абыем Мөхәммәтнең сугышка хәтле язып барган көндәлекләреннән күчермәләр, ә менә мондагылары – фронттан язган хатлары... Шуларны журналыгызда бастырып булмасмы, Шаһинур энем?!

– Иң элек алар белән танышып чыгыйк әле, яме, Мәрьям ханым. Аннары фикеребезне әйтербез. Килештекме?!

Ул, ризалыгын белдереп, йөзен балкытып елмайды...

М.Әхмәтгалиевның көндәлекләрен, хатларын иң элек үзем, өебезгә алып кайтып, зур кызыксыну белән, бер тында укып

чыктым. Таң атканын да сизми калганмын – шулкадәр мавыктыргыч итеп язылган алар!

Мөхәммәт каләмдәшебезнең ихласлыгы, эчкерсезлеге, әтиәнисенә, туганнарына, якыннарына, дусларына карата булган олы кайгыртучанлыгы – мәхәббәте, һәрвакыт ярдәмгә килергә ашкынып торуы тирәнтен сокландырды, тетрәндерде мине...

Әлбәттә, аның әлеге язмалары, һичшиксез, дөнья күрергә тиеш! Аларда – шул чор яшьләренең кайнар сулышы, дәртле йөрәк тибеше, изге уй-хыяллары, якты өметләре...

Мәрьям ханымга абыйсының язмалары турында уңай фикеремне әйтеп шылтыраткач, ул, бик шатланып, үзләренең фатирларына кунакка чакырды. Башкалабызның Зур Кызыл урамындагы биш катлы йортларның берсендә торалар икән. Ире Фатыйх абый да, Мәрьям апа кебек, ачык күңелле кеше булып чыкты. Мул сыйлы түгәрәк табын янында иркенләп сөйләшеп утырдык ул көнне. Безнең җанлы әңгәмәбезне ихлас күңелдән хуплагандай, өй түрендәге зур портретыннан Мөхәммәт Әхмәтгалиев елмая төшеп карап торды. Мәрьям ханымнарга аны абыйсының сабакташ дуслары – мәшһүр рәссамнар Харис Якупов белән Лотфулла Фәттаховлар махсус ясап бүләк иткәннәр икән...

Мөхәммәт Әхмәтгалиевның архивы, чыннан да, шактый бай булып чыкты. Энесе Ильяс вакытсыз вафат булганнан соң, анда сакланган кайбер язмаларны да үзенә алдыру чарасын күргән Мәрьям ханым. Тик, ни кызганыч, архивның бер өлеше, Ильяс әфәнделәрнең дачаларында булган көчле янгын нәтиҗәсендә көлгә әйләнгән...

– Мөхәммәт абыебызның бездә булган бар язмаларын, рухи байлыгын, матбугат-нәшриятлар аша, халкыбызның күңел түренә җиткерәсе иде,– диде Мәрьям ханым, безнең белән саубуллашканда.– Иң зур теләгем һәм максатым шул минем...

М.Әхмәтгалиевның көндәлекләрен һәм хатларын тиз арада гына «Казан утлары»нда чыгарып булмады, чөнки журналның алдагы саннары инде ныклап планлаштырылып, тиешле материаллар бастыру өчен нәшрият цехларына җибәрелгән иде. Мәрьям ханым китергән язмаларны дөньяга чыгару өчен ким дигәндә тагын ярты ел көтәргә кирәк...

Бу юлы да безгә бәхет елмайды. Газета-журналлар нәшриятының унынчы катында безнең белән янәшә бүлмәдә генә эшләүче «Казан» журналының баш мөхәррире Юрий

Анатольевич Балашов һәм аның урынбасары Рушания ханым Камалова көннәрдән бер көнне:

– Сездә Бөек Ватан сугышы темасына багышланган, басылырга чират көтеп ята торган материаллар юкмы? – дип мөрәҗәгать иттеләр.– Хәрби темага багышлап махсус сан чыгарырга уйлаган идек...

Үзара киңәшкәннән соң, М.Әхмәтгалиев язмаларын әлеге журналга бирергә булдык. Һәм ул тиз арада «Казан»ның 1996 елгы 1–2 нче кушма саннарында татарча басылып та чыкты. «Әгәр кайтмый калсам, онытмагыз...» дигән баш астында бирелгән ул язмалар журналның кырыкка якын битен иңләп тора иде. Өстәвенә анда фронтовик шагыйрьнең фоторәсеме, үз кулы белән язган хат үрнәкләре, шигырьләре, әти-әнисенең, бертуган сеңелесе һәм энесенең, алар яшәгән йортның, каләмдәш дусларының сурәтләре дә бар иде. М.Әхмәтгалиевның басылган китапларын һәм аның шигырьләре кергән җыентыкларны бергә туплап фоторәсемгә төшерүдә безгә үз эшенең чын остасы – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт ага Шакирҗанов ихлас булышлык күрсәтте...

Бөек Ватан сугышында 23 яшендә гомер җыры өзелгән гвардияче абыем Миннегаян Ибраһимовның (әниемнең бертуганы ул!) чордашы-яшьтәше булган Мөхәммәт Әхмәтгалиев миңа ничектер бик тә якын, кадерле булып китте. Шуннан соң да аның турында төрле газеталарда шактый язмалар бастырдым. Газиз милләттәшләребез яшәгән байтак төбәкләргә таралучы «Татар иле» газетасының 2001 елгы июнь–июль саннарында Мөхәммәт каләмдәшебезнең хатларыннан, көндәлекләреннән тагын өзекләр бирдек...

Хәзер инде аларны тулы килеш чыгарырга ныклы әзерлек эшләре алып барабыз. Булачак җыентыкта М.Әхмәтгалиевның мәктәп чорында язган шигырьләре, көндәлекләрендәге язмалар да урын алачак. Фронттан язган хатлары да бернинди кыскартуларсыз басылачак. Шулай ук аның инде дөнья күргән шигырьләрен дә бергә туплап бирәчәкбез, Аллаһы боерса! Бары тик саулык-сәламәтлектән, иминлектән генә аермасын, Яшәү утларын гына сүндермәсен Ходай...

...Әлеге юлларны язып утырган кояшлы иртәдә иҗат бүлмәмә, йөгереп, өченче оныгым Җәмилә килеп керде. Аның сабан тургаедай үз телендә матур итеп сайравы яшәүгә булган якты омтылышымны тагын да көчәйтеп, рухи дөньямны

ямьләп җибәрде. Әйе, безгә вакытсыз үлгәннәр өчен дә яшәргә, алар турындагы ихлас-чын сүзне меңнәр, миллионнар йөрәгенә җиткерергә кирәк!..

## КАЙТАВАЗЛЫ БАЛКЫШ

Үзенең туган төбәгенә бөтен барлыгы белән гашыйк, чын ватанпәрвәр, ихлас күңелле дустым – хәзерге вакытта Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология кафедрасы деканы, филология фәннәре докторы Васил Заһит улы Гарифуллин, Теләче районының Олы Кибәхуҗа авылына кунакка кайткач, миңа бер гыйбрәтле вакыйга турында сөйләгән иде:

– ...Әнә күрәсеңме, авыл уртасында балкып, иман нуры сибеп утыручы мәһабәт мәчетне?! Утызынчы елларда, шул чор шаукымына ияреп, кайбер куштаннар, «диннең төбен-тамырын корытабыз» дип, аның манарасын кисәннәр. Манара ыңгырашып-гөрселдәп җиргә аугач, аның Ае күршедәге бер апаның ишегалдына «сикергән». Ә ул апа бик тә изге күңелле, үтә динле-денле кеше булган: шул Айны – чит-ят күзләр күргәнче дип – тиз арада! – үзе генә белгән җиргә яшереп тә куйган. Күпме генә эзләсәләр дә, көмеш Айны таба алмаганнар «кара йөрәкләр»... Дистәләрчә еллар үткәч, саф-җылы җилләр исә башлагач, шул иске, әмма шактый таза мәчеткә яңа манара торгызганда, әлеге Айны теге апабыз авыл аксакалларына китереп тапшыра. Шулай итеп, яңадан үз урынына менеп утыра тылсымлы-горур Ай!..

Бөек Җиңүнең чираттагы еллыгын зурлап билгеләп үткән көннәрдә, Васил каләмдәшемнең шул сүзләрен күңелемдә тагын яңарттым. Ни өчен дигәндә, үзенең иманына-кыйбласына гаять тугрылыклы әлеге авыл халкы, бер үк вакытта, йөрәгендәге Хәтер Утын да һич сүндерми-сүрелдерми саклый икән! Шулай булмаганда гади бер егетнең – моннан алты дистә ел элек Бөек Ватан сугышында һәлак булган Морат Мостафинның якты исемен авыл мәктәбенә кушарлар идемени?! Өстәвенә әле бу эш – кыласы изге гамәлләрнең башы гына икән... Хәер, барысын да үз тәртибе белән сөйлик әле...

Иң элек укучыларыбыз күңелендә кызыксыну уяткан «Морат Мостафин кем ул?» дигән сорауга җавап биреп үтик...

## 1. Хәтердә гел яши Батырлык!..

Моннан байтак еллар элек безнең кулга ерак Украинадан җибәрелгән искиткеч кызыклы хат – Җөмһүриятебезнең Теләче районында туып үскән мөгаллим, журналист, политрук һәм Бөек Ватан сугышы партизаны Морат Мостафин турында дулкынландыргыч язма килеп кергән иде. Әлеге кадерле истәлекләрнең авторы – ике тапкыр Советлар Союзы Герое, генерал-майор С.А.Ковпак (1887–1967) җитәкчелегендәге партизаннар берләшмәсендә хезмәт иткән политрук, сугыштан соң Украина ССРның Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгында җаваплы вазифа башкарган Л.Е.Кизя булып чыкты. Министр урынбасары безгә Татарстан белән Украинаның уртак горурлыгы булып әверелгән якташыбыз турында түбәндәге хатирәләрен юллаган иде:

«...Легендар Сидор Артемьевич Ковпак җитәкчелек иткән партизаннар берләшмәсендә иң яхшы группа командирларыннан саналган Морат Әхмәтсафа улы Мостафин 1942 елның 25 маенда дошманга каршы көрәштә батырларча һәлак булды. Татарстанның Теләче районы Олы Кибәхуҗа авылында туган бу ир-егет – данлыклы татар халкының һәм бөтен совет халкының тугрылыклы улы иде.

Мин М.Ә.Мостафинны яхшы белә идем, аның белән бергә күп мәртәбәләр фашистларга каршы көрәштем. Морат Әхмәтсафа улы кыю, Ватан-Анага чиксез бирелгән егет иде. Ул, Алтын Йолдызы булмаса да, чын герой иде!

Бу турыда М.Ә.Мостафинның туганнарына хәбәр итүегезне үтенәм һәм дустым турында белгән-күргәннәремне язып җибәрәм.

...Морат Әхмәтсафа улын Кролевецкий партизаннар отрядына 1942 елның апрелендә кабул иттеләр. Элеккеге политрук тиз арада үз кеше булып әверелде. Дошманга каршы үткәрелгән берничә операция барышында үзен аеруча тәвәккәл, ышанычлы, оста оештыручы итеп таныткач, Мостафинны группа командиры итеп билгеләделәр. Моңа җавап итеп, Морат дустыбыз, үзенең сугышчан иптәшләре белән, дошман тылында яңадан-яңа батырлык үрнәкләре күрсәтте, фашистларга һич кенә дә тынгылык бирмәде...

1942 елның Беренче Май бәйрәмен партизаннар тантаналы төстә билгеләп үттеләр. Иске Гута авылында уздырылган партизаннар хәрби парадында Морат Мостафин да кат-

нашты. Парадны берләшмә командиры С.А.Ковпак һәм комиссар С.В.Руднев кабул итте. Киселгән агач төпләренә баскан килеш алар пехотачыларны, артиллеристларны, кавалеристларны Беренче Май бәйрәме белән кайнар котладылар.

Бердәм «Ура!» тавышлары тыну белән, тынгылык белмәгән командир партизаннар алдына яңа бурыч куйды: «Украина җирендә дошман тылына тирән рейд ясарга!» Язгы юлсыз вакыт иде: ни арба, ни чана йөрми. Шулай да май урталарында Ковпак партизаннары, дошманнар белән сугыша-сугыша, борынгы Путивль шәһәренең стеналары янына килеп җиттеләр...

24 майда, коеп яуган яңгыр астында, күзгә төртсәң дә күренмәслек төнге караңгыда, Сумы өлкәсенең Литвиновичи авылына кердек. Авыл халкы партизаннарны ачык күңел белән каршы алды. Шунда безгә Иске Шараповка авылына урнашкан дошман гарнизонын тар-мар итәргә фәрман килде. Инде мәгълүм хәбәрләр буенча, анда яхшы коралланган ике йөзләп дошман солдаты һәм офицеры булырга тиеш иде. Ә безнең партизаннарның саны аларның яртысы кадәр дә юк иде диярлек.

– Кинәттән һөҗүм итәбез! – диде отряд командиры Василий Кудрявский.– Искәрмәстән һөҗүм итәбез икән, бу инде –ярты җиңү дигән сүз!..

Яңгыр һаман коеп ява иде. Алдыбызда – Клевань елгасы. Төн инде таңга авышты. Иртәнге 3 ләр чамасы. Сызылып 25 майның таңы беленде. Шул яктыда – алда – Иске Шараповка авылындагы йорт-каралты күләгәләре күренә башлады. Елга аша җәяүләп кенә чыгарлык иске күпер бар иде. Дошман, партизаннар һөҗүм итәсен белгәндәй, елга ярларына миналар куйган икән – кинәт бик көчле шартлау тавышы яңгырады. Һава дулкыны дистәгә якын партизанны җиргә екты, туфрак катнаш мина ярчыклары әллә кайларга чәчрәде! Берничә партизан һәм отряд комиссары Онойченко шунда мәңгегә ятып калды...

Шартлау тавышыннан дошман гарнизоны аякка басты. Искәрмәстән һөҗүм итү планы юкка чыкты.

– ...Шулай да приказны кичекмәстән үтәргә кирәк! – диде командир һәм безне һөҗүмгә алып китте.

Көн яктыргач, яңгыр туктады, күк аязды. Офык тирәсендә сирәгәеп калган болытлар чыгып килүче кояш нурларыннан кан төсенә керде.

Иртәнге тынлыкны пулемет тыкылдавы бозды, минометлар дошман өстенә мина яудырырга тотындылар, өстебездән дошман ягына Ковпак артиллериясе снарядлары очты.

Ләкин дошман партизаннарны бар төр коралларыннан ут ачып каршы алды. Аяусыз сугыш кызганнан-кызды. Тиздән безнең сирәгәйгәннән-сирәгәя барган сафларыбыз чигенә башлады. Дошман безне урманга кысты. Ә урман – партизаннар оясы (крепосте), анда дошманнарга хакимлек итәргә юл куярга ярамый. Шулаен шулай да, ләкин... көчләр тигез түгел.

Сугыш кызганнан-кыза барды. Дошманнар инде безне камап алып, тәмам тар-мар итеп бетерер кебек иде...

Шул вакыт кинәт дошман солдатлары арасында безгә аңлашылмаган ниндидер тәртипсезлек башланды. Немец солдатлары һөҗүм иткән җирләреннән кинәт ни алга, ни артка йөгерергә белмичә аптырап, каушап калдылар, дистәләгән дошман, берьюлы диярлек, җиргә тәгәрәде. Гүя әкиятләрдә генә була торган ниндидер көч, безгә ярдәм итәргә теләп, гитлерчыларны үзенең дәһшәтле сулышы белән өтә, яндыра кебек иде.

Моның сәбәбен тикшереп торырга вакыт юк иде. Партизаннар шундук дәртләнеп киттеләр – пулеметчылар, минометчылар, уңайлырак позицияләр сайлап, дошманга көчле, бердәм ут ачтылар. Дошман солдатлары кырга сибелде. Безгә шул гына кирәк – тигез болын өстендә алар уч төбендәге кебек иде. Немецлар Иске Шараповка авылына чигенергә мәҗбүр булды. Урманда, кырда һәм яр буйларында аларның йөздән артык үле гәүдәләре аунап калды. Бик күп коралларны да кулга төшердек...

Бу тигезсез сугышта безгә җиңү китергән төп сәбәпче кем, нәрсә булды соң? Без моны соңыннан гына белдек.

...Морат Мостафин, урман арасыннан үрмәләп, дошманның тылына чыга. Немец пулеметчысын атып үтерә дә, аның коралыннан һөҗүм итүче дошман сафларына төбәп, ут ача.

Партизаннарның бу җитди операциясен уңышлы башкарып чыгуга Морат Мостафинның кыюлыгы гаять зур ярдәм итте. Ләкин безнең шатлык озакка бармады: сугышның соңгы минутларында кадерле дустыбызны – батыр Моратыбызны дошман ядрәсе безнең арабыздан алып китте...

Һөҗүм башланыр алдыннан гына, Морат миңа, сугыштан соң Сумы өлкәсенең Урта Буд районындагы Красичка авылына барып, авыр минутларда үзенә ярдәм кулы сузган

украинлы дусларына рәхмәт белдерәсе килүен әйткән иде. Ләкин бу теләген тормышка ашыра алмады ул – Украина җирләрен азат итү өчен барган изге сугышта шәһит китте...

Каһарман Морат Әхмәтсафа улы Мостафинны партизаннар берләшмәсенә нигез салынган тарихи Спадшань урманына – Туганнар каберлегенә күмдек.

– Ватан Сине бервакытта да онытмас, Морат! – диде командирыбыз Кудрявский.– Партизанга, сугышчыга, коммунистка, чын кешегә мәңгелек дан!

Партизаннар, винтовкалардан, пистолетлардан атып, өч тапкыр салют бирделәр. Залп тавышлары урман эчендә, батырлык кайтавазы булып, озак яңгырап торды...»

* * *

Инде хәзер Морат батырның үзенә һәм аның якыннарына сүз бирик.

## 2. М.Мостафинның соңгы хаты

*«Дошман тылыннан хат.*

*Исәнмесез!*

*Барыгызга да сагынып кайнар сәлам! Күрше-күлән, кардәш-ыруларның барчасына да сәлам, диярсез. Сәлам соңында шул: үзем хәзергә исән-сау. Менә нәкъ сигез айдан соң сезгә хат язарга мөмкинлек алдым. Үзем, узган елның октябреннән бирле, дошман тылында фашист этләренә каршы көрәшне дәвам иттерәм. Көннәр җылыну белән безнең эшчәнлек аеруча җанланып китте. Партизан отрядыбыз көннән-көн йөзләгән кадрлар белән тулылана бара!*

*Фашистларны көннәр һәм төннәр буенча кыра бирәбез, кая кереп посарга урын таба алмыйлар. Без алар хисабына коралланабыз, туенабыз һәм киенәбез. Ләкин ул кара җаннар хатын-кыз һәм бала-чагаларны бик күп үтерәләр. Әлегә без булмаган төбәкләргә барып чыгып, авылларны, барлык халкы белән бергә, утта яндыралар... «Партизан» исеме аларның йөрәкләренә инә урынына кадала...*

*Шулай итеп, без көрәштә көннән-көн чыныга киләбез. Тәҗрибә арта, эшебезнең хаклыгына, җиңүебезгә ышаныч көннән-көн ныгый. Ярый, хуш, сау булыгыз (без хәзергә Украинаның Сумы өлкәсендә). Барыгызга да яхшыдан-яхшы теләкләр теләп калам. Тигез-тату, матур яшәгез һәм нык ыша-*

*ныгыз: дошман якын киләчәктә безнең җиребездән үзенең соңгы сөякләрен алып качар. Шул чагында без дә ерак тылдан үзебезнең туган Кызыл Армиябезгә кайнар котлау сүзләрен юлларбыз! Рәхмәт – шул якты көнне якынайту өчен, картлар да, хатын-кызлар да, бала-чагалар да, бар да безгә бик теләп булышалар...*

*Тирән дошман тылында сезне сагынып хат язучы, еракта торып булса да кулыгызны яратып кысучы улыгыз – партизан Морат. Хушыгыз! 2.V.42 ел».*

## 3. Батырның бертуган сеңлесе Ләбибә ханым Мостафина-Умерова истәлекләреннән

«...Әтиебез – Әхмәтсафа Мостафин – укытучы иде. Пенсиягә чыкканның соңында үзебезнең Олы Кибәхуҗа авылында башта – агротехник, Бөек Ватан сугышы башлангач – колхоз председателе булып эшләде. 1943 ел җәендә авырып үлде. Әниебез – Зәйнәпбикә Мостафина – озак еллар безнең янда, ягъни кияве Тәүфыйкъ Умеров һәм кызы тәрбиясендә Әстерхан шәһәрендә яшәп, 1969 елда вафат булды. (82 яшендә иде кадерле кешебез, авыр туфрагы җиңел булсын!)

Морат абыем 1916 елның 14 июлендә Олы Кибәхуҗа авылында туган. Техникум тәмамлагач, берничә ел укытучы булып эшләде – Саурыш, Олы Кибәхуҗа һәм Югары Кибәхуҗа авылларында балалар укытты, исеме һәрчак мактаулылар рәтендә йөрде. Аннан соң аны, мәкаләләр, шигырьләр язарга һәвәслеген, кешеләр белән тиз аралашучанлыгын күреп, Теләче районы газетасына эшкә алдылар. Армиягә дә Морат абыем шуннан китте.

Аңарчы өйләнеп тә өлгергән иде. Махсус курсларда белемен күтәргәннән соң, политрук урынбасары булып хезмәт итте абыебыз. Аның турында авыл советына, колхоз идарәсенә, өебезгә берничә мәртәбә мактау хатлары да килде... Бик тырыш иде шул Морат абый!..

Сугышның башыннан ук абыемны фронтка җибәрделәр. Озак вакытлар хат-хәбәре килми торды. Ниһаять, аның 1942 елның 2 маенда язган хатын алдык. Әлеге кош теледәй хат яраткан абыебызның безгә соңгы сәламе һәм изге васыяте дә булган икән...

Морат абыемның ул хатына каршы җавап та язган идем. Әмма минем хат барып җиткәндә, кадерле кешебез инде...

Хатымның буш калган урынына партизаннар отряды командиры абыемның батырларча һәлак булуы турында берничә җөмлә язган иде.

Шуннан бирле Морат абыебыз турында бер хәбәр дә ишеткәнебез юк иде әле...

Ерак Украинадан якын-газиз кешебез турында килгән яңа хат-хәбәр безнең һәммәбезне – Морат абыемның хәләл җефете, мөгаллимә Миңнемаһруй җиңгине, бердәнбер кызы Флүрәне, барлык туганнарны гаять нык шатландырды. Без Морат абыебызның яшьтән үлеп китүенә (нибары 26 ел яшәп калды бит ул фани дөньяда!) бик кайгырып еласак та, аның фашистларга каршы сугышта күрсәткән батырлыклары турында ишетеп-укып, тирән дулкынлану, горурлык хисләре кичердек!

Абыебызны бик җылы итеп искә алып, аның Туган илебезнең азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен барган изге көрәштә ничек һәлак булуы, соңгы батырлыгы турында чын дөреслекне язып җибәргән украин дустыбыз Л.Е.Кизяга туганнарча кайнар рәхмәтебезне һәм чиксез ихтирамыбызны белдерәбез...»

* * *

...Әйе, украин дуслар татар егете Морат Мостафинның батырлыгын онытмыйлар. Сумы өлкәсенең Путивль шәһәреннән 12 чакрым ераклыктагы Спадшань урманында, матур бер аланлыкта аңа мәрмәрдән һәйкәл куелган. Истәлек өчен шул һәйкәлнең фоторәсемен дә җибәргәннәр ерактагы якын дуслар Морат батырның гаиләсенә. Өстәвенә кунакка да чакырганнар, «Путивль шәһәрендәге крайны өйрәнү музеенда әтиегезгә кагылышлы стенд белән дә таныштырырбыз»,– диеп язганнар алар Флүрә ханымга...

## 4. Мәктәбенә кайтты батыр!..

Бәхеткә, якташлары да онытмый Морат дигән чын каһарманны!

Заманында ул укыган һәм укыткан Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбенә аның исемен бирдерү турында да күпләр кайгырткан. Әлеге авыл кияве – исеме югарыда телгә алынган мөхтәрәм профессор Васил Гарифуллин, заманында М.Мостафин чакыруы буенча Теләче район газетасына эшкә килгән һәм аның хәер-фатихасы белән тормышта үз юлын тап-

кан икенче бер зур шәхес – Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, философия фәннәре докторы, Ш.Мәрҗани исемендәге премия лауреаты Яхъя ага Абдуллин, район мәгариф бүлеге мөдире Мансур Газизов, батырларыбызның якты истәлекләрен мәңгеләштерү белән дә шөгыльләнүче яшь туристлар станциясе директоры Хәләф Нуретдинов, авылның үтә дә тынгысыз, эзләнүчән мөгаллимәләре Наилә Мөхәммәдиева, Гамбәрия Нигъмәтҗанова, Кече Кибәхуҗа урта мәктәбе директоры Миннәхмәт Биктимеров һәм башкалар – әнә шундыйлардан. Теләче районы хакимияте башлыгы, Татарстан халык депутаты Илдар әфәнде Низамов та аларның бу изге теләген ихластан хуплаган һәм шул хакта тиешле карарны чыгарып та өлгергән!..

Мәктәпкә Морат батыр исемен бирү тантанасына Казаннан да байтак кунаклар чакырылган иде. Шулар арасыннан каһарманның хәләл җефете Миннемаһруй ханым, кызы Флүрә ханым, кияве Нуретдин ага, аларның балалары Сания белән Марат, кияүләре Илдус, киленнәре Гөлшат, оныклары Илсур белән Азат, Айдар белән Айрат һәм башка туганнары-якыннары аерым бер игътибар-ихтирам үзәгендә булды. «Хәтер яктысы» дип исемләнгән бу очрашу барышында Морат батыр турында бихисап җылы сүзләр әйтелде, истәлекләр яңартылды. Васил әфәнде белән Мәдинә ханым Гарифуллиннарның музыкант уллары – гармунчыларның Ф.Туишев исемендәге республика конкурсы лауреаты Илназ Гарифуллин исә авыл халкына Морат батыр аеруча яраткан көйләрне уйнап күрсәтте...

Ахырдан, җыенның уртак фикерен чагылдырып, авылның иң абруйлы кешеләреннән берсе – Татарстанның атказанган механизаторы Гомәр ага Заһидуллин эшлекле тәкъдим белән чыкты:

– ...Бөек Җиңүнең 60 еллык юбилеен исә каһарман якташыбыз Морат абый Мостафинга һәйкәл куеп каршылыйк, җәмәгать!.. Мәктәбебез ишегалдын нурландырып торсын ул... Без украинлы дусларыбыздан киммени?!

Алдынгы мөгаллимнәрне, үткен каләмле журналистларны бүләкләү өчен районда М.Мостафин исемендәге махсус премия булдыру, Морат батыр призына спорт ярышлары үткәрү турында да кызыклы фикерләр әйтелде җыенда...

Шунысы куанычлы, әлеге тәкъдимнәр район хакимияте башлыгы күңелендә дә теләктәшлек тапты...

Уртак фикергә килүгә сөенгәндәй, авыл өстендә, яшен яшьнәп, күк күкрәде, җылы яңгыр явып үтте. Бераздан соң, күңелләрне илаһи-серле нурларга төреп, тирә-юньне сафландырып, салават күпере балкыды. Кеше җаны нурлардан яратылган, диләр бит. Салават күпереңнең дә бер башы еракта Украинаның Спадшань урманнарыннан башланып, икенче башы Татарстанның нәкъ менә шушы Олы Кибәхуҗа авылы мәктәбенең ямьле ишегалдына төшкәндер дә Морат батырның җаны, кайтавазлы балкыш булып, авылдашларының хәл-әхвәлләрен белергә, рәхмәт әйтергә кайткандыр кебек тоелды миңа бу истәлекле мизгелдә...

## ҖӘЛИЛЧЕ-МАКИЗАР[1]

Җай чыккан саен, Яңа бистәдәге Татар зиратында булырга тырышам мин. Мәркәзебез Казанның хатирәләрне яңарта торган гыйбрәтле вә изге урыннарының берсе ул. Биредә милләтебезнең йөзек кашлары булган бихисап олуг шәхесләр үзләренә мәңгелек сыену урыны тапкан. Араларында үзем белгән, якыннан аралашкан күренекле әдәбият-сәнгать әһелләре дә, хәрби эшлеклеләр, сугыш һәм хезмәт каһарманнары да байтак. Зират аллеялары буйлап йөргәндә, аларның каберләре алдында тез чүгеп, башымны иеп, кулларымны күкрәк-йөрәк турысына куеп, үзем белгән догаларны укыйм...

Монда горур җанлы җәлилче-макизар Әмир Галимҗан улы Үтәшев тә (1919–1996) үзенең мәңгелек урынын алган. Генерал-майор Юныс Ибәтуллин кебек фидакарь хәрби эшлеклеләр, Таҗи Гыйззәт, Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Рәшит Ваһапов, Ильяс Әүхәдиев кебек халкыбызның олуг мәхәббәтен казанган әдәбият-сәнгать осталары, Гыйлем Камай, Рәфгать Таһиров кебек киң танылган галимнәр янәшәсендә ята ул.

...Аның белән мине туксанынчы еллар башында атаклы җәлилче якташым – нәсел тамырлары белән Мамадыш өязенең Өскебаш төбәгеннән булган мөхтәрәм Рушад ага Хисаметдинов таныштырган иде:

– ...Франциядә фашистларга каршы көрәштә зур батыр-

[1] Макизар – француз партизаны.

лыклар күрсәткән легендар шәхес ул Әмир абыең!.. Озак еллар дәвамында хаксызга рәнҗетелгән, «онытырылган» чын каһарманнарыбызның берсе... Әйдәгез әле, бергәләшеп, күтәрик әле үзен – кайтарыйк әле илгә, халыкка данлы исемен!..

Әмир ага Үтәшев белән соңгы елларда якыннан аралашуым-дуслашуым, андагы искитмәле тарихи язмалар, Франциядән җибәрелгән, Дәүләт Куркынычсызлыгы комитеты (КГБ) архивларында дистәләрчә еллар яткан байтак документлар белән танышуым нәтиҗәсендә мин Рушад аганың батыр йөрәкле көрәштәше турында ихластан әйткән сүзләренең хаклыгына тагын бер мәртәбә тирәнтен ышандым...

Сугышка хәтле Ә.Үтәшев, Уфада кооперация техникумын тәмамлап, Татарстанның Арча районы үзәгендә, райпотребсоюзда баш бухгалтер урынбасары, аннары баш бухгалтер булып эшләгән. Фронтка да шуннан киткән. Алабугада политруклар хәзерләүче кыска сроклы курсларны тәмамлаган өлкән лейтенант Үтәшев (батальон комиссары) беренче сугышчан чыныгуны 1942 елның июне азагында Курск өлкәсендә ала. Хәлиткеч-җитди көрәшләрнең берсендә, дошман танклары белән «дуэль» вакытында ул, ике аягы да авыр яраланып, аңсыз хәлдә берничә тәүлек бомба чокырында ята. Һәм шул хәлдә дошман «тырнагы»на килеп эләгә. 1942 елның 6 июленнән аның өчен газаплы әсирлек тормышы башлана...

Баштарак фашистлар Әмир абыйны Киевта, аннары Дарница, Владимир-Волынск лагерьларында яткыралар, соңыннан Польшаның Ченстохов лагерена күчерәләр. Яралары да төзәлеп бетмәгән Әмир абый биредә тифтан егыла. Немец офицеры, аның терелүенә өметен җуеп, мәетләр барагына чыгарып ташларга боера. Әмма дөньяда яхшы адәмнәр дә бар бит әле: таныш бер әсир-санитар Үтәшевнең документларын үлгән чуваш егете Александр Николаевныкы белән алыштырып куя да, Әмир абыйны эчләре китүче авырулар ята торган баракка күчерә һәм тифтан дәвалау чараларын күрә. Шулай итеп, Әмир Үтәшев Александр Николаев (Франциядә «Александр Николас», «Капитан Александр») булып китә. Французлар биргән барлык документларда аның исеме алга таба «Әмир» дип түгел, «Александр» дип телгә алына...

1943 елның маенда Ә.Үтәшевне Польшаның Едлинодагы хәрби әсирләр лагерена – «Идел-Урал» легионына китерәләр. Биредә ул, Рәхим Саттар, Әкрам Мамлеев ярдәмен-

дә, Муса Җәлил белән якыннан таныша һәм биредәге яшерен оешманың ныклы әзерлекле бер әгъзасы булып китә.

– ...Легионда синең яшерен эш алып баруыңның төп максаты – үзебезнең ватандашларны, ничек кенә булса да, партизаннар ягына алып чыгып, фашистларга каршы бергәләп көрәшү булырга тиеш! – ди Муса Әмиргә.– Мин сиңа ышанам: башлаган эшебезне дошманны тәмам җиңгәнчегә кадәр дәвам ит... Дөнья бит бу, безне алда нәрсә көтәчәген бер Алла үзе генә белә...

Күңеле дөрес сизенгән икән шагыйрьнең. Озак та үтми, 10 августта, фашистлар М.Җәлилне һәм яшерен оешма әгъзаларының бер өлешен кулга алып, зинданнарга ташлыйлар. 1943 елның августында «Идел-Урал» легионының Көнчыгыш фронтка җибәрү өчен әзерләнгән өченче (штаб) батальонын, ашыгыч рәвештә ике эшелонга төяп (писарь Әмир Үтәшев тә шунда була), немецларның көчле сагы астында, Франциянең Югары Луара департаментындагы Ле-Пюи шәһәренә озаталар (чөнки баштагы беренче, икенче батальоннардагы легионерлар, фронт сызыгына килүгә үк, немец офицерларын юк итеп, Витебск өлкәсендә һәм Көнбатыш Украинада партизаннар ягына чыккач, гитлерчылар тирән пошаманга төшә). Җәлилчеләрнең Франциядәге яшерен оешмасы җитәкчесе буларак, Ә.Үтәшев тиз арада француз партизаннары – макизарлар белән элемтәгә керә һәм легионерларның, бераздан немецларны коралсызландырып, французларның Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә бердәм рәвештә кушылуларын тәэмин итә. Бер үк вакытта Совет Армиясе офицеры да, Франция Эчке Көчләре капитаны да, татар һәм рус партизаннарының беренче группасы җитәкчесе дә булган Әмир абый (французлар аны, хөрмәтләп, «Комбатан Волонтер» дип йөртәләр, үзләренең иң зур орденнары белән бүләклиләр), ике меңгә якын легионерны, макизарны Туган илгә исән-имин кайтаруда да һәм җәлилчеләрдән Габбас Шәрипов, кан кардәше, авылдашы Нигъмәт Терегулов, француз патриоткасы Мария Дебиезе белән берлектә, дөньяны тетрәткән «Моабит дәфтәрләре»нең беренчесен саклап калуда да чын егетлек күрсәтә. (Безнеңчә, аларның һәркайсына – хәтта кайберләре инде үлгән булса да! –Россия, Татарстан хөкүмәтләре тарафыннан тиешенчә бәһа бирелергә тиеш. Әнә бит, Бельгия гражданины Андре Тиммермансны, «Моабит дәфтәрләре»нең икенчесен саклап калга-

ны өчен, Совет хөкүмәте 1966 елда «Батырлык өчен» медале белән бүләкләде!)

Ә.Үтәшевне дә «бүләклиләр». Тик – башкача. 1945 елның 1 сентябрендә Әмир Галимҗан улын – Франциядәге ватандашларын Туган илгә алып кайтучы эшелон җитәкчесен – совет – герман чигендә армия контрразведкасы кулга ала. Хәрби трибунал башта аны «Ватанга хыянәт иткән өчен» атарга хөкем итә, бераздан бу карар 25 елга иректән мәхрүм итү – каторга белән алыштырыла... Гаделлек, чын дөреслек тантана итсен өчен бик озак көрәшергә туры килә бу батыр йөрәкле, курку белмәс ир-атка. Үзеннән бигрәк, бер гаепсезгә төрмәләргә ябылган, лагерьларга озатылган сугышчан дуслары өчен борчыла, газаплана ул. Фашизмга каршы бергәләп көрәшкән иптәшләренең намуслы исемнәрен кире кайтарырга булышу, инде вафат ветераннарның якыннарына легионер-макизарлар турында чын хакыйкатьне ачу өчен, Әмир ага 1990 елның августында француз теле белгече Надежда Татаренко (Казан) белән бергә махсус рәвештә Франциягә, Баинс, Ле-Пюи шәһәрләренә барып, якташларыбызның каһарманлыкларын раслаучы үтә мөһим документлар алып кайта...

Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтик: Франциядә аны, зурлап, милли Герой итеп каршылыйлар! Югары Луара департаментының «Трибуна» газетасы 1990 елның 3 август санында «46 ел узгач, Россия макизары Баинс янында сугышлар барган урында» дигән мәкаләсендә болай дип яза:

*«...Бу пәнҗешәмбедә Баинс шәһәренең мэры Мишель Декольн әфәнде, Казан кунагы Александр Үтәшевне аэропортта каршыларга дип, Парижга китте... Ярты гасырга якын вакыт узганнан соң, Россия солдаты кайчандыр сугыш кыры булган урыннарга, өч ватандашы күмелгән Вержезак зиратына әйләнеп кайта. Аның кайтуы Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә, дөресрәге, Баинс янындагы сугышларга бәйләнгән. Бу хакта, Фернан Буатенең «Түгелгән канның таш шаһитлары» дигән китабын укып, төгәлрәк мәгълүматлар алырга була.*

*...Ле-Пюига килеп урнашкан һәм Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашучыларга каршы сугышырга тиешле немец гарнизонында хәрби рус әсирләре дә була. Дөресрәге, легионга көчләп кертелгән, җирле халык «монголлар» дип атаган татар әсирләре алар. Каршылык күрсәтү хәрәкәте ныгый барган шул чорда йөзләп әсир, гарнизоннан качып, Ру-*

*жак һәм Иссенжо районнарында капитан Сегель җитәкчелегендәге макизарларга барып кушыла. Немецларга каршы Баинс шәһәре өчен барган сугышта һәлак булган алты партизанның да өчесе – элекке легионерлар. Менә алар кемнәр: Андрей Аксенов – очучы, капитан; Газизҗан Зөбәеров һәм билгесез солдат...*

Ул сугышта исән калганнарның берсе – Александр Үтәшев. Легионнан качып, ул Каршылык күрсәтү хәрәкәте алып барган көрәшләрдә бик нәтиҗәле катнаша...»

Шул ук газетаның 13 августта чыккан санындагы «Баинс: 1944 елгы сугышны искә алу» дигән язмага да күз салып үтик:

*«...Баинста һәлак булганнар монументы янына ике йөзләп кеше җыелды. СССРдан капитан Александр Үтәшев килү сәбәпле, быелгы тантана аеруча истәлекле узды. Каршылык күрсәтү хәрәкәте ветераннары элеккечә олы кунак янәшәсенә тупландылар...*

*Александр Үтәшев француз партизаннарының мөһим заданиеләрен үти – дошман турында тулы мәгълүматлар тапшырып тора. 1944 елның июль аенда ул, бик күп иптәшләрен ияртеп, макизарлар янына китә. Алар майор Когальон җитәкләгән отрядка барып кушылалар, бергәләшеп, немецларга каршы күп кенә бәрелешләрдә катнашалар...*

*Азатлык килгәннән соң, Франциянең Каршылык күрсәтү хәрәкәте җитәкчелеге бүләкләгән икенче Хәрби Тәрене дә алырга өлгермичә, Александр Үтәшев туган иленә – Советлар Союзына кайтып китә. Әмма анда аны «хыянәтче» дип, 25 елга хөкем итәләр...»*

«Левэй» газетасы шул ук елның 14 август санында чыккан «Каршылык күрсәтү хәрәкәте сугышчылары Александр Үтәшев янында» дигән мәкаләсендә, Әмир ага турында сүзне дәвам итеп, түбәндәгеләрне яза:

*«...Ле-Пюидагы яшерен оешма җитәкчесе Үтәшев СССРда 8 ел буена лагерьларда утырып чыкканнан соң гына реабилитацияләнә. Хәзер инде ул үзенең көрәштәш ватандашларын аклау чараларын эзли...*

*Һәлак булган иптәшләренең каберләренә чәчәк бәйләмнәре куйгач, карт солдат күз яшьләрен тыя алмады...*

*Һәйкәл янында соңгы сүзне Генераль совет вәкиле Прориоль әфәнде әйтте. Ул Үтәшев әфәндегә, көчле рухлы, изге-якты күңелле шәхес булганы һәм Францияне дошманнан азат итүдә турыдан-туры катнашканы өчен кайнар рәхмәт белдерде.*

*«Сугыш Сезне бу якларга элек көчләп – мәҗбүри итеп китергән булса, бүгенге иминлек Сезне безнең департаментта олы кунак сыйфатында кабул итәргә ярдәм итте»,– диде ул...»*

* * *

Гомумән, Франциягә бу баруында Әмир ага Үтәшев үзенең күптәнге танышы – сугыш чорында Югары Луара департаментындагы француз партизан отрядлары берләшмәсе командующие – отставкадагы подполковник Серж Запальский (псевдонимы – Жевольд) белән очраша, аның ярдәмендә күп кенә мөһим архив документларының фотокүчермәләрен алып кайта. Хәер, КГБ архивында да С.Запальский әфәнде язган кайбер хатлар сакланып калган икән. Менә шуларның берсе –1945 елның 5 апрелендә язылганы:

*«Париждагы Совет Хәрби Миссиясенә.*

*Немец армиясе подразделениеләрендәге хәрби әсирләр арасында Югары Луара округы партизаннары белән ныклы багланыш тотучы кызылармеецлар шактый иде. Аларның күбесе Татар легионын таркатуда булышлык күрсәтә. Соңыннан легионерларның бер өлеше француз партизаннарына кушылды.*

*Командирларын аеруча билгеләп үтәр идем:*

*1. Капитан АНДРЕЙ АКСЕНОВ – 1913 елның 13 декабрендә Мәскәүдә туган. Хатынының адресы: Москва-112, Душевская, 7–11. Рус партизаннарының беренче группасын оештырып, аны 1944 елның 28 июлендә Ружак шәһәре янындагы урманга алып килде. Отряды белән гаять кыю сугышып, Югары Луара округындагы (Көньяк Франция) Баинс шәһәре өчен немецлар белән бәрелештә 1944 елның 11 августында батырларча һәлак булды.*

*2. Капитан АЛЕКСАНДР ҮТӘШЕВ – 1919 елның 15 сентябрендә Башкортстанның Благовар шәһәре янындагы Каргалы авылында туган, хатынының адресы: Татарстан Республикасы, Арча эшчеләр поселогы, Интернационал урамы, 35 нче йорт. Рус партизаннарының беренче группасын оештыручы һәм аның комиссары булды. Капитан Аксенов белән берлектә ул группаны макизарлар янына урманга алып килде. Андрей Аксенов һәлак булганнан соң, капитан Александр рус партизаннары группасын җитәкләде һәм сан ягыннан үстерде.*

*Үтәшев үз отряды белән Баинс шәһәре янындагы бәре-*

*лешләрдә катнашты һәм 22 рус солдатын әсирлектән коткарды. Аллегро, Монтан тирәсендә барган сугышларда да үзен уңай яктан нык танытты. Аннары Соги (Югары Луара округы) янында немец солдатларын һәм француз фашистларын эзләп табып, аларны кулга алуда турыдан-туры катнашты. Ле-Пюи шәһәрен азат иткән көндә аның группасында 118 ирекле сугышчы бар иде инде. Алар һәммәсе дә тәртипле, сугышчан хәрәкәтләр алып бару өчен ныклы әзерлекле иде. Өстәвенә командирларын да хөрмәт итәләр иде.*

*Капитан Александр Үтәшевнең отряды һәрвакыт соңгы тамчы канынача сугышырга әзер булуы һәм кыюлыгы белән француз партизаннарына үрнәк булды.*

*Легионны таркатудагы тырышлыгы өчен, партизаннар отрядын искиткеч оста оештырганы һәм җитәкләгәне өчен Совет Армиясе офицеры Александр Үтәшевкә Француз Армиясе капитаны дәрәҗәсе бирелде (Франция Эчке Көчләренең Келлерман батальоны буенча 1944 елның 2 августында игълан ителгән 2 нче номерлы приказы нигезендә.– Ш.М.) һәм ул Франциянең Хәрби Тәре ордены белән бүләкләнде...*

*Курку белмәс батыр патриотларның ихлас ярдәме нәтиҗәсендә ирешелгән уңышларның аеруча мөһимлеген искә алып, Кызыл Армиянең Югары командованиесенә шул хакта җиткерүегезне сорыйм.*

*Подполковник ЗАПАЛЬСКИЙ».*

1990 елның 11 августында исә подполковник С.Запальский Баинс шәһәре бәйрәменә СССРдан Ә.Үтәшевнең килүе хөрмәтенә үткәрелгән митингта, югарыда китерелгән сүзләрен куәтләп, болай ди:

«...Минем дустым Үтәшевкә – капитан Александрга – без тиешле хөрмәтне күрсәтергә бурычлыбыз. Сугышчан дуслыкка тугрылыклы булып калуы белән, үзенең искиткеч кешелекле эш-гамәлләре белән ул безнең һәлак булган иптәшләребез турындагы изге хатирәләребезне яңартты... Нәкъ менә шушында, дөресрәге, Ружакта, 1944 елның 26 июне көнне вермахт карамагындагы рус солдатларын яңадан сафка кайтару стратегиясе эшләнде. Шуннан соң без Баинста немецларны тукмауга керештек. Франция Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә бу стратегия искиткеч зур роль уйнады. (Тик – шунысы кызганыч – бу хакта бездә аз беләләр әле.) Шушы уникаль стратегия ярдәмендә без макизарлар отрядларын

кораллы рус солдатлары (легионерлар.– *Ш.М.*) хисабына тулыландырдык, дошманның сугышчан көчен киметтек, рухын сындырдык. Үзебез исә бик аз кеше югалттык. Әйе, без бу эшне оста башкарып чыктык. Немецларның Генштабы, аның вәкиле майор Шмелинг үзләренең җиңелүләрен танырга мәҗбүр булды... 1944 елның 12 августына чаклы рус әсирләреннән 188 кеше, безнең тарафтан бернинди басым ясалмыйча, үз теләкләре белән макизарлар ягына чыкты. Капитан Александр минем: «Партизаннарга каршы сугышудан баш тартсыннар!» – дигән әмеремне легионга җиткергәч, анда калган легионерлар бу фәрманымны берсүзсез үтәделәр. Немецларның армиясе таркала башлады. Легионерларның макизарлар ягына авышуы хәлне бөтенләй үзгәртеп җибәрде. 1260 партизанга каршы 286 немец белән 36 француз полицае гына торып калды. Шуннан соң алар безгә әсирлеккә бирелергә мәҗбүр булдылар...»

Серж Запальский, моның белән чикләнмичә, Әмир Үтәшев артыннан күренекле язучы-җәлилче Рафаэль Мостафинга хат та юллый:

*«Идел-Урал» татар легионында антифашистик оешма бар иде,–* дип яза ул.*– Аңа капитан Александр Үтәшев җитәкчелек итте. Без аны Александр Николас буларак беләбез. 1944 елның мартыннан башлап Үтәшев әфәнде безнең белән Александр Николас буларак хезмәттәшлек итте. Август башында, ягъни партизан отрядына күчкәч, ул шушы исемгә паспорт алды (немецлар туктаткан очракта күрсәтү өчен). Паспортны аңа мин үзем тапшырдым. Александр Франция гражданины булып санала башлады (моны раслаучы документлар хәзер дә Югары Луара департаменты архивларында саклана. Александр, эз яшерү өчен, «милләте буенча – алжирлы» булып теркәлде).*

*Әсирлектән азат ителгәч һәм 352 нче номерлы совет батальоны оешкач, ул ФХК (Франция Хәрби Көчләре) капитаны булды һәм батальон командирының сәясәт буенча урынбасары булып хезмәт итте...»*

* * *

Франциядән кайткач, Әмир ага Үтәшев канатларын тагын да җәеп, колачын киңәйтебрәк җибәрде. Радио-телевидение тапшырулары, газета-журнал битләре аша чыгышлар

ясап, Идел-Урал төбәкләрендәге хәрби комиссариатлар, Дәүләт Куркынычсызлыгы комитеты вәкилләре белән элемтәгә кереп, үзенең сугышчан дусларын, легионер-макизарларны эзләүгә кереште.

1991 елның 24 декабрендә Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев белән дә очрашты ул. Бу көнне биредә Алманиянең Плетцензее төрмәсендә 1944 елның 25 августында көндезге 12 сәгать 06 минуттан 12 сәгать 36 минуткача вакыт эчендә фашист гильотинасында башлары киселгән унбер татар каһарманын зурлап искә алу, шуларның унысына, дөресрәге, якыннарына, I дәрәҗәле Ватан сугышы орденнарын тапшыру тантанасы үткәрелде.

Билгеле булганча, патриот шагыйрь Муса Җәлил, «Бөек Ватан сугышында немец-фашист илбасарларга каршы көрәштә тиңдәшсез ныклык һәм батырлык күрсәткәне өчен» СССР Югары Советы Президиумының 1956 ел 2 февраль Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән мәртәбәле исемгә лаек булган иде инде. 1957 елның 22 апрелендә исә аңа дөньяны тетрәткән «Моабит дәфтәрләре» исемле шигырьләр циклы өчен Ленин премиясе дә бирелде...

Ә менә М.Җәлил белән бер үк дәрәҗәдә каһарманлык үрнәге күрсәткән көчле рухлы шәхесләрдән Гайнан Кормаш, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров кебек фидакарь җаннар Советлар хөкүмәтенең бернинди бүләге белән дә билгеләп үтелмәделәр. Шушы гаделсезлек бик күпләрнең күңелләрен тырнап торды.

Заманында Татарстан Язучылар оешмасын җитәкләгән мөхтәрәм каләм әһелләреннән Зәки Нури, Гариф Ахунов, Җәлилнең якын дусты Гази Кашшаф һәм, әлбәттә инде, патриот-шагыйрь һәм аның көрәштәш дуслары турында гаҗәеп кызыклы, сискәндерерлек язмалары белән миллионлаган күңелләрне үзенә җәлеп иткән эзтабар әдип Рафаэль Мостафин гаделлекне торгызу, торгынлык чоры бозларын эретү буенча үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр. Аннары бу эшкә, җиң сызганып, 1984–1989 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булган киң колачлы, тынгысыз әдип-драматург, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин алынды. Рафаэль Мостафин һәм милләтпәрвәр җанлы бер төркем зыялыларыбыз белән бергә ул Татарстан Республикасы һәм

СССР җитәкчеләренә, М.Җәлил белән бер үк вакытта җәзаланган ун татарга да иң югары дәрәҗәле исемнәр бирүне яисә орденнар белән бүләкләүне сорап, хат арты хат юллады. 1989 елда Т.Миңнуллин СССР Югары Советына депутат итеп тә сайлангач, аңа бу өлкәдә эшне тизләтү өчен шактый зур мөмкинлекләр дә ачылды.

Билгеле булганча, Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев үзе дә каһарманнарыбызны бүләкләү кирәклеге турында, җай чыккан саен, СССР Президенты М.С.Горбачевның исенә төшереп тора. Туфан ага да шушы мөһим мәсьәлә буенча һәр ике Президент Аппаратында булып чыга, Бүләкләүләр бүлегенең ишеген еш шакый...

Ниһаять, 1990 елның 5 маенда «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында актив катнашучыларны I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләү турында» Совет Социалистик Республикалар Союзы Президенты Указы игълан ителде. Анда «фашистларга каршы яшерен группада актив патриотик эшчәнлекләре, ныклык һәм батырлык күрсәткәннәре өчен» ун каһарманыбызның исем-фамилияләре зурлап телгә алына...

Шулай итеп, рейхстаг түбәсенә Җиңү байрагы кадаганнан соң 45 ел вакыт үткәч, батырларыбызга карата, шактый соңлап булса да, җылы сүз әйтелде, кылган бөек гамәлләренә тиешле бәя бирелде...

1991 ел декабрендә Казан Кремлендә җәлилчеләрне искә алу тантанасында чыгыш ясап, Татарстан Президенты күңелләргә сары май булып ятарлык өметле сүзләр әйтте:

– *Әле без батырларыбызның данлы исемнәрен, аларның якты образларын һәркемнең йөрәк түренә җиткерү буенча киләчәктә тагын да нәтиҗәлерәк шөгыльләнергә уйлыйбыз. Ышандырып әйтә алам: озакламый Муса Җәлил һәйкәле янына аның көрәштәш дуслары да, бронза барельефлар рәвешендә, сафка һәм сакка басар! Батырлык һәм Хәтер мәйданы булып әверелер ул изге урын...*

Әмир ага Үтәшев тә, мөмкинлектән файдаланып, үзенең фикерләрен әйтеп калырга ашыкты:

– Җәлилчеләрнең, легионер-макизарларның истәлекләрен туплап, газета-журналларда бастырасы, аерым китаплар итеп чыгарасы иде... Аларга багышлап документаль кинофильмнар, видеофильмнар, теле-радиотапшырулар эшлисе иде... Вакыт көтми, вакыт ашыктыра! Берәү дә мәңгелек түгел...

* * *

1993 елның 21–24 апрель көннәрендә Ә.Үтәшев, Франциядә фашистларга каршы көрәшкән легионер-макизарларның Беренче халыкара конференциясендә дә катнашып, эзләнүләрен тагын да киңрәк җәелдереп җибәрү өчен зур мөмкинлекләргә ия булды. Шул ук елның 6 маенда, Татарстан Дәүләт милли музеенда җәлилчеләргә багышланган искә алу җыенында, Әмир аганың тырышлыгы белән, Каршылык хәрәкәтендә катнашучыларның «Кызыл ромашка» исемле ассоциациясе төзелде. Оешманың рәисе (президенты) итеп бертавыштан аның үзен сайлап куйдылар. Әлеге ассоциация Идел буе, Урал төбәге республика-өлкәләрендә яшәүче элекке легионерларны, макизарларны, хәрби тоткыннарны, партизаннар хәрәкәтендә катнашучыларны үзенә берләштерде.

Әмир Галимҗан улының турыдан-туры булышлыгы белән легионер-макизарлардан байтак кешегә намуслы исемнәре кире кайтарылды, хәрби бүләкләре тапшырылды...

Ниһаять, мәңге эремәс булып тоелган торгынлык бозлары ныклап җеби башлады. Җәлил белән бергә Мәңгелеккә күчәр алдыннан батырларның һәркайсы үпкән изге Коръән Казанга әйләнеп кайтты. Үлемсезлеккә атлауларына нәкъ ярты гасыр тулган көндә – 1994 елның 25 августында көндезге 12 сәгатьтә Муса һәйкәле янәшәсендә ун каһарманның һәркайсы барельефтагы сурәт рәвешендә (скульпторы – академик В.Е.Цигаль) торып басты! Җәлилчеләргә багышланган Хәтер җыенында Әмир ага Үтәшев тә чыгыш ясап:

– Бу көнне күрүем белән бик тә бәхетлемен! – диде.– Инде бүген Мусага һәм җәлилче дусларыма шатланып рапорт бирә алам: Едлинода сезгә биргән вәгъдәбезгә тугры калдык, башлаган изге, хак эшебезне ахыргача җиткердек – легионерларның өченче батальоны да ватандашларыбызга, французларга каршы корал күтәрмәде... Шуңа сөенәбез, горурланабыз: Сезнең батырлык онытылмый, йөрәкләрдән йөрәкләргә, буыннардан буыннарга күчә бара! Бу юнәлештә без дә – исән җәлилчеләр дә – көчебездән, сәләтебездән килгәнчә үзебездән өлеш кертәбез...

«Исән җәлилчеләр» дигәннән, биредә Гарәф Фәхретдинов, Фәрит Солтанбәков кебек олуг затларны истә тотып әйткән иде ул чакта Әмир ага. Аларның җәлилчеләргә багышланган «Кайда минем Илем?» (1994 ел, 8–9 саннар),

«Үлем сәгатен көткәндә» (1995 ел, 5 сан) исемле документаль язмалары иң элек «Казан утлары» журналында дөнья күрде. Рушад Хисаметдиновның магнитофон тасмасында калган җанлы тавышы, аның атаклы сынчы-рәссам Бакый ага Урманче белән булган мавыктыргыч-җанлы әңгәмәләре исә, галимә Флора ханым Әхмәтова-Урманче белән язучы-тәрҗемәче Азалия ханым Бадюгинаның уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә әлеге журналны укучыларга «Дусларымның васыятен үтәдем» дигән документаль кыйсса рәвешендә барып иреште (1995 ел, 9 сан). Әмир ага Үтәшев тә бу өлкәдә җиң сызганып эшләде, төрле газета-журналларда истәлекләре еш басылды...

1995 ел азагында Әмир аганың тормышында тагын бер истәлекле вакыйга булды: ул Франция хөкүмәте билгеләгән махсус пенсияне ала башлады! Идел-Урал төбәгендә яшәүче элекке макизарлар арасында беренчеләрдән булып... Әнә шулай, киң күңелле, олы җанлы французлар үз Ватаннарының азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшкән «комбатан Волонтер»ны – инде сугыштан соң күп еллар үтсә дә! – онытмыйлар. Әмир ага Үтәшев турында кайгыртып, 1995 елның апрелендә Казанга Франциянең Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Пьер Морель әфәнде махсус килеп киткән иде. Пенсия өчен кирәкле документларны да шул чорда хәзерләтеп алган иде ул. Рәхмәт үзенә – сүзендә торган!

Танылган журналист Борис Бронштейн шул уңайдан «Известия» газетасының 1995 елгы 23 декабрь санында «Пенсионер французского значения» дип исемләнгән күләмле язмасы белән дә чыгыш ясады. Анда Әмир аганың орден-медальләр тагып төшкән зур фоторәсеме дә бирелгән иде (Евгений Канаев эше). Аннары әлеге язманы «Татар иле» газетасы да, тәрҗемә итеп, үзенең 1996 елда чыккан 1 гыйнвар санында урнаштырды. Билгеле булганча, бу газетаны Россия Федерациясенең һәм элекке СССРның татарлар яши торган күп кенә төбәкләрендә алдыралар...

Үтәшевләрнең фронтовик-әдип Гадел Кутуй урамындагы фатирына еш килеп йөргәнлектән, аларның үтә тынгысыз, кайнап торган тормыш белән яшәүләренә исләрем китә иде. Легионер-макизарларны барлау һәм аларның күбесен аклау штабына әйләнгән иде бер бүлмәле, әмма «шушы меңмиллион мәшәкатьле дөньяны үзенә сыйдыра алган» хикмәтле бу фатир... Йөрәкләрдә дөрләп торган Хәтер утын сүндермәс өчен әнә Франциядә дошманга каршы иңгә-иң то-

рып сугышкан якын дусты Рушад ага Хисаметдинов та үләр алдыннан Әмир агага үзенең хат-васыятьнамәсен язып калдырган:

*«Кадерле Әмир! Газраил минем җанымны алырга берничә мәртәбә омтылыш ясап карады инде. Шуңа күрә Сиңа – ихлас дустыма – үтенеч-теләгем зурдан: йөрәгең типкәндә, башың эшләгәндә, колагың ишеткәндә, аяк-кулларың йөргәндә, безнең легионер-макизар дусларыбызны (исәннәрен дә, үлгәннәрен дә!) барлаудан һәм аларны аклау, хак исемнәрен кайтару өчен көрәшүдән һич тә туктама! Мин Сиңа ышанам...»*

Муса Җәлил кебек, Рушад дусты да аңа шундый зур ышаныч белдергәч, үтенечен җиткергәч, ничек тик кенә ятсын инде Әмир ага?! Һәм ул, йокы-ялын онытып, көрәштәш дусларының язмышларын җиңеләйтү өчен, югары оешмаларга бихисап хатлар язды, аларның чын патриотлар икәнлеген раслаучы тарихи документларны туплап җибәрде, кирәк икән – теге яки бу төбәккә үзе үк барып кайтты. Әйтик, Татарстанның Буа районындагы Янтуган авылында яшәүче легионер-макизар – француз партизаннары отрядында данлыклы старшина булган Ибраһим Айнатулла улы Айнатулловны һаман да сугыш ветераны итеп санамауларын-санламауларын белгәч, ул, барлык эшен ташлап, юллар өзеклегенә, язгы ташуга карамастан, 1992 елның март азагында – апрель башында шул төбәккә кичекмәстән барып чыкты. Биредә ул сугышчан дусты турында район һәм хуҗалык җитәкчеләре белән очрашып сөйләште. Авыл халкы, укытучылар һәм укучылар катнашында аңа багышлап мәктәптә зур кичә үткәрде. Шуннан соң гына Ибраһим аганың кәефе дә, абруе да бердән күтәрелеп китте. Гомере буе туган ягында шофер һәм янгын сүндерүче булып намуслы хезмәт иткән, сөекле хәләл җефете – Хәтирәсе белән берсеннән-берсе булдыклы егетләр, уңган кызлар тәрбияләп үстергән ветеранның иңнәренә пар канатлар үскәндәй булды шул истәлекле, дулкынландыргыч очрашулардан соң...

Республикабызның Кукмара районындагы Зур Сәрдек, Ташлы Елга, Ятмас Дусай авылларында яшәүче Гаян Әхмәтшин, Нургали Шәйдуллин, Галимҗан Әхмәтҗанов, Әтнәдән Мөбарәкша Хәсәнов, Азнакайдан Гомәр Асибаков, Баулыдан Петр Долгов, Буадан Фазыл Хәйруллин, Казаннан Ризван Мөхетдинов, Башкортстанның Туймазы, Октябрьск,

Уфа шәһәрләреннән Фәйзерахман Закиров, Әлмөхәммәт Низаметдинов, Әкрам Минһаҗетдинов, Әстерханнан Хәбибулла Моратов кебек дистәләгән легионер-макизарларны аклау, аларның намуслы исемнәрен кайтару буенча да ныклап шөгыльләнде Әмир ага. Бу эшләрнең һәммәсендә аңа кешелекле һәм уңган хатыны – якын дусты һәм киңәшчесе Рәйсә ханым, үз мәктәпләрендә «Иң яхшы мөгаллимә» буларак танылган кызлары Әлфия, оныгы – яшь шагыйрә Кадрия бик теләп булыштылар.

Гомумән, бу күркәм гаилә бар яктан да күпләрне сокландырырлык иде. Заманында Әмир абый, аклангач, Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлап, төзелеш оешмаларында баш бухгалтер буларак тырышып эшләгән – мактаулы исеме телдән төшмәгән. Рәйсә Йосыф кызы исә, дүрт дистә ел дәвамында балаларга төпле белем-тәрбия биреп, мәгариф өлкәсендә уңыш казанган. Инде күптән лаеклы ялда булсалар да, аларның һәр көне (кайчакта – төннәре дә!) адәм балаларына игелек кылып үтә иде. Әмир ага белән Рәйсә ханымга кешеләрне ярата белү таланты тумыштан бирелгән, күрәсең. Әтнәдә яшәүче һәм Үтәшевләрнең кунакчыл фатирына еш килеп йөрүче мөгаллимә Мәрзия ханым Хәсәнова (мәгълүм макизар М.Хәсәновның хатыны) бик хаклы әйткәнчә, «биредән җанга – җылылык, күңелләргә яктылык алып, Хакыйкатьнең кайчан да булса бер тантана итәчәгенә ныклы ышаныч белән чыгасың!..»

Үләренә берничә ай кала, Әмир ага Казан – Чаллы – Азнакай – Баулы – Октябрьск – Туймазы – Бүздәк – Уфа – Казан маршруты буенча йөреп кайтты. Үзенең көрәштәш дуслары, легионер-макизарлар һәм аларның гаилә әгъзалары, якын туганнары белән очрашты ул. Аңарчы Әмир ага Франциянең Баинс шәһәре янында барган сугышларда батырларча һәлак булган коралдаш дусты – үз отряды сугышчысы Газизҗан Зөбәировның гаиләсе янында – Башкортстан Республикасының Кыйгы районында булып, алар белән рухи туганлашкан иде...

Франциядәге Каршылык күрсәтү хәрәкәте ветераннарының «Комбатан Волонтер» ассоциациясе Әмир Галимҗан улы Үтәшевне, сугыш елларында фашистларга каршы көрәштә күрсәткән зур батырлыклары һәм макизарларны аклаудагы тынгысыз эшчәнлеге өчен, 1995 елда үзләренең Почет билгесе белән бүләкләде. Әлеге илнең танылган фото-

рәссамы Нуак Карраy әфәнде, Париждан махсус килеп, фоторәсемгә дә төшереп алды Әмир аганы Рәисә ханым белән...

«Комбатан Волонтер» ассоциациясенең Мәскәүдәге оешмасы җитәкчесе Олег Озеров, җәлилчеләрдән Фәрит Солтанбәков (Казан), Гарәф Фәхретдинов та (Ташкент) атаклы макизарны зур бүләккә лаек булуы белән беренчеләрдән булып котладылар. Исән булса, Рушад Хисаметдинов та, изге әманәткә тугрылыгы өчен, Әмир дустына үзенең ихлас рәхмәтен белдерер иде. (Ни кызганыч, ул әлеге тантананы күрә алмады – 1992 елның 28 августында (җәлилчеләр җәзалап үтерелгән айда!) Кыргызстан Республикасының Ош шәһәрендә йөрәк өянәгеннән 81 нче яшендә вафат булды. Авыр туфрагы җиңел булсын!..

Әнә шулай каһарман шәхесләр, фани дөньяны калдырып, бакый дөньяга – Мәңгелеккә китә тора. Әмир ага Үтәшевне рәхимсез авыру (инфаркт-инсульт) 1996 елның 21 гыйнварында, башка кузгала алмаслык итеп, урынга екты. Әҗәл белән соңгы сулышына чаклы көрәште ул. Бөтен гомере тоташ батырлыктан, ялкынланып янудан торган олпат ир-атның – Әмир Галимҗан улы Үтәшевнең күпне кичергән тынгысыз йөрәге изге Рамазан аеның 16 нчы көнендә (6 февраль) 17 сәгать 15 минутта тибүеннән туктады... 77 яшен дә тутырырга өлгермәгән олуг милләттәшебезне, зур кадер-хөрмәт күрсәтеп, Казан каласының Яңа бистәдәге мөселман зиратында җирләдек. Бераздан Әмир ага кабере өстенә мәрмәр таш та куелды...

Кем ничектер, әмма мин һәр җәлилченең, фашизмны җиңүгә үзләреннән лаеклы өлеш керткән һәр легионер-макизарның кабер ташларына яшәүне, тормышны, бар тереклекне, табигатьне, һәр җан иясен өзелеп сөйгән ватанпәрвәр рухлы әдибебез Абдулла Алиш (1908 —1944) сүзләрен мәңге җуелмаслык итеп, уеп язар идем:

*«...Килдем, көрәштем, киттем... без соңгы сулышыбызга кадәр халкыбызга тугры булып калабыз».*

Билгеле булганча, әлеге юллар А.Алишның 1944 елның 28 гыйнварында хәләл җефете Рокыя ханымга, уллары Алмаз белән Айвазга, якын туганнарына, дусларына атап язган соңгы хатыннан алынды. Бу хатны төрмәдән Бельгия патриоты – антифашист Эмиль Мэйзон алып чыга һәм Казанга юллый...

1944 елның августында фашист гильотинасында башла-

ры киселгән каһарман милләттәшләребез хөрмәтенә Казан Кремле каршында торгызылган мемориаль үзәктә дә әлеге сүзләр балкып янса, аларның рухлары шат, безнең күңелләр түгәрәк булыр иде. Күренекле җәлилче-мөгаллим Фәрит ага Солтанбәков та (1916–2002) үзенең «Эш күрсәткән ирне Ил онытмас...» дигән китабында (Казан, «Матбугат йорты» нәшрияты, 2001 ел) шул хакта искәртеп, ассызыклап язып калдырды. Аларның үтенеч-васыятьләрен тормышка ашыру – без исәннәрнең изге бурычы!..

Җәлил, Кормаш, Алиш һәм башка легионерлар, макизарлар турында чын дөреслекне ачуга, көрәштәшләренең үлемсез батырлыкларын, рухи ныклыкларын раслауга үзләреннән биниһая зур өлеш керткән, якты исемнәре әлеге кыйссада тирән хөрмәт хисләре белән зурлап телгә алынган мөхтәрәм шәхесләр алдында башымны иеп, аларга түбәндәге шигъри юлларымны багышлыйм:

Сез – Җәлил, Кормаш дуслары,
Сез – алардан көч алган! –
Шуңа күрә Тәмуг утын
Сез исән-сау кичә алган...
Сез бит, легион турындагы
Күптән көткән хәбәрне
Алып кайтып, үзгәрттегез
Илдәге күп хәлләрне.
Кара көчләр җиңелделәр,
Балкыды нур-яктылык!
Җәлилчеләрнең йөзләре
Бердәм китте яктырып!
Сез дә бит, Җәлил-Алиштай,
Батырлык эшләдегез!
Дусларыгызны акламый
Иярдән төшмәдегез!
(Сез Хаклыкның Акбүз атын
Ныклап иярләдегез,
Имансыз-кыйбласызларга
Һич тә иярмәдегез!)
Сез бит гомерегез буе
Дуслар өчен яндыгыз,
Яктыртып кара төннәрне
Һәрчак алдан бардыгыз!
Сездән күчкән җылылыктан
Терелде сулган гөлләр...
...Сезнең хакта, изге җаннар,
Гасыр гасырга сөйләр!

# ЯҢА ГАСЫРГА ОЧЫШ

Гастеллочылар... Тиңдәшсез батырлык символы булып әверелгән әлеге сүз күпләребезгә мәктәп елларыннан ук яхшы таныш.

Билгеле булганча, ошбу гыйбарә Бөек Ватан сугышы чорында 42 нче авиация дивизиясенең 207 нче бомбардировщиклар полкында эскадрилья командиры булып хезмәт иткән Николай Францевич Гастелло (1907–1941) исеме белән тыгыз бәйле. 1941 елның 26 июнендә ул – белорус халкының көчле рухлы тәвәккәл улы, 34 яшьлек капитан – Минск шәһәре янәшәсендәге Молодечно-Радошковичи юлында хәрәкәт итүче немец танклары, автомашиналары колоннасын бомбага тота. Дошманның байтак җанлы көчләрен, техникасын юк итә аларның бердәм-дус экипажы. Инде хәрби бурычны үтәп, кайтырга җыенганда гына, аларның очкычы фашист зениткаларының көчле утына эләгә. Нәтиҗәдә бомбардировщик яна башлый. Кискен хәрәкәтләр ясап та, ялкынны сүндерә алмагач, Николай Гастелло экипаж әгъзалары – очучы-күзәтүче лейтенант Григорий Скоробогатый (1919), штурман-лейтенант Анатолий Бурденюк (1922), укчы-радист өлкән сержант Алексей Калинин (1920) белән бердәм фикергә килеп, үзләренең утлы очкычларын дошман машиналары, ягулык цистерналары өстенә юнәлтәләр. Искиткеч көчле шартлау тирә-юньне тетрәтә. Гитлерчыларның байтак техникасы, солдат-офицерлары теткәләнеп, көл булып күккә оча шул мизгелдә...

Әлеге каһарманнар, шушы фидакарьлекләре өчен, хөкүмәтебезнең югары бүләкләренә лаек булалар. Н.Гастеллога, нәкъ бер айдан соң, 1941 елның 26 июлендә СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелә. Экипаж әгъзаларының калганнары I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләнәләр...

Легендар капитан Гастелло экипажы үрнәгендә Бөек Ватан сугышы чорында дошманның җирдәге ныгытмаларына, техникасына, җанлы көчләренә барлыгы, архив мәгълүматлары раслаганча, 503 таран ясалган. Шуларның 286сы штурмовикларга, 119ы бомбардировщикларга, 98е истребительләргә туры килә (кара: «Бессмертные подвиги» китабы, М., Воениздат, 1980 ел, 111–195 битләр; «Правда» газетасы, 1985 ел, 30 март саны, «Иду на таран!» дип исемләнгән

язма; «Календарь знаменательных памятных дат», М., 1985 ел, № 6, 35 бит).

Әмма Галиҗәнап Вакыт һәм эзтабарларның тынгысызлыгы, фидакарьлеге данлы үткәнебезне барларга, яңадан-яңа каһарманнарны табарга, батырлыкларын ачыкларга ярдәм итә. Әйтик, Н.Гастеллоны очарга өйрәткән инструктор М.Ююкин утызынчы елларда Халхин-Голда, 150 нче бомбардировщиклар полкының батальон комиссары буларак, шәхси үрнәк күрсәтә: хәрби бурычны үтәгәндә очкычына ут капкач, ул аны японнарның дзотына юнәлтә... Шәкерте Николай Францевич та иң кыен мизгелдә остазы батырлыгын исенә төшерә һәм дошманны юк итеп җиңү өчен бердәнбер дөрес карарга килә... Хәзер безгә сугышның беренче көнендә – 1941 елның 22 июнендә үк очучыларыбыз тарафыннан 16 (уналты!) мәртәбә таран ясалганлыгы да мәгълүм. Дошман очкычларына һавада таран ясаучылар саны исә 600дән артып китә, шуларның җидесе, ниндидер могҗиза белән, исән (!) кала. Сугыш чорында Алтын Йолдызга лаек булган 2420 очучы арасында таранчылар йөзәрләп исәпләнә...

Әйе, утлы лачыннарның батырлыгы, күпчелек очракта, тиешенчә бәяләнгән. Тик, ни кызганыч, араларында хаксызга онытылганнары да бар әле. Безнең бурыч – әнә шундый тәвәккәл җаннарны Билгесезлек баткаклыгыннан коткару, аларга икенче гомер – Мәңгелек Яшәү бүләк итү...

Архивларда җентекле эзләнүләр барышында, дәһшәтле сугыш чорында дошманга таран ясаган байтак каһарман якташларыбызны, милләттәшләребезне табу бәхете дә насыйп булды. Менә алар кемнәр: Татарстаннан Мансур Гарипов (Кукмара), Владимир Ефремов (Нурлат), Иван Заварыкин (Лениногорск), Алексей Клешевников (Минзәлә), Петр Коклянов (Кайбыч), Анатолий Плотников (Алексеевск), Мисбахетдин Фәттахов (Мамадыш), Константин Шуравин (Яшел Үзән), Башкортстаннан Захарий Вәлиуллин, Казахстаннан Кадил Зәбиров, Пермьнән исән калган гастеллочы, Алтын Йолдыз кавалеры Әнвәр Гатауллин, Свердловск-Екатеринбург каласыннан Хәбиб Сафин...

Соңгы вакытта шушы каһарман очучылар сафына Татарстанның Мөслим районында туып, хәрби хезмәткә Удмуртия башкаласыннан киткән Фәрдетдин Сәхәбетдинов та өстәлде. 63 елдан соң Ижевскига кабат әйләнеп кайтты ул! Узган гасырдан яңа гасырга очып кайтты...

## 1. Тарихта бердәнбер

...Волхов фронты карамагындагы 14 нче Һава армиясенең 281 нче штурм авиадивизиясе составына керүче 703 нче штурм авиаполкы очучысы, кече лейтенант Фәрдетдин Сәхәбетдин улы Сәхәбетдинов белән укчы-сержант Егор Васильевич Кретовка, броняланган һәм көчле коралланган «Ил-2» штурмовигы ярдәмендә, 1943 елның 27 мартында Ленинград өлкәсенең Карбусель авылы – Малукса бистәсе арасында дошман төзегән хәрби ныгытмаларны, җанлы көчләрен, техникасын утка тотарга фәрман бирелә. 1750 ат көчле һәм сәгатенә 420 км тизлек белән очучы әлеге җитез штурмовик, 22 ммлы ике пушкадан фашистларга берөзлексез ут ачып, алар өстенә 100әр килограммлы бомбалар ташлый. «Тагын бер әйләнеш ясыйбыз!» – дигәндә генә, Фәрдетдиннәр очкычы дошман зениткаларының утлы боҗрасы уртасында кала. Нәтиҗәдә самолетка снаряд тия һәм ул яна башлый. Фәрдетдин сугышчан дусты Егорга парашюттан сикерергә боерса да, яралы укчы-сержант үзенең яраткан командирын очкычта ялгыз калдырырга теләми. Сикергән очракта да барыбер дошман кулына эләгәчәкләр бит!.. Шуннан соң Фәрдетдин дә, ныклы бер карарга килеп, атаклы очучы Николай Гастелло үрнәгендә, дөрләп янучы очкычны гитлерчыларның җанлы көчләре һәм хәрби техникасы өстенә юнәлтә. Фашистларның ныгытмалары өстенә җитәрәк, алар тагын 2 бомба ташларга өлгерәләр. Куәтле һава дулкыны ике дус утырган очкычны янә күккә чөя һәм бераздан Малукса бистәсе читендәге сазлыкка илтеп чумдыра...

Бары тик 59 ел вакыт үткәннән соң гына, «Ил-2» штурмовигы үзенең биредә барлыгын сиздерә. Хәрби очкыч үзен йоткан тирәнлектән ниндидер илаһи көч-кодрәт белән өскә күтәрелә башлый. Океан киңлегендә ярдәм сорап, SOS сигналы бирүче ак корабтай, иң элек сазлык өстенә аның уң канаты калкып чыга. Моны янәшәдәге Белое күленә йөрүче балыкчылар, аучылар күреп алалар һәм сәер табылдык турында тиешле оешмаларга тиз арада җиткерәләр.

2002 елның 22 июнендә – дәһшәтле сугыш башлануга нәкъ 61 ел тулган көнне – хәрби очкычны сазлыктан чыгару эшләре башлана. Бирегә Ленинград өлкәсенең Киров районы эзтабарларыннан торган «Мга», «Высота» отрядлары килә. Аларга шулай ук Можайский исемендәге хәрби-инженерлык акаде-

миясенең «Космос» эзләнү отряды әгъзалары да булыша. Ленинград өлкәсе эзтабарлары белән бергә, иңгә-иң торып, Татарстаннан һәм Удмуртиядән килгән отрядлар да эшли. Дүрт метр тирәнлектә яткан хәрби очкычны өскә күтәрү берничә атнага сузыла. Сазлыкка юл салу, самолет янәшәсендәге болганчык суны куәтле насослар ярдәмендә суырту, хәрби очкычны махсус чыгырлар ярдәмендә корырак урынга тарттыру һәм шартлау-фәлән булмасын өчен тиешле хәзерлек чараларын күрү шактый күп вакытны ала... Әмма нәтиҗәләр көткәннән дә яхшырак була. Иң гаҗәбе шул: самолет кабинасы зыян күрмәгән диярлек! Шуңа күрә биредә очучының да, аның ярдәмчесенең дә гәүдәләре (җәсәдләре) чагыштырмача яхшы сакланган. Кесәләрендәге таныклыклар аша алар турында шактый тулы мәгълүматлар алына. Шулай итеп, татар егете белән урыс егетенең уртак батырлыгы яңадан өскә калкып чыга, күпләгән күңелләрне айкалдырып куя, тарихи дөреслек турында сөйләүче гуаһнамәләрне эзләп, архивларда кат-кат эшләргә, әлеге каһарманнарны белүчеләр белән якыннан аралашырга рухландыра...

## 2. Исемең калсын, үзең үлсәң дә...

Хәзер инде шул батырларның беренчесе белән ныклабрак танышып үтик. Чыннан да, нинди шәхес ул Фәрдетдин Сәхәбетдинов? Аны көчле рухлы зат итеп нинди мохит-тирәлек тәрбияләгән? Фәрдетдин Татарстанның Мөслим районы Югары Табын авылында 1919 елның 29 октябрендә дөньяга килгән. Якты күңелле Сәхәбетдин абый белән сөйкемле Таҗылбанат апаны әти-әни иткән иң беренче бала ул! Мәхәббәт язының тәүге ләйсән яңгыры, күз яшьләрендә салават күпере балкыткан, «Нәсел тамыры!» дип, ихластан сөендергән углан-малай ул!

Киләчәктә ошбу ишле гаиләдә унбер бала (!) туса да, ата-ана барлык улларын-кызларын бертигез күреп яратса да, Фәрдетдин барыбер беренче Бала, беренче Шатлык, беренче Горурлык булып калачак! Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалгач, ул әти-әнисенә дә, туганнарына-якыннарына янә дә кадерлерәк, газизрәк булачак әле...

Фәрдетдин туган авылы мәктәбендә өч ел гына укырга өлгерә. Шуннан соң аларның эшчән гаиләсен, ике сыер, ат, берничә сарык асраганнары өчен, «кулак токымы» дигән мө-

һөр сугып, Югары Табыннан читкә сөрәләр. Дәһшәтле-кара егерме тугызынчы еллар бу. Сәхәбетдин абый белән Таҗылбанат апа, мең дә бер мәшәкать-авырлык күреп, өч бала (Фәрдетдин, Харрасетдин, Нәкыя) белән Ижау каласына килеп, ярым җимерек баракка урнашалар. Һәм икәүләшеп заводта эшли башлыйлар. Тора-бара алар шәһәрнең тау битендәге Комсомол урамында яңа йорт та җиткерәләр. Фин сугышында сул кулын калдырып кайткан Сәхәбетдин абый уң кулы белән берүзе ун кешелек эш башкара! Бихисап һөнәрләргә ия булуы, тынгысызлыгы-җитезлеге, булдыклылыгы белән бик күпләрне сокландыра ул! Таҗылбанаты да, гәүдәгә кечкенәрәк булса да, төш кенә! Уңганлыгы, һәр эшкә кулы ябышып торуы, ярдәмчеллеге белән иренә бик тә тиң-пар килгән...

Фәрдетдин исә Ижаудагы 5 нче урта мәктәптә укуын дәвам иттерә. Югары Табындагы кебек, биредә дә барлык фәннәрне бары тик «бик яхшы» билгеләренә генә үзләштерә. Аннары яшүсмер, балачак хыялына тугрылык саклап, шәһәрдәге аэроклубка йөри башлый. Максаты – кинофильмдагы Чкалов кебек, курку белмәс, тәвәккәл очучы булу!

Бераздан, 1940 елның 18 сентябрендә, Фәрдетдинне Кызыл Армия сафларына, хәрби хезмәткә чакыралар. Ижевск аэроклубында тиешле хәзерлек үткән, яхшы чыныгу алган өметле яшь егетне, ике дә уйлап тормыйча, Сарытау өлкәсендәге Балашов шәһәренә, хәрби очучылар әзерли торган махсус уку йортына озаталар. Анда да тырышып укып, хәрби техника серләрен ныклап үзләштерә Фәрдетдин – командирлары тарафыннан курсантның әти-әнисенә җибәрелгән рәхмәт хатлары шул хакта сөйли...

1943 елның 1 гыйнварыннан инде Ф.Сәхәбетдинов мөстәкыйль очышлар ясый башлый. Тәвәккәллеге, һавада оста хәрәкәт итүе, бер үк вакытта һәркемгә, һәрчак булышырга әзер торуы белән командирларының да, хезмәттәшләренең дә тирән хөрмәтен, олы ышанычын казана очучы егет.

Волхов фронтында 14 нче Һава армиясе оештырылгач, кече лейтенант Ф.Сәхәбетдиновны 281 нче штурм авиадивизиясе карамагына җибәрәләр. Шул дивизия составына керүче 703 нче авиаполк составында ул, куәтле «Ил-2» штурмовигы белән, дошман аэродромнарындагы хәрби очкычларны, радиолокация станцияләрен, зенит батареяларын, танкларны, хәрби ныгытмаларны, фашистларның җанлы көчлә-

рен тар-мар итүдә турыдан-туры катнаша. Һәм, үз частенда хезмәт итүчеләр арасында беренчеләрдән буларак, Һава армиясе командующие – Советлар Союзы Герое, авиация генерал-лейтенанты И.Журавлевның шәхси рәхмәтенә, истәлекле бүләгенә (кул сәгате) лаек була. Әле Ф.Сәхәбетдиновның «Батырлык өчен» медале һәм Кызыл Йолдыз ордены да булырга тиеш (боларын безгә, Россия Саклану министрлыгының Мәскәү өлкәсендәге Подольск шәһәрендә урнашкан Үзәк архивына якын араларда барып, ныклап эзләргә туры киләчәк). Фәрдетдин, Җиңү таңын тизрәк якынайту өчен, көченнән-сәләтеннән килгәннең барысын да эшли. Хәрби заводта, көнне төнгә ялгап, сугыш кораллары җитештерүче кадерле әти-әнисенә, бертуган энеләренә һәм сеңелләренә җан җылыткыч хатлар язып салырга да вакыт таба. Хатларын егет кириллицада да, гарәп хәрефләре белән дә яза. Соңгылары – Коръән хәрефләре белән язылганнары – газиз әти-әнисе өчен...

Еллар үтү белән инде шактый саргая төшкән, әмма Тарих өчен, туганнары өчен, эзтабарлар өчен ифрат кыйммәтле, бәһа биргесез шул хатларының берсендә Фәрдетдин, якыннарын тынычландырырга теләп, кояш нурларыдай рухландыргыч-шифалы, хикмәтле сүзләр язып калдырган:

*«...Дошманга каршы көрәштә нинди генә авырлыклар күрсәк тә, кичерсәк тә, Җиңү барыбер безнең якта булыр! Моңа мин тирәнтен ышанам һәм сез кадерлеләрем белән күрешер көннәрне төшләремдә күреп юанам. Көтегез! Аллаһы Тәгаләдән бәхетле кавышуларны сорый-сорый, гел догада булып, зур сабырлык белән көтегез, өметегезне һич кенә дә өзмәгез...»*

Менә шушы сүзләр ата-ананың йөрәгенә шифалы бәлзәм булып ята.

*«...1943 елның 1 апрелендә хәрби заданиене үтәгәндә хәбәрсез югалды»* дигән мөһерле рәсми хат килгәч тә, башта моңа ышанмыйлар. (Ни әйтсәң дә, 1 апрель халык күңеленә алдау көне буларак та кереп калган бит!) Әмма Фәрдетдиннең сугышчан дусты Л.Усов җибәргән һәм кайдадыр адашып йөргән икенче хат (ул 1943 елның 28 мартында язылган була) күңелләрендәге шомлы-кара болытларны кинәт кабартып-куертып җибәрә:

*«Здравствуйте, дорогие родители!*

*Я, как хороший товарищ Вашего сына, хочу сообщить Вам о нем. Вас, конечно, эта новость очень огорчит. Ваш*

*сын не вернулся при выполнении боевого задания. Или, короче говоря, погиб. Да, погиб он храбро, он упал на ненавистных нам врагов. Мы потеряли хорошего боевого товарища, а Вы потеряли сына. Да, я знаю, что Вам тяжело переносить это. Но, Мамаша, нам тоже тяжело. Я с ним вместе спал, все делал вместе и вдруг такой случай...*

*Но Вы знаете, не одна Вы такая. Вот только бы покончить со зверьми человечества. А для этого мы отдадим все силы, а если и потребуется, поступим же так, как Ваш сын-летчик...»*

Шушы хатны укыганнан соң, хәтердә каһарман шагыйрь – үзе дә Волхов фронтында дошманга каршы «утлы» каләме белән көрәшкән легендар Муса Җәлилнең «Батырлык турында» дигән шигырендәге мәгълүм юллар яңара:

Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып.
Исемең калсын, үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык!..

Әйтерсең лә әлеге шигырь Фәрдетдин Сәхәбетдинов кебек тәвәккәл җаннарга атап язылган...

## 3. Эзтабарлар фидакарьлеге

Сугышчан дусты Л.Усовның хатыннан күренгәнчә, Фәрдетдин яу кырында батырларча һәлак булган. Аның дошманга каршы курку белмәс лачындай кыю сугышканына ныклап ышансалар да, һәлак булуына һич кенә дә ышанасылары килми Сәхәбетдин ага белән Таҗылбанат апаның. Аннары аларны ике нәрсә гаҗәпкә калдыра: 42168 нче хәрби частьтан язылган хатта Фәрдетдиннең һәлак булу вакыты итеп 1943 елның март азагы күрсәтелсә, авиадивизия штабыннан килгән рәсми хатта «1943 елның 1 апрелендә» диеп әйтелә. «Кайсысына ышанырга?» дип озаклап баш ваткannan соң, ата-ана Фәрдетдинне гомер буе – соңгы сулышларын алганчыга кадәр көтәргә үзара вәгъдә бирешә. Чөнки уллары көтәргә кушкан бит!..

Карты үлгәннән соң, күзләре сукыраеп, 88 нче яшендә бакый дөньяга күчәр алдыннан – 1986 елның ноябрендә – Таҗылбанат апа да балаларына:

– Сез дә Фәрдетдин абыегызны эзләтегез һәм кайтканын көтегез, яме! – дигән изге васыятен әйтеп калдыра.– Нигәдер ул миңа һаман да исәндер, тиздән, бик тиздән кай-

тып керер кебек тоела. Төшләремдә аны гел елмайган килеш, ак күлмәктән күрәм...

Таҗылбанат апа дөрес сиземләгән икән...

...2002 елның 12 июлендә «Татарстан» радиосы эзтабарлар тарафыннан Ленинград өлкәсендәге бер сазлыкта хәрби самолет кабинасында очучы-кече лейтенант Фәрдетдин Сәхәбетдинов белән укчы-сержант Егор Кретовның чагыштырмача яхшы сакланган гәүдәләре табылуы хакында каткат хәбәр итә, аларны якыннан белүчеләрне эзли. Очучының Татарстанда – Мөслим районы Югары Табын авылында туып үскәнлеге һәм хәрби хезмәткә Удмуртиянең Ижевск шәһәреннән алынуы да әйтелә. Могҗизага тиң әлеге хәбәрне Удмуртиянең Ува станциясендә яшәүче Нәкыя ханым белән Исмәгыйль әфәнде Минһаҗетдиновлар беренче булып ишетәләр. Аларның радиоалгычлары бу чакта Казан дулкынына көйләнгән була. Шунысын да искәртеп үтик: Нәкыя ханым – Фәрдетдин Сәхәбетдиновның бертуган сеңлесе бит!.. Ирле-хатынлы Минһаҗетдиновлар тиз генә Ижевск шәһәренә, Разия ханым белән Нәсим Сәхәбетдиновлар гаиләсенә телефоннан шылтыраталар: «Ишеттегезме әле, Фәрдетдин абыебызны тапканнар бит!»

Шуннан соң китә елашулар, туганнар белән, Фәрдетдинне якыннан белүчеләр белән кат-кат очрашулар!.. Ленинград өлкәсе, Татарстан һәм Удмуртия эзтабарлары да, табылган һәр ике каһарманның үткән тормыш юлларын ачыкларга теләп, күп кенә рәсми оешмалар, аерым кешеләр белән кат-кат элемтәгә керәләр. Татарстандагы «Кар десанты» отряды эзтабарлары башлыгы, «Хәтер Китабы»ның дистәләгән томнарын дөньяга чыгаручы иҗади-эшче төркем җитәкчеләренең берсе, шул өлкәдәге изге-олуг хезмәтләре өчен Татарстан Дәүләт бүләгенә лаек булган Михаил Черепанов, «Ленинград өлкәсенең эзтабар отрядлары» иҗтимагый фонды советы рәисе урынбасары Илья Прокофьев, Санкт-Петербург эзтабарларының «Космос» отряды җитәкчесе полковник Сергей Панин, Удмуртия эзтабарларының «Долг» оешмасында 13 ел дәвамында нәтиҗәле эшләп килүче тынгысыз җанлы милләттәшебез Фаил Ибраһимов (ул Ижевск шәһәренең 17 нче лицеенда тарих укыта; җәйге ялы вакытында, якын дуслары белән бергә, яу кырларында барлыгы 2500гә якын сугышчының җәсәдләрен табып, аларны туганнар каберлегенә хөрмәтләп күмүдә турыдан-туры катнаша.– *Ш.М.*)

булган бар мөмкинлекләрдән файдаланып, тиешле мәгълүматларны тиз арада табалар һәм бер-берләре белән даими хәбәрләшеп-аралашып торалар. Шулай итеп, очучы-лейтенант Ф.Сәхәбетдиновның Удмуртиядә яшәүче Нәкыя, Мәдинә, Разия һәм Әмирҗан исемле бертуганнары ачыклана.

Курск егете – укчы-сержант Е.Кретовның да Иван исемле бертуганы табыла. Ул хәзер гаиләсе белән Орел шәһәренә килеп төпләнгән икән. Эзтабарлар аның белән дә нык-лы элемтә урнаштыралар...

## 4. Батырлык мәйданы чакыра

Көннәрнең берендә Удмуртия хәрби комиссары генерал Геннадий Барсков адресына Ленинград өлкәсе хөкүмәтенең яшьләр, физик тәрбия, спорт һәм туризм эшләре буенча комитеты рәисе Раиса Карташовадан рәсми хат килеп төшә. Анда эзтабарлар тарафыннан 2002 елның җәендә Ленинград өлкәсенең Киров районы Белое күле янәшәсендәге сазлыкта хәрби самолет кабинасында табылган ике каһарман – очучы-кече лейтенант Сәхәбетдинов Фарадык (хәрби документларында Фәрдетдиннең исемен шулай язганнар.– *Ш.М.*) Сәхәбетдин улы, укчы-сержант Кретов Егор Васильевич турында хәбәр ителә. Хат җибәрүнең төп сәбәбе шул: хәрби хезмәткә Ижевск аэроклубыннан алынган Ф.Сәхәбетдиновны һәм аның сугышчан дусты Е.Кретовны шушы елның 10 октябрендә Ленинград өлкәсенең Киров районына керүче «Новая Малукса» мемориаль комплексында – Батырлык мәйданында зур кадер-хөрмәт күрсәтеп җирләргә җыеналар икән. Хат авторы генералдан очучы Фәрдетдин Сәхәбетдиновның туганнарын, әлеге тантаналы-кайгылы чарада катнаштыру өчен, Ленинград өлкәсенә җибәрүдә матди-рухи яктан булышлык итүне сорый...

27 сентябрьдә факс аша Удмуртия хәрби комиссарына килгән хатның күчермәсен тиз арада батырның туганнарына җиткерәләр (Раиса Алексеевна Геннадий Васильевичка юллаган үтенечендә Разия ханымның Ижевскидагы төгәл адресын һәм өй телефоны номерларын да күрсәткән була). Әлбәттә, очучы Фәрдетдиннең туганнары иң олы абыйлары зур батырлык күрсәткән изге урынга барырга бик тә ашкынып тора. Әмма бер җитди тоткарлык бар, ул да булса – финанс кытлыгы. Хәрби комиссариатның да барысын берьюлы җибәрергә мөмкинлеге юк. Үзара ныклап киңәшкәннән

соң, Ленинград өлкәсенә Фәрдетдиннең иң кече сеңлесе Разия ханым белән гаиләдә унберенче бала булган Әмирҗан әфәндене җибәрергә килешәләр. Аларны озатып йөрергә Удмуртия Татар иҗтимагый үзәге вәкиле – элек Хәрби-диңгез флотында хезмәт иткән офицер-штурман, 30 ел дәвамында хәрби заводта инженер-механик булып эшләгән Мифтахетдин әфәнде Фәрдиев үзе теләп алына.

Ерак юлга чыгарга санаулы гына көннәр калганда, Фәрдетдин туганнарының күңелләрен бер якты уй балкытып җибәрә: «Ә нигә абыйларының җәсәден, зур кадер-хөрмәт күрсәтеп, мөселманча, үзебездә, ягъни Ижевскидагы татар зиратында җирләмәскә?!» Газиз эти-әниләре, күп кенә туганнары да шунда үзләренә мәңгелек урын тапкан бит! Фәрдетдиннең үз янәшәләренә кайтуына аларның да рухлары сөенер иде.

Тик бу олы эшне башкарып чыгу – очучы каһарманның җәсәден алып кайту өчен ерак юлга чыгарлык төзек һәм куәтле техникасы булган тәвәккәл җитез егетләр һәм матди яктан зур чыгымнар кирәк. Нишләргә, кемнән ярдәм сорарга? Разия ханым белән без сентябрь аеның ахырында, аны һәм туганнарын әнә шундый җитди уйлар борчыган киеренке бер көндә очраштык. Без дигәнем – Ижевскида яшәүче искиткеч ярдәмчел, якты күңелле татар шагыйре, берничә китап авторы Ринат әфәнде Батталов, «Ватаным Татарстан» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, шагыйрә һәм публицист Асия ханым Юнысова һәм бу юлларның авторы. Удмуртиягә без, бер төркем татар язучылары, җырчылар һәм музыкантлар катнашында, «Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре»н үткәрү өчен килгән идек. Мөмкинлектән файдаланып, Разия ханымны Ижевск каласының мең кеше сыйдырышлы «Аксион» мәдәният сараенда үткән кичәбезгә дә чакырдык. Һәм, Фәрдетдин батыр турында күбрәк, тулырак белү өчен, аларның гаиләсе яшәгән кунакчыл фатирга да бардык. Соңыннан бирегә «Татарстан яшьләре» газетасы журналисты – Мөслим кызы (каһарманның якташы!) Лилия Сөнгатуллина да килеп җитте. Сәхәбетдиновларны борчыган проблемаларны чишү юллары да әнә шул эшлекле-дустанә, ихлас сөйләшүләр барышында хәл ителде. Без аларга бу мөһим мәсьәлә уңаеннан Удмуртия Татар иҗтимагый үзәге президенты – чын мәгънәсендә эшлекле-кыю шәхес, оста оештыручы булган Фнүн әфәнде Мирзаяновка мөрәҗәгать итәргә тәкъдим ясадык. Һәм ялгышмадык.

Ул эшне бик тиз тотты. «Ихлас» хәйрия фонды директоры, Удмуртиядә мәчетләр төзелеше буенча Попечительләр советы рәисе Нәгыйм Каюмов белән фикерләшкәннән соң, кирәкле техника да, акча да табылды. Фәрдетдиннең җәсәден Ижевскига кайтару буенча тоткарлыклар булмасын өчен, Фнүн әфәнде Санкт-Петербург губернаторы В.Яковлевка Удмуртия Татар иҗтимагый үзәге һәм мөселманнарның дини идарәсе исеменнән махсус хат та юллады. Шундый ук рухтагы хат, Удмуртия хөкүмәте Рәисе урынбасары В.Савельев имзасы белән, Ленинград өлкәсе хөкүмәтендә мәгълүм җитәкчеләрнең берсе саналган Р.Карташовага да җибәрелде.

Ниһаять, Разия ханым, аның бертуган энесе Әмирҗан һәм гаиләләренең якын дусты-киңәшчесе Мифтахетдин Фәрдиев 7 октябрь иртәсендә «Ижевск–Санкт-Петербург» поездына утырдылар. Күңелләрне үзенә бертөрле серлелек белән дәшеп торган әлеге ерак сәфәргә чыгар алдыннан, озаклап дога кылдылар. Чөнки алдагы кичтә генә Разия ханымның төшенә йөзләре кояштай балкыган әнисе һәм үзен бер тапкыр да күрмәгән, бары тик хәрби киемдәге фоторәсеме аша гына таныш булган абыйсы Фәрдетдин кергән була. «Хәерле юл сезгә, балакайларым!» – дип, ахырдан үзенең фатыйхасын да бирә аларга Таҗылбанат абыстай...

Ә 9 октябрьдә Разия ханымнар артыннан Санкт-Петербургка, «Газель» машинасына утырып, Рәүф Гастинов (Газетдинов), Линар Хәмидуллин кузгалды. Юлларны яхшы белгән, күпне күргән әлеге гаярь ир-егетләр Фәрдетдиннең җәсәден Ижевскига алып кайтырга тиешләр иде. Ә бу вакытта Мифтахетдин Фәрдиев җитәкчелегендәге делегация, Санкт-Петербургка барып җитеп, рәсми оешмалар белән Ф.Сәхәбетдиновка кагылышлы сөйләшүләр алып бара иде инде. Нигездә сүз батырның җәсәден үзе армиягә алынганчы яшәгән төбәгенә алып кайтып җирләү турында булды. Баштарак моңа: «Бу – безнең церемония программасына туры килми!» – дип каршы төшсәләр дә, ахырдан, Мифтахетдин әфәнденең һәм очучы туганнарының дәлилле-хаклы таләпләрен, рухи ихтыяҗларын аңлап, аларның үтенечләрен канәгатьләндерергә риза булдылар. Әмма шундый шарт белән: бер экипаж составында булган ике каһарманның да җәсәдләрен Батырлык мәйданында янәшә куярга һәм аларга соңгы кадер-хөрмәтне дә бергәләп күрсәтергә! Бу тәкъдим күңелләрдә шундук хуплау тапты...

## 5. Рухи туганлашу

...10 октябрь көне Ленинград өлкәсенең Киров районындагы «Новая Малукса» хәрби мемориаль комплексында мәңге онытылмас Хәтер көне булып кереп калыр. Күңелләрдәге рухи халәткә тәңгәл килеп, биредә иртәдән бирле кар катыш яңгыр явып торды. Әмма мәйданга җыелган бихисап кешеләрне һаваның мондый торышы һич кенә дә куркытмады. Чөнки алар Үлемсезлек дөньясына күчкән газиз җаннар турында уйландыра, хәтерләрне яктырта, йөрәкләрне җылыта торган Мәңгелек ут янына килгәннәр иде. Әлеге Ут хәзер тагын да көчлерәк булып балкыгандай тоелды. Чөнки аңа Ил-Ватан иминлеге өчен газиз гомерләрен биргән тагын ике каһарманның ярсулы йөрәк ялкыннары килеп кушылган иде...

– Бүгеннән башлап әлеге Батырлык мәйданында татар һәм урыс милләтләреннән булган ике каһарманның – очучы-кече лейтенант Фәрдетдин Сәхәбетдин улы Сәхәбетдинов белән укчы-сержант Егор Васильевич Кретовның данлы исем-фамилияләре мәрмәр плитәдә янәшә торыр, яшь буынны, алар кебек, чын дуслыкка соңгы минуткача тугры булырга, Хәтер сагында һәрчак уяу торырга, эзләнүләрне туктатмаска, моңарчы билгесез булган яңадан-яңа батырларны табарга өндәр! – диде әлеге матәм җыенында чыгыш ясаган Раиса Карташова. Ул, Ленинград өлкәсе хөкүмәте җитәкчеләре исеменнән, Ф.Сәхәбетдинов белән Е.Кретовның туганнарына, дусларына, ерак юлны якын итеп килгәннәре өчен, ихластан рәхмәт сүзләре әйтте, эзтабарларның тынгысыз фидакарьлегенә югары бәя бирде. Өлкәнең Киров районы хакимияте башлыгы урынбасары О.Шаулова, хәрби комиссар, полковник В.Зотов, бу төбәктәге эзтабарларның эшчәнлегенә җитәкчелек итүче И.Прокофьев һәм тагын башка бик күпләрнең ихлас-эчкерсез чыгышларыннан тирәнтен дулкынланган Разия ханым белән Әмирҗан әфәнде дә, очучы батырның туганнары исеменнән, рәхмәтле җавап сүзләре белән чыктылар. Удмуртия делегациясе җитәкчесе Мифтахетдин әфәнде Фәрдиев исә, бөтен шартын туры китереп, Фәрдетдин батырның якты рухына Коръән сүрәләре укыды һәм аларның мәгънәләрен җыелган халыкка аңлатып та бирде.

Санкт-Петербургтан махсус килгән Искәндәр хәзрәтнең чыгышы да зур кызыксыну белән тыңланды...

Аннары укчы-сержант Егор Кретовны, хәрбиләрчә, шул

ук вакытта христиан дине йолаларын да үтәп, мемориаль үзәктә җирләү булды. Бирегә аның Орел шәһәрендә яшәүче бертуган энесе Иван Васильевич та үзенең улын ияртеп килгән иде. Фәрдетдин батырның туганнары белән шундук дуслашып киттеләр алар һәм киләчәктә хатлар алышып, аралашып яшәргә үзара вәгъдәләр дә бирештеләр. Иван Васильевич Разия ханымга абыйсының фоторәсемен һәм күкрәк кесәсендә йөрткән 4263096 нчы номерлы комсомол билетының фотокүчермәсен дә бүләк итте.

Хатын-кыз затыннан буларак, Разия ханым бу сәфәр вакытында аеруча зур тетрәнү хисләре кичерде. Ак төннәр башкаласында булуыннан файдаланып, Разия ханым иренең биредә яшәүче якын туганы Нурлыхода ханым Сафинаны да эзләп тапты. Ленинград блокадасының бөтен авырлыгын үз җилкәсендә татыган өлкән яшьтәге бу ханым алар килүгә чиксез сөенде. Аннары бергә Санкт-Петербургтагы мәһабәт мәчеткә барып, әти-әниләре, Фәрдетдин һәм башка туганнары-якыннарының изге рухларына багышлап догалар да кылып кайттылар.

Әнә шулай Батырлык мәйданына алар рухи яктан да чистарынып, пакь күңел, ак уйлар белән килделәр. Аңардагы илаһи балкышны Раиса Карташова да беренчеләрдән булып күреп алды, һәм ул, Разия ханымны кочагына алып һәм җилкәсеннән туганнарча кагып:

– Ярый әле килдегез, сез булмасагыз, бу мәрәсимнең бер чите китек була иде,– дип, Удмуртия делегациясенә карата үзенең тирән хөрмәтен белдерде...

Очучы Фәрдетдин Сәхәбетдиновның җәсәден Ижевскига алып кайтканда юлда тоткарлыклар булмасын өчен, рәсми оешмаларның җитәкчеләре кул куйган, герблы мөһерләр сугылган махсус кәгазьләрне дә тиз арада әзерләп бирделәр. Шул эшләрне төгәлләүгә, Ижевскидан Рәүф Гастинов һәм Линар Хәмидуллин «иярләгән» «Газель» машинасы да килеп җитте. 30 сәгать буена (!), бер-берсен алыштырып, руль артында утырган ир-егетләр, ерак юлда шактый алҗыган булсалар да, үзләренең нәкъ вакытында исән-имин килеп җитүләренә, әйткән сүзләрендә торуларына ихластан сөенәләр дә иде. Алар күңелендәге яктылык башкалар күңеленә дә күчте...

«Белые ночи» кунакханәсендә яхшылап ял итеп алганнан соң, 11 октябрь көнне иртәнге 9 сәгатьтә кайтыр юлга кузгалдылар. Батыр очучының җәсәден саклап алып кайту өчен

«Газель» машинасына Мифтахетдин Фәрдиев үзе дә утырды. Разия ханым белән Әмирҗан әфәндене исә, «Санкт-Петербург – Ижевск» поездына билетлар алып, матур гына озатып җибәрделәр...

## 6. Хәтер көне – Үлемсезлек көне

Ниһаять, 13 октябрь таңында Фәрдетдин батыр җәсәден Ижевскига кайтарып җиткезделәр. Юлда, бары тик Владимир шәһәрендә генә тукталып, бераз ял итеп алдылар. Белгән догаларын сәфәр дәвамында гел укып кайтты Мифтахетдин әфәнде. Шуңа күрә – Ходай Тәгаләнең рәхмәте беләндер инде! – юлда зур кыенлыклар булмады.

Очучының җәсәден беренче кичтә М.Фәрдиев үз йортында кундырды. Аннары каһарманны Разия ханымнар фатирына алып килделәр. 15 октябрь иртәсендә бирелә аны, цинк табуттан алып, мөселман йолаларын тулысынча үтәп, тәхлил әйтеп, догалар укып, Мифтахетдин әфәнде Фәрдиев белән мәчет аксакалы Мәхмүт ага Нуретдинов яхшылап юдылар, ахирәт күлмәге кидерделәр һәм тагын ике кат ак җәймәгә төрделәр. Шуннан соң гына Фәрдетдин батырның җәсәден, агач табутка салып, өстенә әләм ябып, Ижевск шәһәре үзәгендәге Мәңгелек ут янына алып килделәр. Монда янә бер мәртәбә олылау мәрәсиме булды. Бирегә Удмуртиянең һәм Татарстанның төрле төбәкләреннән меңнәрчә кеше җыелган иде. Араларында чал чәчле генераллар да, югары дәрәҗәле офицерлар да һәм япь-яшь солдатлар, курсантлар да бар иде.

Кайгылы-тантаналы җыенны Ижевск шәһәре вице-мэры С.В.Протозанов ачты һәм алып барды. Сергей Владимирович, 24 яшьлек очучы Ф.Сәхәбетдиновның олуг батырлыгын югары бәяләп:

– Безнең Ижевск аэроклубын данлаучы, аны дөньяга танытучы кыю лачыннарның берсе ул! – диде.– Ватаныбыз тарихына тәвәккәл татар егете Фәрдетдин Сәхәбетдин улының да исем-фамилиясе алтын хәрефләр белән язылыр!..

Чыгыш ясаучылардан Удмуртия эзтабарларының «Долг» оешмасы җитәкчесе Фаил Ибраһимов, республиканың Татар иҗтимагый үзәге президенты Фнүн Мирзаянов, милләтпәрвәр шәхес Мифтахетдин Фәрдиев һәм башкалар киләчәктә Фәрдетдин батырның якты истәлеген мәңгеләштерү юнәлешендә башкарылырга тиешле эшләргә тукталдылар.

Аерым алганда, әлеге каһарман укыган 5 нче урта мәктәптә һәм аэроклубта аңа багышланган махсус стенд яисә музей бүлмәсе булдырырга, ел саен 15 октябрьдә «Батырлык» дәресләре үткәрергә, Фәрдетдиннең данлы исемен шәһәрнең яңа төзелеп килүче бер урамына кушарга дигән фикерләр әйтелде. Ижевск–Казан арасында йөрүче экспресска «Гастеллочы Фәрдетдин Сәхәбетдинов» дигән исем бирү тәкъдиме белән дә чыктылар җыенда...

Бу көнне Разия ханымның да күңеле тулышкан иде. Ижевск аэроклубы курсантларына бертуганы Ф.Сәхәбетдиновның шәхси әйберләрен музейга куяр өчен тапшырганда, ул, тирәнтен дулкынланып, болай диде:

– Гомерем буе мин могҗиза көтеп яшәдем. Ниһаять, ул көн килде! Иң олы абыебыз Фәрдетдин, дистәләрчә елларга сузылган хәрби очыштан соң, сугышка кадәр яшәгән җиренә әйләнеп кайтты, мәңгелеккә кайтты! Әгәр дә газиз әтиебез белән әниебез исән булсалар, меңләгән кешеләрнең – төрле милләт вәкилләренең – гади бер татар егетенә күрсәткән кадер-хөрмәтен күреп, чиксез сөенерләр-горурланырлар иде...

Чынлап та, горурланырлар иде!

Фәрдетдин батырның җәсәден Ижевск шәһәрендәге татар зиратына илткәндә, дистәләрчә машиналардан торган матәм колоннасын уздырып җибәрү өчен, һәр җирдә хәрәкәт тукталды. Бу көнне бөтен Ижевск халкы аякка басты – үзенең каһарманын зурлау өчен! «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Удмуртская правда», «Яңарыш» газеталары, телевидение һәм радио хезмәткәрләре дә Фәрдетдин батыр турында иң мөһим мәгълүматларны биреп бардылар. Шуңа күрә дә, каһарманны соңгы юлга озатыр өчен, татар зиратына да бик күп кеше килде. Җеназа намазын Удмуртия мөфтие урынбасары, Ижевск мәчетенең имам-хатибы Фаиз хәзрәт Мөхәммәтшин укыды. Алты ел дәвамында Мәккәдә һәм Мәдинәдә яшәп, дин гыйлемнәрен яхшылап үзләштергән Фаиз хәзрәтнең күңелләрне уята торган вәгазе беркемне дә битараф калдырмады.

– Үткәнен белмәгән-барламаган хәтерсез кешенең киләчәге юк,– диде ул, җыелган халыкка мөрәҗәгать итеп.– Шуңа күрә без, җәмәгать, Иманлы Хәтер сагында һәрчак уяу торырга бурычлыбыз. Киләчәктә шушы зиратта үзебезнең күренекле мөселман кардәшләребез өчен мемориаль үзәк бул-

дыру да бик фарыздыр. Мөхтәрәм Сәхәбетдин ага улы Фәрдетдин кардәшебезнең дә рухы моңа шат булыр иде...

Батыр якташларын соңгы юлга озатуда катнашучылардан Удмуртия Татар иҗтимагый үзәгенең беренче (шәрәфле) президенты, күренекле галим Мәсгут ага Гаратуев, Сарапул шәһәрендәге сугыш ветераннары Советы рәисе, милли хәрәкәт җитәкчеләренең берсе, отставкадагы полковник Илгиз ага Мансуров, «Ихлас» хәйрия фонды директоры, мәчетләр төзетүче Нәгыйм Каюмов, Удмуртия Дәүләт Советы депутаты Роберт Рыбаков, фронтовик Сәет ага Шакирҗанов, аксакал мөгаллим Әдип ага Кәримов, хезмәт ветераннарыннан Нургали ага Мөхәммәтшин, Әхмәт ага Хаҗиәхмәтов, Фәнүс ага Газизуллин, Рәис ага Зиннәтуллин һәм башкалар үзләренең уй-фикерләре белән уртаклаштылар. Ахырдан исә шундый кирәкле, күңелләрне кузгата торган бер шигарь дә яңгырады: Һәр елны 15 октябрьдә Фәрдетдин батыр кабере янына җыелып, илбасарларга каршы үз-үзләрен аямыйча көрәшкән шәһитләребезне искә алырга!.. Һәм бу чакыру һәркемнең йөрәгендә кайнар теләктәшлек тапты. Чөнки Хәтер көне – яңадан туу көне, Үлемсезлек көне ул!..

Фәрдетдин батырны заманында үзе армиягә алынган төбәк туфрагында гүргә иңдерү көне нәкъ менә 15 октябрьгә – Хәтер көненә туры килү Удмуртиядә яшәүче милләттәшләребезне киләчәктә тагын да оешканрак, бердәмрәк булып яшәргә өндәде кебек. Кемгә ничектер, безгә шулай тоелды. Амин, шулай була гына күрсен!

Моңсу тынлыкка чумган зиратта, берән-сәрән сары яфраклары гына калган агачларны сискәндереп, ату тавышлары яңгырады. Яшь солдатлар үзләренең өлкән ватандашларына әнә шулай хушлашу салюты бирделәр: «Тыныч йокла, каһарман... Без сине һәрчак истә тотарбыз!» Кабер өстенә сары сагыш төсендәге яфраклар коелды, яңгыр тамчылый башлады...

* * *

Абыйсын җирләп кайткан шул ук көнне төнлә белән Разия ханым төш күрде: Таҗылбанат апа, Фәрдетдинне үз кочагына алып, аркасыннан кат-кат сыйпый-сөя иде: «Кайтасыңны алдан белгән идем, улым! Рәхмәт, өметләремне акладың! Хәзер инде без мәңгелеккә бергә – Киек Каз юлында-

гы йолдызлар кебек...» Икенче бер мизгелдә ак күлмәкле, көләч йөзле Фәрдетдин, Ижевск белән Казан арасында уктай очучы электричка-экспрессның машинисты буларак, Удмуртиядән – Татарстанга, Татарстаннан Удмуртиягә пассажирлар илтә иде. Ни өчендер ул башына тимерьюлчылар кия торган фуражканы түгел, ә Разия ханымга Санкт-Петербург эзтабарлары бүләк итеп биргән очучылар фуражкасын кигән иде...

Йокысыннан уянгач та, Разия ханым моны ни дип тә юрарга белмәде. Күрәсең, Фәрдетдин абыйсының җаны да ике республика арасында Дуслык поездының пар канатлы очкычтай очып йөрүен бик тә тели иде...

## 7. Йомгаклау сүзе урынына

Борынгы грек мифологиясендә Феникс исемле тылсымлы кош турында гыйбрәтле хикәят бар. Әлеге кошның туган җире Эфиопия саналып, аңа исемне ассириялеләр биргән дип әйтелә. Ким дигәндә 500 ел яшәүче ошбу хикмәтле кош (кайбер чыганакларда Фениксның гомер озынлыгы итеп 1460 ел яисә 12954 ел күрсәтелә.– *Ш.М.*), котылгысыз үлем якынаганын сизсә, үз оясында үзен яндыра икән. Әмма шул мизгелдә аның көленнән яңа кош калкып-балкып чыга, ди. (Кара: «Мифы народов мира», II том, М., «Советская энциклопедия» нәшрияты, 1982 ел, 564 бит.)

Безнең каһарманнарның да батырлыклары, шул Феникс кебек, мәңге үлемсез, искиткеч кодрәтле Яшәү Көченә ия! Шәһитләребезнең җаннары һәм даннары, ару-талуны белмәс меңьяшәр Кош кебек, гасырлардан гасырларга, күңеллрдән күңелләргә оча. Җир йөзендә, Галәмдә аларны туктатырлык, юк итәрлек бернинди көч һәм киртәләр дә юк!..

## МАРЕСЬЕВЧЫЛАР АРАБЫЗДА ЯШИ...

Атаклы язучы Борис Полевойның зур кызыксыну тудырган «Чын Кеше» исемле китабын укып, кемнәр генә тирән тетрәнү, соклану хисләре кичермәде икән?! Автор үзенең әлеге әсәрен 1946 елда, «Правда» газетасының өлкән хәбәрчесе буларак, Нюрнберг процессында – ата фашистларны хөкем иткән Халыкара хәрби трибунал утырышлары барган чорда, бер тында – нибары 19 тәүлек эчендә яза.

Төп гаепләнүчеләрнең берсеннән – Германия Хәрбиһава көчләренең элеккеге башкомандующие, рейхсмаршал Герман Герингтан хөкемдарлар сорау алганда, әлеге нацист болай ди: «Безнең өчен мәңгелек табышмак – җиңелү белмәс рус-совет кешесенең көчле характеры булды. Шуны үз вакытында аңлый алмаганга күрә, без дә, Наполеон кебек, зур хата ясадык...» Үз «гаебен» таныган-үкенгән булып кыланган Герингның шундый сүзләрен ишеткәч тә, Борис Николаевичның хәтерендә гаять истәлекле бер очрашу җанлана. 1943 елның җәендә ул, Орел-Курск дугасында сугышлар кызган бер мәлдә, 9 көн эчендә дошманның 47 хәрби очкычын юк иткән гвардия авиаполкы очучылары янында була. Һәм шунда ике аягы да протезлы, әмма фашист карчыгаларына каршы бик тә нәтиҗәле көрәшүче кыю лачынны күреп таң кала! Менә кайда ул безнең заман герое! Бер тамчы чык бөртегендә кояш чагылган кебек, ватанпәрвәр затлардан саналган шул бер очучы аша да безнең ил кешеләренең искиткеч көчле рухлы булуларын бик ачык күрсәтеп, сурәтләп була.

Б.Н.Полевой, зур рухлану белән, эшкә тотына. Соңыннан миллионлаган тиражлар белән дөньяның барлык төп телләрендә дөнья күрәчәк китабының үзәктәге каһарманы Маресьев белән әнә шулай танышып китәләр алар.

Әйе, китапта әлеге легендар очучы Мересьев дип телгә алынса да, чынлыкта ул Маресьев фамилиясен йөртә. Тулысынча итеп әйтсәк: Алексей Петрович Маресьев. Ул 1916 елның 20 маенда хәзерге Волгоград өлкәсенең Камышин шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбендә һәм эшче-яшьләр мәктәбендә укый. Аннары механик-дизелист булып Амур буендагы Комсомольск шәһәрендә эшли. Биредә Алексей аэроклубка йөри. 1937 елда Кызыл Армия сафларына алынгач, ул гомерен тулысынча авиациягә багышларга уйлый. 1940 елда А.Маресьев, Батайск хәрби авиация мәктәбен тәмамлап, очучы булып китә.

1941 елның августыннан башлап лейтенант Маресьев 580 нче истребительләр авиаполкы составында Төньяк-Көнбатыш фронтта дошманга каршы кыю көрәшә, һава сугышлары вакытында фашистларның байтак очкычларын юк итә...

1942 елның 4 апрелендә Новгород өлкәсенең Демянск плацдармындагы җитди хәрби хәрәкәтләр барышында А.Маресьевның очкычы, дошман утына юлыгып, нык зарарлана.

Һәм ул фашистлар биләгән мәйданга, урман эченә төшәргә мәҗбүр була. Аяклары нык җәрәхәтләнгән очучы 18 тәүлек дәвамында үлем белән көрәшә. Барлык көчен-ихтыярын туплап, зур авырлыкларны җиңеп, шуышып булса да, үзебезнекеләр ягына чыгарга тырыша Алексей Петрович. Бәхетенә, аны урманга чыбык-чабык җыярга килгән малайлар табып ала. А.Маресьевка беренче ярдәм күрсәтелә, аны тизрәк савыктыру өчен ашыгыч чаралар күрелә...

Әмма салкын-патша үзенең коточкыч эшен эшләгән була инде – көчле рухлы очучының нык өшегән ике аягын да кисәргә туры килә...

Алексей Петрович менә шуннан соң тагын да зуррак чыдамлык, тәвәккәллек, максатчанлык үрнәге күрсәтә. Көнетөне бихисап күнегүләр ясап, протез аякларда йөрергә – алай гына да түгел! – хәрби очкычлар белән идарә итәргә дә өйрәнә ул! 1943 елның июненнән башлап гвардия өлкән лейтенанты А.Маресьев яңадан дошманга каршы һава сугышларында катнаша башлый. Бу юлы инде ул Брянск фронты карамагындагы 15 нче Һава армиясенең 3 нче гвардияче истребительләр авиадивизиясен данлый. 63 нче гвардияче истребительләр авиаполкының эскадрилья командиры урынбасары буларак, А.Маресьев иң элек үзе шәхси үрнәк күрсәтә. Мәсәлән, Курск дугасында барган үтә җитди һава сугышлары вакытында ул дошманның өч очкычын бәреп төшерә...

1943елның 24 августында Алексей Петрович Маресьевка СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән мәртәбәле исем бирелә!..

1946 елда майор Маресьев, армия сафларында хезмәт итүеннән туктап, иҗтимагый-фәнни эш белән шөгыльләнә башлый. Аспирантура тәмамлап, тарих фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. 1956–1983 елларда ул СССР сугыш ветераннары комитетының җаваплы сәркатибе, 1983 елдан башлап – гомеренең ахырына хәтле – әлеге абруйлы комитет рәисенең беренче урынбасары вазифаларын башкара...

Мәскәүгә эзтабарлык эше белән барган вакытларымда, миңа әлеге легендар шәхес янында – Гоголь бульварындагы 4 нче йортта еш булырга туры килә иде. Һәркемгә карата искиткеч игътибарлы, гадел, туры сүзле, үтә ярдәмчел булуы өчен нык яраталар, тирән хөрмәт итәләр иде аны. Бихисап орден-медальләр белән бүләкләнгән отставкадагы полков-

ник А.П.Маресьев масаюны-кәпрәюне белмәде, бик күпләр өчен тыйнаклык һәм фидакарьлек үрнәге булып торды. Бал корты кебек эшчән, тиен кебек җитез иде ул...

Әле дә хәтеремдә, чираттагы бер очрашуыбыз вакытында мин аннан:

– Сезнең кебек шәхесләр – маресьевчылар бездә күпме? – дип сораган идем.

Һәм ул, һич тә иренмичә, миңа шундый гаярь очучылар турында байтак кына кызыклы мәгълүматлар бирде. Протез аяклы килеш, яңадан хәрби очкычларга утырып, фашистларга каршы үз-үзләрен аямыйча көрәшкән каһарманнардан гвардия полковниклары А.И.Грисенко, И.С.Любимов, майорлар А.Ф.Белецкий, Л.Г.Белоусов, гвардия капитаннары Г.П.Кузьмин, З.А.Сорокин, өлкән лейтенантлар И.М.Киселев, И.А.Маликовларның исем-фамилияләрен зур ихтирам хисләре белән телгә алды ул. Әлеге тәвәккәл очучыларның җидесе, һава сугышлары барышында исән калып, Җиңү көнен Хәрби-һава көчләре сафларында каршылыйлар. Ике аягы да протез булган гвардия капитаны Г.П.Кузьмин исә, 1942 елда яңадан үз частена кайтып, дошманның 18 очкычын бәреп төшерә, группалы очышларда тагын 8ен юк итә... Лачын йөрәкле офицер 1943 елда полк командиры очкычын дошман утыннан саклап кала һәм, көчләр тигез булмаган бәрелештә, фашистларның техникасын һәм җанлы көчләрен дә юк итеп, батырларча һәлак була.

Ә менә безнең «Кукмара Маресьевы» – Сергей Кузьмич Федоров турында Алексей Петрович моңарчы ишетмәгән-белмәгән икән әле. Мин аңа шул хакта, үз чиратымда, эзләнүләр үткәргәндә Үзәк архивта табылган өр-яңа мәгълүматларны тапшырдым. Хәзер сезгә дә шул хакта сөйләргә телим.

* * *

...Яңа гына хәрби авиация училищесын тәмамлап, Көнбатыш Украина территориясендәге эскадрильяларның берсендә хезмәт итүче яшь лейтенант С.Федоровны 1941 елның 22 июнь иртәсендә, башка очучылар белән бергә, «Тревога!» буенча күтәрәләр. Моны баштарак чираттагы күнегүләрдер дип уйлыйлар. Әмма нык ялгышканнар икән – фашистлар Германиясе Советлар Союзына каршы рәхимсез һөҗүм башлаган!..

Сергей Кузьмич беренче сугышчан чыныгуны әнә шул

кара сөремле июнь көннәрендә ала. Үзенең бомбардировщигы белән ул фашист танклары колонналарын, саранча өермәседәй ябырылган пехотасын тар-мар итүдә катнаша. Дошман гаскәрләренең Ватан йөрәгенә – Мәскәүгә таба баруларын мөмкин кадәр тизрәк туктату өчен, иптәшләре белән берлектә, алар үтәргә тиешле тимер юлларны, күперләрне, гаскәр һәм техника-ягулык төягән эшелоннарны шартлата...

– Беренче көннәр бик авыр булса да, без мәкерле дошманны җиңәчәгебезгә, эшебезнең хак икәнлегенә, урамыбызда бәйрәм булачагына тирәнтен ышандык,– дигән иде Сергей Кузьмич, бер әңгәмәбез вакытында.– Һәм шул ышану безнең йөрәкләргә бетмәс-төкәнмәс көч-дәрман бирде, авыр минутларда сынмаска-сыкранмаска өйрәтте...

Батыр якташыбыз С.К.Федоров үзләренең авиаполкы составында Көнбатыш фронтта һәм шулай ук Воронеж, Сталинград, Беренче һәм Икенче Украина фронтларында каһарманнарча сугыша. Украина, Молдавия, Румыния җирләрен, шәһәр-авылларын азат итүдә катнаша. «Сталинград оборонасы өчен», «Будапештны алган өчен» медальләре белән бүләкләнә. Тигезсез көрәштә байтак кына иптәшләрен югалта. Менә шул кайгылы көннәрдә Сергей Кузьмич гитлерчыларга каршы якын дуслары өчен дә бар көчен-сәләтен, бай тәҗрибәсен биреп көрәшергә, әгәр дә исән-сау калып, Туган илгә кайткан очракта, алар өчен дә тырышып эшләргә, намус белән яшәргә ант итә. Бу теләге аның 1944 елның җәендә, һава сугышларының берсендә каты яраланып, ике аягыннан мәхрүм калгач та сүнми-сүрелми. Киресенчә, тагын да көчлерәк булып дөрли. Чөнки Сергей Кузьмич фашист илбасарларының: «Тагын бер совет кешесен сафтан чыгардык!» – дип, вәхшиләрчә сөенүләрен теләми, нинди генә шартларда да кешенең Кеше булып калуын расларга омтыла.

* * *

Биредә бераз чигенеш ясап, Сергей Кузьмич Федоровны хөкүмәтебезнең олы бүләгенә тәкъдим иткән кызыклы бер хәрби документ белән якыннанрак танышып үтик.

*«...Башкомандование резервының 19 нчы авиадивизиясе карамагындагы Сталинград исемен йөртүче 138 нче авиаполкның авиазвено командиры иптәш Федоров,–* диелә

Бүләкләү кәгазендә,– *1944 елның 9 июнендә фашистларның Карпаттагы оборонасының алгы сызыгын утка тоту өчен бомбалар төяп очты.*

*Дошман зениткалары безнең самолетларга каршы ярсулы төстә ут ачуга карамастан, өлкән техник-лейтенант Федоров звеносы, үз бурычын тулысынча үтәп, фашистларны күпләп юк итеп, кире кайту ягына борылды. Шул мизгелдә иптәш Федоров самолетына снаряд килеп тиде һәм звено командирының бер аягы авыр яраланды. Шуңа да карамастан, ул самолетны зур осталык белән нейтраль полосага утырта алды. Һәм, яраларыннан кан аккан хәлдә, үз экипажы членнары белән бер сәгать дәвамында аларны эзәрлекләп килүче фашистларга каршы көрәште. Патроннар беткәч, үзебезнең якка таба шуыша башладылар. Шул чакта иптәш Федоров, танкка каршы куелган минага эләгеп, икенче аягын да өздерде. Безнең сугышчылар аны авыр хәлдә госпитальгә озаттылар. Анда иптәш Федоровның ике аягын да бот төбеннән кистеләр...*

*Иптәш Федоров – күп кенә сугышларда, шул исәптән 1944 елның январь-февраль айларында үткәрелгән Корсунь-Шевченко операциясендә дә актив катнашкан батыр очучы...*

*Дошманга каршы көрәшләрдә күрсәткән каһарманлыклары һәм яу кырында алган авыр яралары, түккән кайнар каны өчен ул хөкүмәтебезнең олы бүләгенә – Сугышчан Кызыл Байрак орденына тулысынча лаек...»*

Бүләкләү кәгазенә гаскәрләр командующие – армия генералы, соңыннан Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган Иван Владимирович Тюленев һәм Хәрби Совет әгъзасы генерал-лейтенант Мжаванадзе иптәшләр кул куйган (33 нче фонд, 744808 нче тасвирлама, 137 нче эш, 157 бит).

Сергей Кузьмич белән чын күңелдән горурландым мин Бүләкләү кәгазендә язылган шушы юлларны укыганда. Горурланырлык та шул! Әнә бит ул, биргән антына тугрылыклы булу өчен, госпитальдә чакта, Маресьев кебек, айлар буе күнегүләр ясап, протез аяклар белән йөрергә өйрәнә һәм, беренче группа инвалид булуына карамастан, дәваланып чыгуга ук, үзенә яраклы эш бирүләрен сорап, тиешле оешмаларга бара. Моны батырлык димичә, ни дисең?! Фронтовик очучының теләген канәгатьләндерәләр. Сугыштан соңгы елларда Сергей Кузьмич Кукмарада нефтебаза директоры, район көнкүреш комбинаты начальнигы, базар мөдире, киез

итек фабрикасы мастеры, ДОСААФның район комитеты инструкторы, кунакханә администраторы булып эшли. Аннары ул Хөсәен Ямашев исемендәге Ленин орденлы Татарстан мех производство берләшмәсенең (хәзер – «Мелита» акционерлык җәмгыяте) Кукмарадагы 9 нчы фабрика эшчеләре яши торган тулай торакта комендант хезмәтен башкарды. Аның биредә эшли башлавы белән биш катлы бу бинаның эче дә, тышы да танымаслык булып үзгәрде, яшеллеккә, гөлләргә күмелде. Тәрбия эше дә тамырдан яхшырды. Чисталык-тәртип мәсьәләләренә аеруча зур игътибар бирде Сергей Кузьмич. Бистәнең Тимер юл урамындагы мехчылар яши торган 4 нче номерлы йорт та үзенең чисталыгы, гөлләргә һәм агачларга бай булуы белән башкалардан нык аерылып торды. Чөнки биредәге йорт комитетына да тынгы белмәс ветеран С.К.Федоров җитәкчелек итте. Йортта яшәүчеләр белән ул территорияне чистарту-яшелләндерү буенча еш кына өмәләр үткәрә, тирә-юньгә утырту өчен декоратив агачларны да, җиләк-җимеш куакларын да үзенең җиңел машинасы белән алып кайта иде. Әнә шуңа күрә дә бу йортка, Кукмара поселок советы башкарма комитеты карары белән, «Иң үрнәк йорт» дигән исем бирелде, йорт комитеты рәисе Сергей Кузьмичның рәсеме исә поссоветның Почет тактасына куелды. Мактап район газетасына да каткат яздылар үзен...

Кайнар йөрәкле, якты күңелле патриот-ветеран автомәктәпнең штаттан тыш инструкторы (ул инвалидларны машина йөртергә өйрәтте), ОБХССның штаттан тыш инспекторы буларак та зур эш алып барды. Бер үк вакытта Сергей Кузьмич, Кукмара район хәрби комиссариаты тарафыннан еш үткәрелә торган «Яшь сугышчы клубы» занятиеләрендә дә актив катнашып, яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләү буенча үзеннән мактауга лаек зур өлеш кертте...

Маресьевчы якташыбызның биографиясендәге тагын бер характерлы штрих турында әйтеп үтмичә булмый. 1951 елда Сергей Кузьмич Кукмарада Казан аэроклубының филиалын ачып җибәрә һәм аның алыштыргысыз җитәкчесе була. Занятиеләр район үзәгендәге мәдәният сарае янындагы киң мәйданда үткәрелә. Аларга «УТ-2» дигән чын самолет бирәләр. Курсантлар, шул самолетка утырып, поселокның Степан Разин урамы ягындагы бушлыкта парашюттан сикерү күнегүләре ясыйлар. Аэроклуб үзенең өч ел эшләве дәве-

рендә авиация өчен дистәләрчә кадрлар – очучылар, мотористлар, парашютчылар хәзерләп чыгара. Сергей Кузьмич шәкертләренең шактые, соңыннан хәрби училищеларга юл тотып, гомерләрен авиациягә багышлыйлар. Элекке курсантлар арасында хәзер өлкән офицерлар да байтак. Алар Сергей Кузьмич кебек мөхтәрәм ветераннарның лаеклы алмашы, көчле канатлары булып, илебезнең һава чикләрен ышанычлы саклыйлар. Остазларын да онытмыйлар – ялкынлы хатлар язып, аның рухын күтәреп, тормышын нурлап торалар.

Хатлар дигәннән, үзе дә фронтташ дуслары белән кызыксынып, хәбәрләшеп яши Сергей Кузьмич. Якын дусты – украин Владимир Антонович Ярош гаиләсе белән аеруча актив языша. Лачын йөрәкле бу очучы, туган Украинасын явыз дошман тырнагыннан коткарганда, үзен-үзе аямыйча көрәшеп, исемен мәңгелек данга күмә. Аның кабере Днепр ярында, бөек украин шагыйре Тарас Григорьевич Шевченко кабере белән янәшәдә генә...

Дустына биргән антына тугрылыклы булып, Сергей Кузьмич сугыштан соң, госпитальдән чыгуга ук, Ярош гаиләсе белән элемтәгә керә. Озак еллар буена хатлар алышу, берберләренә кунакка барышу эзсез калмый. Аларның гаиләләре тәмам туганлашып, кан-кардәшләр булып китәләр – кызлары Валентина Владимир Антоновичның улы Бориска кияүгә чыга. Хәзер инде Алла, Вадим исемле ике балалары матур гына үсеп килә!..

Сүз уңаенда шунысын да әйтик: Федоровлар гаиләсе – тулысынча интернациональ гаилә. Сергей Кузьмичның искиткеч сабыр, мөлаем хатыны Антонина Васильевна, килене Татьяна – рус милләтеннән, кияүләренең берсе – украин, икенчесе – татар, гаилә башлыгы үзе исә чуаш халкы вәкиле. Шунысы ихластан сөендерә: бик күңелле итеп, гөрләшеп-чөкердәшеп, үзара аңлашып яшиләр алар...

Маресьевлар токымыннан булган әлеге батыр йөрәкле шәхеснең, вакыт-вакыт физик яктан нинди генә көчле авыртулар кичерсә дә (сугыш яралары үзләрен нык сиздерә!), һич тә зарланмавы, тормышка чиксез мәхәббәте, аны ямьләпматурлап, җәмгыятебез өчен кирәкле кеше булып яшәргә омтылуы, дәһшәтле сугыш елларында яу кырында ятып калган фронтовик дусларының каберләре алдында биргән антына һәрчак тугрылыклы булуы һәр очрашуда күңелдә хаклы рәвештә тирән соклану хисләре уята. Тормыш кадерен, яшәү

мәгънәсен әнә шундый көчле рухлы кешеләр янәшәсендә аеруча ачык тоясың. Алар яшьләребезнең барыр юлларында, нинди генә кыенлыклар туганда да бирешмәскә өндәп, якты маяк булып балкып торалар. Шуңа күрә Маресьев, Федоров кебек зур хәрефле Кешеләрне бүгенге көн яшьләре арасында да очратырга мөмкин. «Комсомольская правда» газетасының кушымтасы булган «Собеседник», мәсәлән, үзенең чираттагы бер санында безне тагын бер маресьевчы – Рязань егете Валерий Радчиков белән таныштырды.

Әлеге десантчы-офицер хәрби хәрәкәтләр барышында, дошман минасына эләгеп, бик каты яралана. Госпитальләрдә каткат операцияләр ясап, аның ике аягын да кисәләр. Гаять көчле ихтыярлы бу өлкән лейтенант үз гомерендә күпне күргән, заманында А.П.Маресьевны дәвалаган табибә Анна Васильевна Бобылеваны да гаҗәпкә калдыра. Чөнки Валерий протез аяклар белән йөрергә ике атна эчендә өйрәнә! Күрсәткән зур батырлыгы өчен Кызыл Байрак орденына һәм срогыннан элек майор званиесенә лаек булган тәвәккәл очучы В.Радчиков, үзен армия сафларында калдыруны сорап, югарыдагы хәрби җитәкчеләргә рапорт юллый. Офицер Радчиковка бик сирәк очракта гына була торган ташлама ясала: бүгенге көндә ул яңадан үз частенда, хезмәттәш дуслары арасында!

Азмыни мондый мисаллар?! Батырлык эстафетасы әнә шулай, буыннардан буыннарга күчеп, рухландыргыч матур җырдай дәвам итә!..

## БЕР ОЯ БӨРКЕТЛӘРЕ

*(Бертуган Габдрахмановлар)*

...Юлдашым – Бөек Ватан сугышы инвалиды һәм хезмәт ветераны Габдерәхим ага Габдрахманов белән Менделеев шәһәрендәге атаклы Революция тавының иң югары түбәсенә күтәрелдек. Бирედән тирә-юнь – Рәсәйдә иң борынгылардан саналган химия заводы корпуслары һәм матурланып үсеп килүче яңа шәһәр уч төбендәгедәй бик ачык күренеп тора. Янәшәдә генә, талчыбыклы ярларына тулышып, Тойма елгасы ага. Ул инде, кышкы йокыдан уянып, үзенең боз толыбын салырга өлгергән. Табигать күзгә күренеп яшәрә, җанлана. Язның шифалы җылы сулышын тоеп, Революция тавында яшел чирәм баш калкыткан, инде тау битләрендә сар-

гылт ут төсендәге беренче чәчәкләр дә күренгәли. Габдерәхим абый әйтеп куйды:

– ... Революция тавы дип тикмәгә генә йөртелми бу тау. Биредә, элекке Тын тауда, Бондюг күгендә кара болытлар куера башлагач, бик күпләр, кулларына корал алып, контрреволюционерларга, акгвардиячеләргә каршы батырларча көрәшкәннәр. Химзавод эшчесе Шәрифулла бабайның да берьюлы биш улы – Кәлимулла (кызыл партизаннар отряды командирларының берсе), Габдрахман (монысы әтиебез була инде), Миннәхмәт, Мөхәммәтгариф, Мөхәммәтшакир Советлар власте өчен үз-үзләрен аямыйча сугышканнар монда. Алтынчы улларына – Хәбибрахман абыйга исә – Шәрифулла бабайны акгвардиячеләрдән яшереп саклау бурычы йөкләнгән була. Канга сусаган дошман аны, «биш улына, хәер-фатиха биреп, кызыллар сафына бастырган ата большевикны», дөнья бетереп эзләгән. Әмма тиз генә табарлык җирдә булмаган ул. Хәбибрахман абый Шәрифулла бабайны, җитәрлек күләмдә азык һәм су биреп, үзе генә белгән урындагы тау куышына яшерә. Куыш авызын исә ташлар белән томалый. Әнә шулай исән кала безнең нәселнең олы горурлыгы, мактанычы Шәрифулла бабай!.. Башка туганнарыбыз да гражданнар сугышыннан исән-сау кайталар. Бөек Ватан сугышында да актив катнашалар алар! Әмма әтиебез Габдрахманга гына бу бәхетле көннәрне күрергә насыйп булмады – гражданнар сугышыннан авыр яраланып, контузия алып һәм салкын тидереп кайтканлыктан, дөньядан бик иртә китте... Әмма безнең химзаводта аны бик яхшы беләләр – намуслы тырыш хезмәте белән бик күпләрнең олы ихтирамын казанган иде әтиебез. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда эшләде бит ул!..

Габдерәхим абый бер мәлгә тынып калды. Аннары уйчан карашын Революция тавының иң калку җирендәге контрреволюционерларга һәм акгвардиячеләргә каршы аяусыз көрәштә батырларча һәлак булган каһарман якташларыбыз истәлегенә куелган мәһабәт һәйкәлгә һәм җирдәге сары чәчәкләргә төбәп сүзен дәвам итте:

– ...Кемгә ничектер, әмма миңа бу чәчәкләр батырларның кайнар каны тамган җирдә Мәңгелек ут булып кабынганнардыр кебек тоела. «Без монда, безне онытмадыгызмы?» дигәндәй, шул каһарманнар, һәр елны иртә язда чәчәкләр булып калкып, безгә эндәшәләр кебек...

Әтиебез Габдрахман да шушы туганнар каберлегендә ятадыр кебек тоела тагын миңа. Нигә дисәң, аның кайнар каны да түгелгән бит шушы тау битләренә. Тозлы маңгай тире дә күп тамган. Заманында без ишле гаиләбез белән шушы тауда – Революция тавында яшәдек... Ә-ә-нә безнең барак урыны. Асты – таштан, өсте агачтан иде аның... Комсомол сафларына да шушында яшәгән чакта бастык. И-и-и, ул чактагы очынулар, шатланулар! Башта комсомолга Котдус абый керде, аннары Миңнемөхәммәт абый, соңыннан – мин... Комсомол исеме белән без чиксез горурланып,ниләр генә эшләмәдек ул елларда үзебезнең төбәктә. Химзаводта ударникларча эшләү белән бергә, наданнарны укырга-язарга өйрәтергә, өмәләр оештырырга, клубта халыкка концерт-спектакльләр күрсәтергә, спорт ярышлары үткәрергә дә өлгерә идек!..

Комсомол сафларында тәрбияләнгән ир туганнары турында аеруча горурланып сөйли Габдерәхим абый. Горурланырлык та шул: аларның һәр икесе дә – Котдус та, Миңнемөхәммәт тә – үзләрен тыныч тормышта да, яу кырында да чын кешеләр итеп танытканнар.

Котдус абыйсы, әтиләре Габдрахман абый үлгәннән соң, гаиләдәге алты баланың иң өлкәне буларак, әнисе Фәрдәнә һәм туганнары өчен йортта төп таяныч булып кала. Гаҗәеп тырыш, һәр эшкә сәләтле Котдус 14 яшеннән инде химия заводында эшли башлый. Бераздан аны, иң алдынгы яшь эшчеләрнең берсе буларак, комсомол сафларына кабул итәләр һәм ячейка секретаре итеп сайлап куялар. 1930 елда булдыклы комсомолецны Кызыл Армия сафларына алалар. Аннан ул 1932 ел азагында кече политрук дәрәҗәсендә әйләнеп кайта. Тагын җиң сызганып эшкә тотына тынгысыз егет. Бондюгта ОСОАВИАХИМның башлангыч оешмасына нигез салып, 4 ел дәвамында аның рәисе вазифасын башкара, комсомол-яшьләрне чын ватанпәрвәрләр итеп тәрбияли. Кызыклы бер мисал: Бондюг эшчеләр поселогыннан чыккан 6 Советлар Союзы Героеның һәркайсы заманында аның шәкертләре булганнар бит! Шушы факт үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

1932 елда Котдус Габдрахмановны ВКП (б) сафларына кабул итәләр. Яшь коммунистка бераздан тагын да җаваплырак вазифалар йөклиләр. 1936–1939 елларда ул Эчке эшләр халык комиссариатының (НКВДның) Алабуга, Биектау район бүлекләрендә эшли. Алабугада Анна исемле кыз бе-

лән танышып, гаилә корып җибәрә. Күпләрне сокландырып, бик тату-матур яшиләр алар. Ак финнарга каршы сугыш башлангач, Котдус үзе теләп фронтка китә. Мотоукчы полкның аерым чаңгычылар батальонында взвод командиры вазифасын башкара ул. Һәм коммунист-лейтенант Габдрахманов аннан, СССР – Финляндия арасында солых килешүе төзелүгә үз өлешен кертеп, әмма контузия алып һәм яраланып, култык таяклары белән кайтып төшә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Котдус Габдрахман улы яңадан, үз теләге белән фронтка җибәрүләрен сорап, тиешле оешмаларга гариза яза.

– ... Сезнең бит әле аягыгыздагы ярагыз да төзәлеп җитмәгән, бераз сабыр итегез! – диюләренә каршы ул кистереп:

– Туган илебезне дошман дагалы итекләре белән аяусыз таптаганда, ничек түзеп, тыныч кына өйдә ятмак кирәк?! – ди.– Минем кебекләрнең урыны хәзер алгы сызыкта – Ватан язмышы хәл ителгән урында!..

Ничек итсә итә, әмма барыбер үз дигәненә ирешә Котдус. Яу кырында элеккечә дошманнарга каршы үз-үзен аямыйча көрәшә ул. Хөкүмәтебез бүләкләренә лаек була. Тагын авыр яралана. Госпитальләрдә шактый ятып, туган ягында бераз сихәтләнгәч, ярсу күңеле тагын фронтка – алгы сызыкка дәшә... Ләкин 1944 елның февралендә Революция тавындагы төп йортка гвардия өлкән лейтенанты К.Г.Габдрахмановның Кировоград өлкәсенең Петрово районындагы Лелековка авылы өчен барган сугышта батырларча һәлак булуы турында кайгылы хат килә.

Бик авыр кичерәләр кече Габдрахмановлар йөрәк өшеткеч бу кара хәбәрне. Өстәвенә, әле яңарак кына авырып китеп, әниләре Фәрдәнә дә үлгән була. Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан гына Белоруссиядә хезмәт иткән 1918 елгы икенче абыйлары Миңнемөхәммәттән дә инде күптәннән хатлар килми. Үзенең тормыш юлын Бондюг химия заводында эшләүдән башлаган, Днепродзержинск шәһәрендәге индустрия институтында укыган Миңнемөхәммәт, Кызыл Армия сафларына чираттагы хәрби хезмәткә алынып, политруклар әзерли торган курсларны тәмамлый, үзен «Ворошиловча төз атучы» итеп таныта. Баштарак аны, физик кимчелеген табып (бер аягы чак кына кыскарак була), армиягә алмаска уйлаганнар. Әмма комсомолец егет үз дигәнен иткәнче хәрби комиссариат юлын таптаудан, бер-бер артлы

гаризалар язудан туктамый. Тиздән ВКП(б) сафларына әгъза итеп тә кабул итәләр үзен. Миңнемөхәмәттән соңгы хат 1941 елның июнь азагында килә. Вакытына караганда, 21 июньдә язган ул түбәндәге сүзләрне:

*«...Хезмәт итәремә тагын 6 ай калып бара, хәзер сезнең янга кайтырга хәзерләнәм. Әнигә бик матур шәльяулык, Котдус абыйга яхшы күн итек, киленебез Нюра апага, яраткан кыз туганнарым Минзифа, Гөлзифа апаларга һәм Миннисa сеңелемә бер дигән күлмәкләр алып куйдым. Габдерәхим энем белән үземә пардан костюм да алдым. Әгәр дөньялар тыныч булса, шәт, тиздән күрешербез, көтегез!»*

Әмма күрешергә насыйп булмаган икән...

– Ул чакта мин үзем дә фронтта идем,– дип искә ала шул дәһшәтле елларны I һәм II дәрәҗәле Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнгән батыр разведчик Габдерәхим абый Габдрахманов.– 1944 елның 21 гыйнварында госпитальдә уң аягымны кистеләр. Аңарчы уң кулым белән уң яңак сөягем яраланган иде... Озак вакытлар хат-хәбәрем булмый торгач, мине дә төп йорттагылар инде үлгәнгә санаганнар. Ә мин менә хәзер дә исән әле, сугышта һәлак булган туганнарым өчен дә яшим... Еш кына мине, Миңнемөхәммәт абыйларым ничек һәлак булганнар, кайда күмелгәннәр икән, дигән сораулар бик тә борчый, тынгысызлый иде. Инде менә сезнең булышлык белән боларны да ачыклау бәхетенә ирештек...

Биредә, бераз чигенеш ясап, «булышлык» дигән сүзгә аңлатма биреп китик әле. Билгеле булганча, безнең «Хәтер яктысы» оешмасы билгесез батырларны эзләү-барлау буенча эзлекле-нәтиҗәле эш алып бара. Соңгы ике дистә ел дәвамында Саклану министрлыгының Подольск шәһәрендәге Үзәк архивында эшләгәндә республикабызның күп кенә билгесез каһарманнары табылды. Алар арасында 58 нче гвардияче укчы дивизиягә караган 175 нче гвардияче укчы полкның рота командиры – 1908 елда туган өлкән лейтенант Котдус Габдрахман улы Габдрахманов та бар иде. Ул хезмәт иткән укчы полкның 1942–1945 еллардагы сугышчан хәрәкәтләре турында сөйләүче журналда гаярь якташыбызның күрсәткән фидакарьлеге турында түбәндәге юллар язылган:

*«...8 февраль, 1944 ел.*

*Рота командиры, гвардия өлкән лейтенанты К.Г.Габдрахманов Туган ил хакына үзенең газиз гомерен корбан итте. Ул, Кызыл Армия офицеры, аяусыз ут яудыручы дошман дзо-*

*ты амбразурасына ташланып, аны күкрәге белән каплады. Фашист пулеметы, коммунист Габдрахманов канына тончыгып һәм ул ыргыткан гранаталардан тәмам эштән чыгып, бөтенләй тынып калды...*

*Сугышчан дуслары яраткан командирларының вакытсыз үлеме өчен дошманнан аяусыз үч алдылар һәм, җиңү арты җиңүләр яулап, алга таба юлларын дәвам иттерделәр...»* (188431 нче тасвирлама, 2 нче эш, 26 нчы бит.)

Безнең командованиенең үтә мөһим хәрби заданиесен башкарганда әнә шундый гайрәтлелек үрнәге күрсәткән якташыбыз турында «Татарстан яшьләре» газетасында язма да бастырган идем. Шуннан соң ике-өч көн дә үтмәде, безнең янга – Казанга – Менделеев шәһәреннән чандыр-җыйнак гәүдәле, сыңар аяклы, култык таяклы һәм күзлекле бер агай килеп житте.

– ...Сез телгә алган Котдус Габдрахмановның бертуган энесе Габдерәхим абыең булам мин,– диде ул, алдыбызга калын гына фотоальбом куеп.– Менә монда безнең гаиләнең, туганнарыбызның, якыннарыбызның байтак рәсемнәре бар... Сезнең язманы кат-кат укып, сөенештек тә, елаштык та. Күзгә йокы керми хәзер, ашау-эчү дә онытылды. Әле менә Әлмәттәге кыз туганым Минниса яныннан урап килешем, аны да сөендерим, дидем. Барлык туганнарымның телендә хәзер бер сүз: Котдус, Котдус, Котдус... Гаҗәпләнерлек тә шул: аның ничек һәлак булганлыгын ничәмә-ничә дистә еллар үткәч кенә белдек бит!.. Инде Миңнемөхәммәт абыйның да язмышын ачыклыйсы иде – сугыш башланганда ул Брест крепостенда хезмәт иткән...

«Брест крепосте» дигән сүзне ишетүгә, мин шундук «Татарстан яшьләре» газетасы хәбәрчесе – Брест крепосте каһарманнарын эзләү-барлау белән байтактан шөгыльләнүче журналист-эзтабар Атлас Гафиятов белән элемтәгә кердем.

– ...Крепостьны саклаганда батырларча һәлак булучылар арасында, чыннан да, сез әйткән Габдрахманов фамилияле каһарман бар,– диде ул, Бресттан үзе алып кайткан исемлекне тикшереп.– Исеме дә туры килә. Аның гәүдәсе калдыкларын (җәсәден) 1968 елда тапканнар һәм шундагы мемориаль комплекстагы мәрмәр плитәләрнең берсенә – «Неизвестный» дигән сүзләр урынына – исем-фамилиясен алтын хәрефләр белән язганнар. Билгесез батырларның исемлеге әнә шулай елдан-ел тулылана бара анда. Моңарчы без Габдрахмановның кайсы районнан икәнен тәгаен белми идек

әле – медальонындагы язуларда төгәл адресы сакланмаган, әмма «ТатАССР» дигән сүзләр ачык беленеп тора. Димәк, әлеге каһарман Бондюгтан – Менделеевтан! Димәк, бу районның тагын бер, хәер, ике батыры артты!

Әнә шулай итеп, газета материалына бәйле рәвештә, без тагын Бөек Ватан сугышының билгесез ике каһарманын таптык, бертуган фронтовик Габдрахмановларның исән калган өченче туганнары белән якыннан таныштык.

Ә ул өченче туган – Габдерәхим абый – гаҗәеп кызыклы, шигъри күңелле, яшәүнең һәр мизгеленнән ямь-тәм таба белүче, тормышка бөтен барлыгы белән гашыйк кеше булып чыкты. Яу кырыннан аяксыз килеш кайткач та, ул төшенкелеккә бирелмәгән. Сугышның бөтен рәхимсезлекләренә үч итеп, инвалид булуына да карамастан, заманында химзаводта да, ДОСААФ оешмасында да күңел биреп эшләгән. Үзе кебек гамьле, ярдәмчел, булдыклы хәләл җефете Бибиямал апа белән бергә матур гына гомер кичереп, ике кыз, бер егет тәрбияләп үстергәннәр.

Габдерәхим аганың тагын бер кызыклы ягы: һәр елны Менделеев районында үткән сабантуйларда көрәшеп (!), үзе кебек ветераннар арасында еш кына призлы урыннарны яулап килә икән... Батыр булып та калганы бар, диделәр. Димәк, икеләтә-өчләтә батыр ул!

* * *

...Габдерәхим ага белән, Революция тавы башыннан төшеп, Менделеев шәһәре үзәгендәге изге урынга – каһарман якташларыбызның данлы исем-фамилияләре, кылган батырлыклары мәңгеләштерелгән мемориаль комплекска килдек. Үлемсез батырларның ярсу-тынгысыз йөрәге шикелле березлексез дөрләп-талпынып торучы Мәңгелек ут янында күренекле шагыйрь – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Харрас Әюповның тирән мәгънәле шигъри юллары хәтеребездә яңарды:

«Мәрмәр ташка гөлләр сарылганнар,
Кабер өсләрендә ак тынлык,
Туфрак асларыннан сирпеләдер
Ак җаннардан төшкән яктылык...»

Әйе, бертуган Габдрахмановларның да шанлы исемнәре туып үскән якларына әйләнеп кайтты инде. Хәзер аларның кылган батырлыкларын мәңгеләштерү турында кайгыр-

тасы бар. Заманында алар – символик мәгънәле Революция тавы башыннан күтәрелгән яшь бөркетләр – Котдус, Миңнемөхәммәт һәм Габдерәхим Габдрахмановлар үзләрен Туган илебезнең чын патриотлары итеп танытканнар. Якын киләчәктә – Бөек Җиңүнең 60 еллык юбилее алдыннан – аларның исемнәре мемориаль комплекстагы исемлеккә дә алтын хәрефләр белән язылыр, шәһәрнең берәр яңа урамына «Бертуган Габдрахмановлар» дигән мәртәбәле исем бирелер, аларга һәйкәлләр дә куелыр әле, шәт, иншалла!..

## БУШ НИГЕЗЛӘР НИ СӨЙЛИ?..

Еш кына бездән – хәрби-патриотик темага язучылардан: «Ни өчен сез сугышта үлгән кешеләр турында күбрәк язасыз!» – дип сорыйлар. Бу сорауга күренекле әдип – батырларыбызның якты исемнәрен, кылган каһарманлыкларын мәңгеләштерүдә биниһая зур эшләр башкаручы Шамил ага Рәкыйповның «Аяз күктә карлыгачлар» дигән әдәби-документаль китабындагы (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982) гыйбрәтле сүзләр белән җавап бирәсем килә.

«...*Үлгәннәр истәлеге тереләр өчен кирәк,*– ди китап геройларының берсе – Алтын Йолдыз кавалеры, республикабызның Балык Бистәсе районында туган Александр Максимович Меркушев.– *Тереләрнең җаны тыныч түгел. Дөнья тыныч түгел. Үлгәннәр турында даими сөйләргә кирәк. Вакытсыз үлгәннәр турында... Алар онытылмаска тиеш. Алар хакы изге...*» (220 бит.)

Герой-фронтовикның менә шушы сүзләре тирәнтен уйланырга мәҗбүр итә. Әлеге сүзләр сугыш китергән дәһшәтне, явызлык-рәхимсезлекләрне үз җилкәләрендә нык татыган һәм фашизм дигән кара көчне җиңеп чыккан зур хәрефле Солдатларның, Ватан-Ана сакчыларының алмашка килүче яшь буынга үтенеч-теләге дә... Изге көрәштән беркем дә читтә калырга тиеш түгел! Шуңа күрә бүгенге язмамда да мин Туган ил иминлеге өчен утка кереп, гомерләрен биргән каһарманнарның тагын берсе турында сөйләргә һәм күңелемдә туган кайбер уй-фикерләрем белән уртаклашырга телим.

...Мамадыш районының Урта Кирмән җирле үзидарәсенә караган Алан эшчеләр бистәсендәге буш нигезләрнең берсе янында тирән уйларга чумып басып торам. Мондый

буш нигезләрне һәр авылда күпләп очратырга мөмкин. Һәркайсының – үз тарихы, үз моңы... Менә бу нигезнең дә үткәне гыйбрәтле. Заманында биредә өч сугыш ветераны булган бабам Ибраһим белән әбием Хәбибҗамал тормыш кичерәләр иде. Куе урман эчендә, яшел чирәмле тау битендәге түгәрәк аланлыкка урнашкан әлеге «оҗмах оясы»на без – аларның нәкъ бер дистә оныклары – өч чакрым ераклыктагы Арташ авылыннан еш менеп йөри идек. Бабай белән әбигә кышлык утын-печән хәзерләүдә, бакча эшләрендә, су китерүдә, мал-туар карауда кулыбыздан, көчебездән килгәнчә теләп-яратып булыша идек. Өлкәннәрнең май кояшыдай балкыган рәхмәтле якты карашларын, кыстый-кыстый тәмләп чәй эчертүләрен һич онытасыбыз юк...

Бабам белән әбием әлеге төбәкнең бик хөрмәтле кешеләре иде. Гомерләре буе (бабай 90 яшькә, әби 80 яшькә кадәр яшәде), күпләрне сокландырып, тату-матур тордылар. Тик бәхетләре тулы-түгәрәк булсын өчен бер нәрсә җитми иде аларга. Ул да булса – бердәнбер уллары Миннегаянның сугыштан әйләнеп кайтмавы. Һәр көнне бабам белән әбием, аның яу кырыннан җибәргән беренче һәм соңгы фоторәсеменә карап, уллары белән исән кешедәй сөйләшәләр, күңелләрендәге шатлыкларын да, борчуларын да уртаклашалар иде.

Аларның үз тормышлары белән икесе ике җирдә яшәүче кызлары – әниебез Гөлзәйнәп, апабыз Бибимәгъшия дә – очрашканда, бертуганнары Миннегаян абыйны чиксез сагынып-юксынып еш телгә алалар, аның турында сөйләгәндә, яулык читләре белән яшьле күзләрен еш сөртәләр иде. Шуңа күрәдерме, Ватан сакчысы булган Миннегаян абыебызның якты истәлеге бала чактан ук безнең күңелләргә тирәнтен уелып калды. Без аны әкиятләрдә сөйләнелә торган өч башлы аждаһаны җиңгән пәһлеван батыр итеп күзаллый идек, аның белән ихлас күңелдән горурлана идек.

Сөйләүләренә караганда, чыннан да, яшьтән үк батыр йөрәкле, тәвәккәл, үтә булдыклы кеше булган Миннегаян абый. Туган ягында – күмәк хуҗалыкта, беренче бишьеллыкларның удар төзелешләрендә тырышып эшләгән – мактаулы исеме телдән төшмәгән.

1941 елның мартыннан ул Кызыл Армия сафларында хезмәт итә башлый. Фашист илбасарларының безнең илгә каршы сугыш башлауларын да шунда ишетә.

Миннегаян абый танкка каршы ата торган артиллерия

полкы составында Мәскәүдән Көнчыгыш Пруссиягә кадәр сугышчан озын юл үтә, рядовойдан орудие командиры дәрәҗәсенә күтәрелә, хөкүмәтебез бүләкләренә лаек була. *«Дошманны эзәрлекләп, көне-төне алга барабыз, хәзер дошманны үз җирләрендә тукмыйбыз инде, тиздән туган нигезгә кайтыр вакытлар да җитә – көтегез!»* – дип яза Миннегаян абый 1945 елның гыйнварында бабайларга җибәргән хатында. Әмма аңа бәхетле Җиңү көннәрен күрергә насыйп булмаган икән – сугыш бетәргә берничә ай калганда гына хатлар килү өзелә. Озак та үтми, ул хезмәт иткән частьтан бабайлар йортына: *«Сезнең улыгыз – гвардия өлкән сержанты Гаян Ибраһимов социалистик Ватан өчен көрәштә, хәрби антына соңгы сулышынача тугры булып, батырларча һәлак булды»*,– дигән хәбәр килеп төшә...

Ышанмыйлар карт белән карчык улларының үлгәнлегенә. Җиңү таңы атып, кайтасы фронтовиклар кайтып беткәч тә, бабай белән әби Миннегаян абыйны көтүдән туктамадылар. Бәлкем, исәндер, кайда да булса тоткарланадыр дип, һаман могҗиза көтеп яшәделәр. Әнә бит кияүләре – Кызыл Йолдыз ордены кавалеры Әхмәтсафа солдатның да үлгәнлеге турында ике мәртәбә кара хәбәр килгән иде, өченчесендә тере килеш (!) үзе кайтып төште. Авыр яраланып, контузия алып, ике күзе дә сукыраю, ишетә дә, сөйләшә дә алмау сәбәпле, госпитальләрдә озак дәваланган икән... Шуңа хат-хәбәре булмый торган... Азмыни андый язмышлар?!

Еллар үтә торды. Әмма бабам белән әбием күңел күкләрендәге өмет кояшын һаман сүндермәделәр. Һәм көннәрнең берендә аларны тирәнтен дулкынландырган бер вакыйга булып алды.

Ул көн – 1966 елның кояшлы феврале бүгенгедәй хәтеремдә. Түбән Ушмы урта мәктәбендә (Мамадыш районы) уку атнасын тәмамлап, Аланга бабайларга булышка дип менгәч, алар йортына почтальон абзый чит почерклы хат китерде. Үзләре хәзерге язуны рәтләп таный белмәгәнлектән, бабам белән әбием ул хатны миннән укыттылар (соңыннан эзтабарлык эше белән тирәнтен кызыксынуыма сәбәпче булган әлеге хатны бүгенге көндә дә үземдә кадерләп саклыйм һәм биредә аны тулы килеш китерүне кирәк дип саныйм).

*«Исәнмесез, кадерле иптәш Ибраһимов Гаян! Исәнмесез, гвардияче батырның туганнары!* – диелгән иде хатта.– *Сезгә Мәскәү өлкәсенең Шахов районына кергән Никола-*

*Дуниловский сигезьеллык мәктәбенең кызыл эзтабарлары зур үтенеч белән мөрәҗәгать итәләр. Безнең VII класс укучылары элекке 16 нчы армиянең танкка каршы ата торган 1 нче гвардияче артиллерия полкы сугышчыларын эзләү белән шөгыльләнәләр. Бу уңайдан без СССР Оборона министрлыгы Үзәк архивы белән дә элемтәгә кердек. Архив мәгълүматларына караганда, 1 нче гвардияче артиллерия полкы составында кызылармеец Ибраһимов Гаян да булган. Ул үзе – 1921 елгы, 3 нче батареяның 1 нче взводында орудие расчеты номеры... Иптәш Ибраһимов 1942 елның февралендә безнең төбәкне дошманнан азат итүдә каһарманнарча сугышкан... Бәлкем, бу хатны гвардияче батыр үзе алып укыр һәм безгә шул утлы-давыллы елларга кагылышлы истәлекләрен язып җибәрер, хәзерге көндәге тормышы турында да мәгълүматлар бирер... Сездән түземсезлек белән җавап көтәбез!»*

Хаттагы әлеге юллар бабам белән әбиемне чиксез дулкынландырдылар. Бүтән вакытларда сабырларның да сабыры булган Ибраһим бабамның да сугышта кылыч белән телгәләнгән бит алмалары буйлап бөрчек-бөрчек яшьләр тәгәрәде.

– Кара син аларны – эзтабарларны әйтәм, рәхмәтләр төшсен инде үзләренә! – нинди игелекле, кирәкле эшкә тотынганнар! Сугыштан соң ничәмә-ничә еллар узса да, безнең улыбызны да онытмаганнар! – диде карт солдат, яу кырында каты гарипләнгән уң кулы белән әлеге хикмәтле хатны йомшак кына сыйпап. Аннары ул, фронтовик улының фоторәсеменә карап, аның белән сөйләшә башлады: – ...Кырык бишнең кышында үлгән хәбәрең килсә дә, күңел никтер ышанмады, балам! Әле менә хәзер дә бит үзеңә, исән дип белеп, хат язганнар... Их, белергә иде синең язмышыңны, кайларда гына югалдың икән?!

Бабамның шулай өзгәләнүе, әбиемнең әрнүле, сурәтләп биргесез моңлы карашы әле хәзер дә, бик ачык булып, күз алдымда тора, сүзләре исә, набат булып, колагымда кабаткабат чыңлый.

Гомерләре буе сугышны ләгънәтләп һәм улларын көтеп яшәделәр өлкәннәр. Әмма изге теләкләренә барыбер ирешә алмадылар – уллары белән кавышу шатлыгын татый алмыйча, бер-бер артлы җир куенына керделәр. Бабамның үләр алдыннан әйткән сүзләре шул булды:

– ...Тәки кайталмады улыбыз Вакыт табып, Миннегаян абыеңның язмышы белән дә кызыксын әле, олан!

Ил Агасының – яраткан бабам Ибраһим Ситдыйк улының гозерләп әйткән васыятен үтәдем. Каһарман якташлар эзеннән Саклану министрлыгының Үзәк архивында кат-кат булуым чорында гвардияче Миннегаян Ибраһимовның да сугышчан юлы белән җентекләп таныштым.

...16 нчы армиянең танкка каршы ата торган 289 нчы артиллерия полкы составында дошманга каршы көрәшеп, Мәскәү янындагы сугышларда зур батырлык үрнәкләре күрсәтә Миннегаян абый. Архив документларыннан күренгәнчә, 1941 елның 25 октябрендә алар полкы оборона тоткан участокка – Спасс-Рюховское һәм Ивлево авылларына таба дошманның 80нән артык танкы, дүрт дистәгә якын бомбардировщигы һәм ике батальон күләмендәге пехотасы һөҗүм итә. Көчләр тигез булмаса да, безнең артиллеристлар каушап-калтырап калмыйлар. Ике сәгатьтән артык дәвам иткән кискен көрәш вакытында дошманның 59 танкын, 5 самолетын һәм бер батальон пехотасын юк итәләр. Нәтиҗәдә фашистлар чигенергә мәҗбүр булалар. Шушы гаять авыр шартларда Миннегаян абый хезмәт иткән орудие расчеты да, төз атып, дошманның 6 танкын яндыра.

«...*Пушканы корып торучы иптәш Ибраһимов шушы җитди-кискен көрәштә үзен искиткеч батыр, тәвәккәл, җитез һәм иң кыен вакытта да каушап калмый торган салкын канлы, аек акыллы сугышчы итеп танытты,*– диелә 16 нчы армия командующие – генерал-лейтенант Рокоссовский, артиллерия генерал-майоры Казаков һәм Хәрби Совет әгъзасы Лобачев кул куйган Бүләкләү кәгазендә.– *Ватаныбызның курку белмәс улы Гаян Ибраһимов «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүгә тулысынча лаек*». (33 фонд, 682524 тасвирлама, 239 эш, 505 бит.)

Шулай итеп, абыебыз – кызылармеец Г.Ибраһимов – «немец илбасарларына каршы көрәш фронтында совет командованиесенең сугышчан заданиеләрен үрнәк төстә үтәгәне өчен» Көнбатыш фронт Хәрби Советының 1941 елның 5 ноябрендә игълан ителгән 0280 номерлы приказы нигезендә беренчеләрдән булып сугышчан бүләккә лаек була. Гаян абый хезмәт иткән 289 нчы артполк исә Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә һәм ул тиздән «танкка каршы ата торган 1 нче гвардияче полк» дип үзгәртеп йөртелә башлый. Мәскәүне саклаганда «гвардияче» дигән гаять мактаулы исемгә иң беренчеләрдән лаек булган әлеге дан-

лы полк артиллеристлары алда торган хәлиткеч сугышлар барышында да үзләрен арыслан йөрәкле батырлар итеп таныталар. Белорус Клецко, грузин Грдземишвили, дариец Гасаниев, рус Романов, украин Попович, казак Турсункулов, каракалпак Гурсунов һәм башкалар, иңгә-иң торып, дошман юлына мәңге бирешмәс алмаз кыядай торып басалар. Күрсәткән батырлыклары өчен аларның күкрәкләрендә хөкүмәтебезнең югары бүләкләре балкый. Татарстаннан килгән сугышчылар да республикабыз данын югары йөртәләр. Мәскәү янындагы сугышларда Арча районының Шушмабаш авылыннан килгән Гыйльметдин Шиһапов Ленин ордены, Актаныштан Мәгариф Галиәхмәтов, Әлмәттән Мансур Галәветдинов иптәшләр исә Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнәләр.

Гаян абый да «Мәскәү оборонасы өчен», икенче тапкыр «Батырлык өчен» медальләренә лаек була. Соңгысы аңа Пущай торак пунктын һәм Орша шәһәрен азат итү өчен барган сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен бирелә. Архив документларыннан күренгәнчә, Миннегаян абый үзенең расчеты белән әлеге торак пунктларга иң беренче булып бәреп керә һәм, төз атып, дошман пулеметчыларын, миномет батареясын һәм күпләгән солдатларын юк итә...

Мондый мисалларны аның сугышчан тормышыннан байтак китерергә мөмкин. Күкрәгендә Ватан-Анага карата тиңсез мәхәббәт, дошманга каршы чиксез нәфрәт хисләре кайнаган гвардия өлкән сержанты – орудие командиры Гаян Ибраһимов, фашист илбасарларының күпләгән җанлы көчләрен һәм техникасын юк итә-итә, Көнчыгыш Пруссиягә кадәр данлы сугышчан юл үтә. Һәм 1945 елның 26 гыйнварында ныгытылган шәһәр-крепость Кенигсбергны алу өчен барган сугышларда батырларча һәлак була. Нибары 23 яшендә...

* * *

–...Миңа нәкъ 20 яшь тулган көнне үлгән икән Миннегаян абыегыз,– диде күзләрен мөлдерәтеп әниебез Гөлзәйнәп, аңа бертуганы турында хәрби архивтан алып кайткан сугыш чоры документларының күчермәләрен күрсәткәч.– Өйләнгән булса, балалары – дәвамы калыр иде... Хәер, ятимнәрнең, тол хатыннарның да язмышлары бик үк җиңелдән түгел шул...

Һәм ул яңадан үзенең бертуганы Бибимәгъшия апа турында сөйләп китә. Апасының ире Газиз Кадыйров, 1941

елның көзендә фашистларга каршы көрәшкәндә, Молдавия җирендә һәлак булгач, аңа бердәнбер кызы Гарифәне берүзенә карап үстерергә туры килә (уллары Камил исә бик яшьләй вафат була). Ничек итсә итә, әмма чын кеше итеп үстерә кызын Бибимәгъшия апа. Гарифә башта Мамадыш районының Уразбахты авылында – «8 Март» колхозында сыер савучы булып эшли. Мактаулы исеме, фотосурәте район һәм республика газеталары битләрендә еш күренә аның. Аннары ул, кияүгә чыккач, тегүче һөнәрен үзләштереп, Пермь өлкәсенең Губаха шәһәрендә, соңгы елларда исә – лаеклы ялга киткәнче – Түбән Кама каласындагы «Яшьләр» ательесында бик күп кешеләргә игелекле хезмәт күрсәтә. Ире Габделфәрт тә, шофер буларак, нык билгеле, булдыклы шәхес... Өчесе дә бер түбә астында торгач, шатлыкларын да, кайгыларын да тигез бүлешеп яшиләр алар. Бибимәгъшия апа да, Гарифә дә үзләре өчен иң кадерле кешеләрдән саналган Кадыйр Газизов белән Миннегаян Ибраһимовны һәркөнне иртә-кич догаларыннан калдырмыйлар, аларның соңгы фотосурәтләренә, тирән юксыну-сагыну хисләре белән, кат-кат багалар...

Нәкъ шундый ук сүзләрне Хәбибҗамал әбиебезнең якын туганы Искәндәр солдатның сөекле хәләл җефете Зарифа апа Ибраһимовага карата да әйтергә була. Ул да иреннән бик яшьләй, ике баласы белән тол калган. Шөкер, уллары Фаяз белән Гаяз йөзгә кызыллык китермәделәр – тәртипле, тәүфыйклы, иманлы булып үстеләр. Һәр эшкә дә куллары ябышып тора аларның. Егет булгач, үзләренә тиң ярларны – Нурлыхода белән Сабира кебек сөйкемле, уңган, ачык йөзле авыл кызларын сайладылар. Киленнәр исә, итәк тутырып, берсеннән-берсе булдыклы, тырыш балалар үстерделәр. Эчке эшләр органнарында эшләгән Фаязы озак еллар дәвамында инде Соколка бистәсендә яши. Нократ белән Чулман кавышкан урында!.. Ә атказанган игенче буларак танылган Гаязы әти-әнисе корган төп нигезгә – серле-сихри Аккош тавы итәгендәге биниһая кадерле урынга ныклап урнашты. Шушы тау буеннан Зарифа апаның да бер дә китәсе килмәде. Ирен өзелеп сагынган мизгелләрдә, тау янәшәсендәге урман буена барып, күңелен җыр белән юата иде ул:

Ак күгәрчен, күк күгәрчен
Оча урман итәкләп.
Сукыр булсаң да кайт, җаным! –
Үзем йөртәм җитәкләп...

Юк шул, күпме генә көтсә дә, кайтмады Искәндәре. Башка бик күпләр кебек, сержант И.Ибраһимов та, дәһшәтле дошманга каршы тигезсез көрәштә, бүгенге якты көннәр хакына шәһит китте. Татарстанда чыккан «Хәтер Китабы»ның 16 нчы томында, 104 нче биттә мәңгелеккә урын алган аның исем-фамилиясе...

Шул ук томда әтиебез Әхмәтсафа Мостафинның, абыебыз Миннегаян Ибраһимовның да үлгән көннәре һәм күмелгән урыннары күрсәтелгән. Әйтик, әтиебез турында китапта: «...1943 елның15 октябрендә һәлак булды. Псков өлкәсенең Невельский районындагы Горушки авылы янында күмелде»,– диелә. (Безнең бәхеткә, әтиебез, мең үлемгә үч итеп, исән калган!) Миннегаян абыебызның мәңгелек сыену тапкан урыны, изге кабере исә хәзерге Калининград өлкәсенең Полесск (элекке Лабиау) шәһәре уртасында...

Фашист снаряды 1945 елның 26 гыйнварында гвардия өлкән сержанты Миннегаян Ибраһимов белән бер туп расчетында хезмәт иткән дүрт кешенең гомерен берьюлы өзә. Архив документларыннан күренгәнчә, яу кырында абыемның якын сугышчан дусларыннан – башкорт егете Гомәр Дүшәнбаев, рус халкы вәкилләре Петр Жевлев, Василий Янков, үз-үзләрен аямый көрәшеп, батырларча һәлак булалар.

Заманында шул хакта «Советский патриот» газетасында «Завещание Деда» дигән язмамны (1989 ел, 8 февраль саны) бастырган идем. Әлеге очерк ничектер мәрхүм Гомәр Дүшәнбаевның улы Рафикъның күзенә чалынган. Һәм ул, адресымны шул газета редакциясе аша тиз генә соратып алып, миңа бик тә дулкынландыргыч хат юллаган булган. (Әлеге язмамда аның әтисе турында да җылы итеп әйтеп үткән идем.) Ни кызганыч, ул хат, иске фатирыбыздан күчү сәбәпле, миңа бик соң килеп иреште. Рафикъ туганкай белән күрешергә-аралашырга өлгерми дә калдык – ул кинәт кенә үлеп китте...

Шулай да минем заманында Гомәр һәм Рафикъ Дүшәнбаевлар гомер кичергән төбәккә – Башкортстанның Зианчура районындагы Тазлар авылына бик тә барып чыгасым, анда яшәүчеләр белән якыннан аралашасым-дуслашасым килә. Зиратларына барып, игенче-музыкант әтисен гомере буе сагынып-өзелеп көткән Рафикъ туганкайның, аның якыннарының каберләре алдында башымны иеп, дога кыласым, Миннегаян абыебызга тормыш бүләк иткән үзебезнең Ма-

мадыш төбәгенең изге туфрагын шунда саласым килә. Әйдә, тагын да ныграк туганлашсын әле ике җөмһүрият туфрагы! (Моңарчы инде Башкортстан туфрагын – рейхстаг түбәсенә Җиңү Байрагын беренче булып менгезеп кадаган легендар милләттәшебез Гази Заһитов кабереннән (Мишкә районының Яңа Куыш авылы зиратыннан) үз кулларым белән алган биниһая кадерле туфракны фронтовик әтием Әхмәтсафа Мостафа улының каберенә 2000 елның октябрь аенда сипкән идем...)

Әлеге зарури теләгемне Башкортстанның халык шагыйре – Дүшәнбаевлар яшәгән төбәктә туып үскән мөхтәрәм милләттәшебез Марат ага Кәримов та ихлас күңелдән хуплады һәм, җай чыгу белән, үзләренә кунакка килергә чакырды...

* * *

...Яу кырыннан кайткач, Миннегаян абыем ныклап төпләнергә тиеш булган йорт нигезе янында уйланып утырам. Буш нигез, бомба төшкән чокырдай, күңелгә шом һәм моң салып каралып тора... Кулымда – бабам белән әбиемнең исән чакта төшкән фоторәсемнәре. Алар, җыйнак кына өйләренең капка төпләренә чыгып басканнар да, зур өмет белән олы юлга карап торалар. Бабамның сугышканда имгәнгән уң кулы, канаты каерылган бөркетнеке кебек, салынып төшкән. Карашы – җитди, иреннәре, нәрсәдер әйтергә теләгән сымак, бераз ачылган. Ак яулыклы әбием дә, сул кулын кашлары өстенә куеп, юлны күзли. Улларын көтәләр...

Әгәр Миннегаян абый исән булса, бу нигездә дә тормыш гөрләп торыр иде. Йорттан тирә-юньгә яктылык сибелер, җыр ургылыр иде. Тәрәзә алларында гөлләр кояшка үрмәләр иде. Сабый балаларның җиз кыңгыраудай чыңлап торган шатлыклы тавышлары бүгенге кебек эчпошыргыч тынлыктан качарга ярдәм итәр иде...

Юк шул, сугыш – аяусыз, сугыш – рәхим-шәфкатьсез! Күпме асыл ир-атларны үзенең комсыз тегерменәненә салып тарттырган, күпме тол-ятимнәрне арттырган ул! Күпме карт-карчыкларны газиз улларыннан, сөекле кызларыннан – соңгы терәк-таянычларыннан, өметләреннән аерган ул!

Буш нигезләр – авылларның үзәк өзгеч моңы, мәңге таралмас сагышы. Буш нигезләр – сугышка чиксез көчле нәфрәт билгесе!

Буш нигезләр – сугыш дигән афәтнең ниндилеген искәртүчеләр дә, кабат сугыш ялкынын булдырмас өчен көрәшне туктатмаска кирәклеген кисәтүчеләр дә!

Буш нигезләр – яу кырыннан кайтмый калганнарның тынычлык өчен изге көрәшкә чакырган үтә җитди карашы һәм тетрәндергеч авазы да ул!..

Буш нигезләр үзләренең Бөек Ватан сугышында һәлак булган хуҗалары турында кыю эзтабарларның, җирле үзидарә һәм хуҗалык җитәкчеләренең, мәктәп директорларының, мөгаллимнәрнең, мәдәният учакларында эшләүчеләрнең...– һәммәбезнең тирәнтен кызыксынуларын көтәләр, аларга багышлап «Хәтер» мемориаллары, «Сугышчан Дан» почмаклары булдырганны, күмәкләшеп Батырлык елъязмасы тудырганны өмет итәләр. *Әйе, беркем дә, бернәрсә дә онытылырга тиеш түгел!* Бу – безгә абыйларның, әти-бабайларның изге васыяте, үтенеч-теләге дә!.. Бөек Ватан сугышында җиңүебезнең 60 еллыгын матур итеп каршылау өчен һәркайсыбыз үзеннән лаеклы өлеш кертсә, сугышта гомерләре иртә өзелгәннәр каршында йөзләребез ак, вөҗданыбыз пакь булыр иде...

## БЕЗ ҖИҢӘРГӘ КИЛДЕК БУ ҖИРГӘ!

*(Өскебаш төбәге каһарманнары)*

«...Менә – сигнал!.. Батарея ата,
Кузгалабыз хәзер һөҗүмгә...
Без алырбыз таш каланы, тауны –
Без җиңәргә килдек бу Җиргә!..»

*Фронтовик шагыйрь Нух Идрисовның 1943 елның 10 февралендә ерак тылдагы хәләл җефетенә – мөгаллимә Нажия ханымга җибәргән шигъри хатыннан өзек*

«Батырлар мәктәбе», «Мәктәп-музей»... Җөмһүриятебезнең Кукмара районындагы каһарман-шагыйрь Нух Идрисов исемендәге Түбән Өскебаш урта мәктәбе турында сүз чыкканда, аны еш кына әнә шулай атап йөртәләр.

...1967 елның буранлы февралендә Аксыбы башлангыч мәктәбенә Мәскәүдән дулкынландыргыч хат килеп төшә. Аны Нух Идрисов командирларының берсе – ике Сугышчан Кызыл Байрак, Суворов һәм Кутузов орденнары белән бүләк-

ләнгән Петрозаводский исемендәге 313 нче укчы дивизиянең штаб начальнигы, гвардия полковнигы В.И.Крапивин язган була. Василий Иванович үзенең хатында 1070 нче укчы полкның взвод командиры лейтенант Н.И.Идрисовның Карелия җирендә, 1944 елның 27 июлендә 216,0 номерлы гаять мөһим биеклекне алганда, иң хәлиткеч мизгелдә, рәхимсез үлем уклары чәчүче дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән каплап, сугышчан иптәшләренә җиңүгә юл ачуы турында хәбәр итә. Һәм дивизиянең данлы үткән юлы, аның каһарманнары турында үзе яза торган китабында куллану өчен батыр офицер Нух Идрисовның фоторәсемен тиз арада табып җибәрүләрен сорый. Бер үк вакытта, күрсәткән искиткеч фидакарьлеге өчен, фронтовик дустына тиешле I дәрәҗәле Ватан сугышы орденының аның гаиләсенә яисә якын туганнарына тапшырылу-тапшырылмавы белән дә кызыксына хат иясе...

Матросовчы каһарман Нух Идрисов турындагы хәбәр яшен тизлеге белән бөтен авылга, тирә-юньгә таралып өлгерә. Полковник Крапивин язган хатны мәктәп укучылары, укытучылар да, колхозчылар да кат-кат укыйлар. Н.Идрисовның Аксыбы авылындагы туганнары һәм күрше Мамадыш районының Тулбай авылында яшәүче хатыны, кызы, оныклары сөенечләреннән нишләргә дә белмиләр. Ничәмә-ничә еллар дәвамында өзелеп-саргаеп көткәннән соң, ниһаять, аларның кадерле, үтә якын кешеләре турында белүче-сөйләүче табылды бит! Моңарчы әле алар Нухның нинди шартларда, нинди батырлык күрсәтеп һәлак булуын бөтенләй белмәгән дә булалар...

Шуннан соң ике арада хатлар алышу башлана. Батырның фоторәсемен дә табып җибәрәләр Мәскәүгә. В.И.Крапивин, Нух батыр гаиләсенең орден турында бөтенләй хәбәрдар булмавы турында укыгач, Саклану министрлыгы һәм хәрби комиссариатлар белән элемтәгә керә. Һәм, ниһаять, чирек гасырдан соң – 1969 елның 25 февралендә – шул кадерле, истәлекле Ватан сугышы ордены Нух Идрисовның хәләл җефетенә – ветеран укытучы Нәҗия Госам кызына һәм кызы Гүзәлгә тапшырыла. Өстәвенә В.И.Крапивин «Карелия» нәшриятында яңа гына дөнья күргән «313-ая Петрозаводская» дигән китабын да бүләк итеп җибәрә. Аның берничә бите Нух Идрисов һәм аның үлемсез батырлыгы турында сөйләүгә багышланган...

Менә шулай полковник Крапивин, үзе дә сизмәстән, Өс-

кебаш төбәге эзтабарларына Нух батыр турында эзләнүләр башлап җибәрү өчен ныклы этәргеч бирә. Эзләнү штабы, билгеле инде, Түбән Өскебаш урта мәктәбенә урнаша. Биредән Аксыбы, Тулбай авыллары да якын – Нух батырның туганнары, якыннары белән элемтәгә керү өчен уңайлы.

Эзләгән – табар, ташка кадак кагар, ди бит халык. Мәктәп эзтабарлары, иң башта Рәкыйп Мәрданов, Нурзидә Җәләлиева, Фоат Миннәхмәтов, Гандәлиф Бариева кебек өлкән укытучылар җитәкчелегендә, Нух Идрисовның үткән тормыш юлына кагылышлы мәгълүматлар, истәлекле документлар туплыйлар. Аннары бу изге-кирәкле эшкә Рифат Җәләлиев, Гомәр Мөбарәкшин, Резидә Бариева, Фирдәвия Исмәгыйлова кебек яшьрәк буын мөгаллимнәре дә алына...

Эзтабарлар, авылдан авылга, өйдән өйгә йөреп, Нухны яхшы белгән кешеләр, аның якыннары белән очрашып, сугышчан дуслары белән элемтәгә кереп, Карелия фронты турында тарихи китаплар, мемуарлар укып, батырның тормышы, сугышчан юлы турында гаять кызыклы мәгълүматлар, фоторәсемнәр, хатлар, күргәзмә әсбаплар туплыйлар.

...Булачак батыр 1918 елның 16 октябрендә Мамадыш өязенең Битләнгер (Аксыбы) авылында Идрис Ихсан улы һәм Шәмсенаһар Шиһабетдин кызы гаиләсендә туа. Гражданнар сугышында катнашып, аннан авыр яраланып кайткан әтисе, дәһшәтле 1921 елда, ишле гаиләләрен үлем тырнагыннан коткарып калу өчен, икмәк эзләп Донбасска барганда, юлда актык сохариларын бөтенләй таныш булмаган балаларга биреп, үзе ачлыктан шешенеп үлә. Үзе турында бөтенләй кайгыртa белмәгән – гел башкалар өчен тырышкан ул...

Әтисенең шул асыл сыйфатлары, күрәсең, Нухка да күчкән – кечкенәдән үк үтә ярдәмчел, кешелекле, тәвәккәл булып үскән малай тора-бара әнисенең төп ярдәмчесенә әверелә. 12 яшеннән инде Нух колхоз эшләрендә катнаша башлый. Өлгерлеген, тапкырлыгын, көрәшкә маһирлыгын, оештыру сәләтен күреп, җырга, шигырь чыгарырга осталыгын белеп, бераздан аны хат ташучы, аннары клуб мөдире итеп билгелиләр. Колхоз яшьләре оешмасы җитәкчесе, бригадир да була ул... 20 яшендә инде Нух колхоз рәисе итеп сайлана... Хәрби хезмәткә алынгач, Амур елгасы буендагы Комсомольск шәһәре төзелешендә дә җиң сызганып катнаша егет. Армиядән кайткач, аны тагын колхоз рәисе итеп

сайлап куялар. Күрәсең, Нух авылдашларының күңелләренә ошаган. Колхоз алда булгач, авызлар балда булган шул...

Туган туфракта гомергә төпләнеп калырга уйлап, Нух үз авылларында балалар укытучы Нәҗия исемле кыз белән гаилә корып җибәрә. Бераздан Гүзәл исемле кызлары да туа аларның. Әмма яшь гаиләгә рәхәтләнеп бергә яшәргә насыйп булмаган икән. Рәхимсез сугыш җилләре алар корган җылы ояны тузгыта.

Гәрчә броне булса да, Нух, үзе теләп, 1941 елның 7 августында яу кырына китеп бара. Дошманга каршы Карелия фронтында үзен-үзе аямыйча көрәшә ул. Хәер, сугышка кадәр үк инде Нух тиңсез кыюлыгы, батыр йөрәкле булуы белән халык теленә кергән була. Бервакыт, Тәкәнештән төнлә туган авылына кайтканда, басуда аңа бүреләр һөҗүм итә. Әмма егет каушап калмый – «башлык» бүрене үтереп, башкаларын качарга мәҗбүр итә. Язгы ташу вакытында бозлы суга егылып төшкән балаларны коткаручы, дөрләп яна торган йорт эченә кереп, өлкән яшьтәге әби-бабайны аяусыз үлем тырнагыннан тартып алучы да – шул ук гаярь егет!

Карелия җирендә ике аяклы «бүреләр» – фашистлар белән очрашканда да, көрәшче данын югары йөртә Нух Идрисов. Һәм, иң авыр чакта, күкрәге белән дошманның дәһшәтле ут өермәсен томалап, бик күп сугышчан дусларының гомерләрен саклап кала – җиңү яуларга ярдәм итә...

Җиңү дигәннән, шагыйрь офицер күңеле күптән көтелгән җиңүнең нәкъ менә яз аенда – шомыртлар чәчәк атканда булачагын алдан ук нык сизенгән. Сөекле Нәҗиясенә 1943 елның 22 февралендә – сугыш бетәргә 26 ай да 15 көн кала җибәргән шигъри хатында Нух Идрис улы менә ниләр яза:

«...Син көт, иркәм, син көт – мин кайтырмын,
Шомыртлар ак чәчәк атканда!..
Тәрәзәңне чиртеп уятырмын,
Җиңү белән өйгә кайтканда!..

Салкын чишмәләрне урарбыз да
Без йөрербез бергә болында.
Мин сөйләрмен сиңа яшь егетнең
Үлмәс батырлыгы турында.

Дошман тылларына разведкага
Барган чакта урман буеннан,
Мәхәббәтең миңа гайрәт бирде
Һәм саклады дошман угыннан.

Кайда гына, иркәм, йөрсәм дә мин,
Син булырсың һәрчак күңлемдә.
...Атакага бардым синең белән
Һәм ял иттем нарат төбендә...

Син көт, иркәм, син көт – мин кайтырмын,
Шомыртлар ак чәчәк атканда!..
Тәрәзәңне чиртеп уятырмын
Җиңү белән өйгә кайтканда!..»

Каһарман шагыйрьнең үз гаиләсенә, якыннарына җибәргән әнә шундый искиткеч җылы шигъри хатлары белән танышкач, мәктәп эзтабарлары ул һәлак булган урынга бару, аның каберен эзләп табу турында уйлый башлыйлар.

Саклану министрлыгының Үзәк архивы, 313 нче укчы дивизия ветераннарының Ижау шәһәрендәге советы, Карелиядәге Суоярви районы эзтабарлары белән элемтәгә кереп, ниһаять, батырның кайда күмелгән булуын ачыклыйлар. Каһарман якташыбыз каберен эзләп табуда аларга заманында Карелиядәге Вегарус урманчылыгында эшләгән ирле-хатынлы Игорь Владимирович һәм Татьяна Андреевна Равиннар, биредәге «Сугышчан дан» музее җитәкчесе Клавдия Петровна Гартвич кебек тынгысыз, шәфкатьле җаннар зур булышлык күрсәтә...

1982 елның июленнән башлап мәктәп эзтабарлары, батыр якташыбызның якыннары – бертуган сеңлесе Шәмсеямал апа, кызы Гүзәл, оныгы Илшат һәм бу юлларның авторы белән бергә, Карелиядә дүрт мәртәбә булдылар. Нух Идрисовның фронт юлларыннан, аның сугышчан дуслары – җөмһүриятебезнең Арча районында яшәүче Шакир ага Салихов, Днепродзержинскидан Михаил Прокофьевич Береговой, Вологдадан Алексей Николаевич Шохин һ.б. белән бик күп шәһәр-авыллар аша ахыргача бергә үттеләр эзтабарлар. Аның җәсәден кеше аяк басмый торган тыюлыктан алып, ак каенлы, чәчәкле-җиләкле, зәңгәр күлле аланлыкка күчереп күмү эшен оештыруда да алар башлап йөрде. Шунда – Советлар Союзы Герое исемен йөртүче якташыбыз Н.Ф.Кайманов исемендәге чик буе заставасына илтүче олы юл читында – Карелиядәге дуслары белән бергәләп, яңа кабере янында Нухка мәһабәт һәйкәл дә торгыздылар. Суоярви шәһәрендәге иң матур урамнарның берсенә Нух Идрисов исемен бирү, аңа багышлап шундагы мәктәптә музей бүлмәсен ачу, каһарман якташыбыз призына спорт ярышлары үткәрү

һ.б. шундый күркәм эшләрнең, башлангычларның үзәгендә һәрвакыттагыча Өскебаш эзтабарлары булды...

Н.И.Идрисовның туып үскән ягында да, аның якты истәлеген мәңгеләштерү юнәлешендә, эзтабарларның тынгысыз эшчәнлеге нәтиҗәсендә, файдалы күп кенә чаралар тормышка ашырылды... Бөек Җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Аксыбы авылында Нух батыр яшәгән нигездә мемориаль комплекс ачылды, урамга аның исеме бирелде. Колхоз яшьләре исә үз оешмаларына матросовчы якташыбыз исемен кушып, аның *«Без җиңәргә килдек бу Җиргә!»* дигән шигъри сүзләрен үзләренә төп шигарь итеп алдылар. 1986 елдан башлап, хуҗалыкта хезмәт алдынгыларын бүләкләү өчен, Нух батыр исемендәге премия һәм махсус диплом булдырылды. 1988 елның 16 октябрендә – тууына нәкъ 70 ел тулган көндә – Нух Идрисовка Түбән Өскебаш мәктәбенең ишегалдына танылган скульптор Әлфәрит Әбдерәшитов тарафыннан эшләнгән мәһабәт һәйкәл (бюст) куелды. Аны ачу тантанасына Карелиянең Суоярви шәһәреннән җыр укытучысы Галина Петровна Капитонова җитәкчелегендә Лена Жеменайте, Наташа Труш, Оля Бояркина кебек тынгысыз эзтабарлар – Нух Идрисов батырлыгын һәм иҗатын армыйталмый яшьтәшләре күңеленә җиткерүчеләр килгән иде. Соңыннан алар, Тулбай авылында да булып, Нух батырның хәләл җефете, кызы, оныклары белән дә очраштылар. 1989 елның 23 августында исә Түбән Өскебаш урта мәктәбенә каһарман-шагыйрь Нух Идрисов исеме бирелде...

Әлеге мәктәптә Нух батырга багышлап 1969 елдан эшли башлаган нәни генә музей тора-бара һәртөрле экспонатларга, тарихи әйберләргә гаять баеды, зурайды. Мәктәп мәһабәт яңа бинага күчкәч, музей үз эшчәнлеген тагын да яхшырта һәм киңәйтә төште. Эзтабарлар Нух батырдан соң тагын бер матросовчы – нәсел тамырлары белән шул ук Аксыбы авылына килеп тоташкан Әхмәтгали Мөхәммәдиев язмышы белән тирәнтен кызыксына башладылар... Тора-бара биредә республикада хәзергә бердәнбер булган, үзенә шундый 24 каһарман турында тулы мәгълүматлар туплаган «Татарстан матросовчылары-мөхәммәтҗановчылары музее»-на нигез салынды. Андагы документлар арасында легендар Александр Матросовның чынбарлыкта мөселман егете Шакирҗан Мөхәммәтҗанов икәнлеге турында сөйләүче белешмә дә бар. Мәктәп эзтабарлары, әлеге батыр һәм Газинур

Гафиятуллин эзләреннән алар һәлак булган Псков өлкәсенә барып, документаль фильмнар өчен кызыклы киноматериаллар да туплап кайттылар...

* * *

Бер үк вакытта үз төбәкләрендә туып үскән башка батыр якташлары турында эзләнүләрне дә киң колач белән алып баралар Өскебаш тынгысызлары. Фашистларның күпсанлы техникасын һәм җанлы көчләрен юк итеп, 18 яшендә үк Советлар Союзы Герое булган, гади солдаттан гвардия полковнигы дәрәҗәсенә күтәрелгән Сабир Әхтәмҗан улы Әхтәмов турында сөйләүче экспонатларга да бик бай хәзер мәктәп музее. Биредә әлеге легендар шәхеснең хәрби кителе, 1945 елның 24 мартында бирелгән Герой дипломының һәм Алтын Йолдызның төгәл күчермәләре, каһарманның данлы тормыш юлына кагылышлы бихисап документлар, фоторәсемнәр урын алган. Шунда ук Сабир аганың үз кулы белән язган автобиографиясе, сугыш чоры эпизодлары...

Алардан күренгәнчә, булачак батыр 1926 елның 15 июнендә Югары Өскебаш авылында туа. Гаиләдәге 7 бала (5 кыз, 2 малай) арасында ул – иң өлкәне. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Сабир 14 яшеннән әтисе янында тимерчелектә эшли башлый...

Бөек Ватан сугышы башлангач, Әхтәмҗан абый, олы улын гаиләдә һәм тимерче алачыгында төп хуҗа итеп калдырып, фронтка китеп бара. Шулай итеп, Сабир 1941 елның августыннан 1943 елның ноябренә кадәр колхозда өлкән тимерче булып эшли. Шул чорда яшүсмер егет үзен бары тик яхшы яктан гына таныта – колхозда да, йортта да төп таяныч була. Ә инде үз авыллары янәшәсендәге басуга төшәргә мәҗбүр булган самолетка беренче ашыгыч ярдәмне дә күрсәткәч (ул аның ярылган бензин багын яхшылап ямап бирә), абруе тагын да үсеп китә Сабирның. Тагын шунысын да әйтик: очучы аны, рәхмәт йөзеннән, үз очкычына утыртып, Өскебаш тирәли әйләндерә. Биеклектән башы әйләнсә дә, уңышлардан башы әйләнми егетнең – тимерче алачыгын чыңлатып-гөрләтеп, ут уйнатып эшләвен дәвам итә. Бер үк вакытта җирле халыкның, ягъни авылдашларының-колхоздашларының, тормыш итү кирәк-яракларына кагылышлы үтенечгозерләрен дә күңелен биреп, җиренә җиткереп башкара

ул. Ни әйтсәң дә, авыр сугыш барган чорда әнисе Зәкиягә ныклап булышырга – сигез җанлы ишле гаиләне туендырырга да, киендерергә дә кирәк бит!..

Көтмәгәндә фронттан авыр хәбәр алына: «Кызылармеец Әхтәмҗан Сәлимҗанов фашист илбасарларга каршы барган изге көрәштә, хәрби антына ахыргача тугры калып, батырларча һәлак булды...» Тимерче этисенең батыр булуына шикләнмәсә дә (әле алдагы хатында гына ул үзенең «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүе турында хәбәр иткән иде), аның үлүенә һич кенә дә ышанасы килми Сабирның. Дөньяда иң газиз-кадерле кешеләрнең берсе булган этисе шулай тиз генә юкка чыга ала микәнни?!

Дошманнан тизрәк үч аласы килү теләге-омтылышы, кайнаган вулкан кебек, тимерче егетнең йөрәген көйдерә. 1943 елның ноябрендә Сабир, үзе теләп, фронтка китә. Тимерче инструментын танкка каршы ата торган мылтыкка алыштыра ул. Зиһенле, үткер күзле егет корал белән эш итәргә бик тиз өйрәнә – фашистларның техникасын «чүкеп» кенә тора. Бераздан инде ул 2 нче гвардияче танк корпусының 4 нче гвардияче мотоукчылар бригадасында иң оста бронебойщикларның берсенә әверелә. 3 нче Белоруссия фронтына караган әлеге бригада составында С.Әхтәмов Смоленскидан Кенигсбергка кадәр данлы сугышчан юл үтә. Белоруссияне, Балтыйк буе республикаларын азат иткәндә һәм Көнчыгыш Пруссия өчен барган сугышларда зур кыюлык, батырлык үрнәкләре күрсәтә. Белоруссиядә «Багратион» операциясе вакытында ул, мәсәлән, төз атып, дошманның бер танкын һәм үзйөрешле орудиесен сафтан чыгара. Шуның өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Көнчыгыш Пруссиядәге фашистлар группировкасын тар-мар иткәндә, Сабир Әхтәмҗан улы үзенең исемен мәңгелек данга күмә. Шул чордагы хәлиткеч сугыш турында мәктәп эзтабарларына җибәргән хатында ул түбәндәгеләрне яза:

*«...1944 елның октябрендә дошманның Немерсдорф исемле бик яхшылап ныгытылган торак пунктына килеп җиттек. Безнең 2 нче батальонга, тукталып тормастан, танклар белән берлектә Немерсдорфны алырга һәм, махсус күрсәтмә булганчы, яулап алынган позицияне кулдан ычкындырмаска боерык бирелде.*

*Торак пунктка җиткәндә, дошманның төп юнәлештәге көчле уты безнең һөҗүмне туктатты. Кече сержант Лу-*

*ковкин (минем икенче номерым) белән икебез әлеге «җәһәннәм учагын» юк итәргә сугышчан задание алдык. Дошманның аяусыз ут давылы астында, үрмәләп-шуышып, тиешле объектка 70–100 метрга кадәр якынлаштык. Шунда без гранаталар атып кына аны юк итеп булмаячагын аңладык. Дошман янына яшеренеп килергә мөмкин түгел иде. Башка чара табарга кирәк. Ут сибүче ныгытманың бер кырыенда ягулык багына охшаган әйбер күренде. Берничә тапкыр ату нәтиҗәсендә аны яндырырга мөмкин булды. Ялкын җиргә күмелгән «Фердинанд»ның эченә үтеп керде. Снарядлар шартлый башлады. Сугышчылар «Ура!» кычкырып, дошман позицияләренә ташландылар. Төнлә бу торак пункт безнең кулга күчте. Тиздән дошманның бер рота пехотасы сугышчан разведка ясый башлады. Төнге сугыш вакытында безнең расчет дошманның тагын ике «Фердинанд»ын сафтан чыгарды.*

*Таң алдыннан дошманның күпсанлы танклары контратакага күчтеләр. Моторлар гөрелтесе якында гына ишетелә башлады. Әмма без, каушамыйча, дошманны якынга ук җибәрдек. Ара 150 метрлап калгач, безнең бронебойщиклар танкларга каршы ут ачтылар. Берничә минуттан уң флангтагы Филиппов расчеты бер танкны яндырды. Без берничә тапкыр атуга, сул флангтагы танк та туктап калды. Өченче танкның чылбырларын өздердек. Яны белән туктап калган танкка берничә тапкыр атуга, ул дөрләп яна да башлады. Дүртенче танк туры безнең өскә килә иде. Тиз генә чокырга яшерендек һәм шуннан атып аны да җимердек. Безнең солдатлар дошман пехотасын танклардан аердылар. Атака туктады, немец солдатлары чигенә башладылар. Шул вакытта дошманның тагын ике бронетранспортерын һәм снарядлар төягән ике автомашинасын юк иттек... Ике көн буе барган авыр сугышлар безнең гвардиячеләрнең тулы җиңүе белән тәмамланды...»*

Герой хатына тагын бер кызыклы өстәмә: бригада командиры, шушы сугышларда хәлиткеч роль уйнаганы өчен, яшь бронебойщик Сабир Әхтәмовны «Советлар Союзы Герое» дигән мактаулы исем бирүгә тәкъдим иткәндә: *«Үзенең батырлыгы, сабырлыгы һәм ныклыгы белән ул Немерсдорф шәһәрен штурмлауда һәм аны саклап калуда бәя биреп бетергесез булышлык күрсәтте, барлык сугышчыларга үрнәк булды»,–* дип яза.

Арыслан йөрәкле якташыбыз тагын күп кенә сугышларда катнаша, яралана, тагын сафка баса. Фашистларның җирдәге куәтле техникасын, җанлы көчләрен күпләп юк итү белән бергә, баш өстендә генә масаеп-гайрәтләнеп ут яудыручы бер хәрби очкычын да бәреп төшерә ул дусты Луковкин белән хәтта... 1945 елның гыйнварында Сабир Әхтәмов Көнчыгыш Пруссиядәге бер һөҗүм вакытында, күпкатлы йортның чарлагыннан атып, дошманның ике «Пантера»сын да яндыра. Шулар өчен Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә ул. Әнә шулай тимерче егет яу кырында да сынатмый, фашист ядрәсеннән һәлак булган сөекле әтисе, бергә сугышкан авылдашы Миннехан Габделхаков, чит-ят туфракта мәңгегә ятып калган йөзләрчә якташлары өчен дошманнан аяусыз үч ала.

Сабир Әхтәмҗан улы 1945 елның 24 июнендә Мәскәүдә үткәрелгән тарихи Җиңү парадында катнаша. Парадта катнашучыларның Кремльдәге кабул итү мәҗлесендә булу бәхете дә елмая аңа...

Сугыштан соң Сабир Әхтәмов кичке урта мәктәпне тәмамлый, Ленинградта офицерлар хәзерләү курсында укый, хәрби частьларның берсендә подразделение командирының сәяси эшләр буенча урынбасары вазифасын башкара. Аннары Мәскәүдә хәрби институт тәмамлап, Эчке эшләр министрлыгы хәрби частьларында хезмәт итә, атказанган хезмәткәр исеменә лаек була, полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.

Хәзер отставкадагы өлкән офицер Сабир ага Әхтәмов хәләл җефете – авылдашы һәм сабакташы Рабига ханым белән Казан каласында яши. Яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләү буенча зур эш алып бара ул. Ил агасы туып үскән төбәген дә онытмый – авылдашларына хатлар язып, кайткалап тора...

...Бөек Җиңүнең 50 һәм 55 еллыкларын бәйрәм иткән көннәрдә дә Мәскәүгә чакырып алдылар мөхтәрәм ветеранны – мәргәннәрнең мәргәнен! Һәр ике баруында да Сабир ага, ялкынлы яшьлек елларын хәтереннән кат-кат үткәреп, Җиңү парадында катнашты. Башын горур тотып, дәртле адымнар белән, ир-егетләрчә үтте ул күпне күргән Кызыл мәйданнан!..

Туган ягында легендар шәхес Сабир ага Әхтәмовка мәһабәт бюст куелды, документаль фильм эшләнде.Батырлык, әнә шулай, еллар үтсә дә, онытылмый – Тарихта мәңгегә кала!...

* * *

Мәктәп музеена яңадан-яңа экспонатлар өстәлә тора. Саный китсәң, башкарган эшләре бихисап аларның. Соңгы елларда, мәсәлән, музейда легендар партизан Зәки Җәләлиевка, атаклы Муса Җәлилгә һәм аның көрәштәш дусларына, Әхәт Атнашев белән Рушад Хисаметдиновка багышланган экспозицияләр пәйда булды. (Исемнәре телгә алынган соңгы ике батыр да шушы төбәктән!) 1995 елның 15 февралендә мәктәптә җәлилче-легионерларның һәм макизарларның I республика-зона «Хәтер җыены» зурлап уздырылды. Әлеге тантанада Кукмара районы хакимиятенең ул чактагы башлыгы Мөхәммәт Гатиятуллин, атаклы җәлилче – Үзбәкстанның халык мәгарифе отличнигы Фәрит ага Солтанбәков, район мәгариф бүлеге мөдире Роберт Мансуров, мәдәният бүлеге мөдире Азат Сабитов, район хәрби комиссариаты хезмәткәре – майор Тәлгать Сөнгатуллин һ.б. чыгыш ясап, Югары Өскебаш мәктәбе эзтабарлары эшчәнлегенә югары бәя бирделәр. «Хәтер җыены»нда район хәрби комиссары Заһир Абдуллин элекке легионер-макизарлардан өлкән яшьтәге укытучы – Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы Гаян ага Әхмәтшинга (Зур Сәрдек авылы), колхозчы Нургали ага Шәйдуллинга (Ташлы Елга) «Бөек Ватан сугышында катнашучы» таныклыклары, күп кенә ветераннарга истәлекле бүләкләр тапшырды. Шул ук көнне мәктәптә җәлилчеләргә багышланган музей да ачылды. Геройшагыйрьнең шигырьләрен һәм аның сүзләренә язылган җырларны сәнгатьле итеп башкару буенча район күләмендәге иҗади конкурсның соңгы туры да биредә үткәрелде. Җиңүче балаларга җәлилче каһарманнарның култамгалары (автографлары) куелган истәлекле китаплар һәм Әхәт Атнашев сурәте төшерелгән алтынсу төстәге истәлек медальләре бирелде. Медальләрне «Таң» күмәк хуҗалыгы, шушы очрашуга атап, махсус эшләткән иде. Район хакимияте исә җәлилчеләр җыенын үткәрү өчен кирәк кадәр акча да бүлеп бирде. Һәрьяктан хуплауга, мактауга лаек башлангыч бу!

Кагыйдә буларак, үткәрелгән һәр чара укучыларда Ватанга тугрылык, батырлар үрнәгендә яшәргә омтылу, намуслы хезмәткә зур хөрмәт, өлкәннәргә тирән ихтирам, ярдәмчеллек, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияли...

Бу уңайдан мәктәпнең эзтабарлар төркеме һәм музей

советы җитәкчесе, хәрби-патриотик тәрбия эшенең чын остасы Рифат Җәләлиевның, «Батырлык» кинофотостудиясенә нигез салган һәм дәресләрдә, класстан тыш сәгатьләрдә, һәртөрле очрашулар барышында файдалану өчен дистәләрчә төсле документаль фильмнар, слайдлар эшләгән, бер үк вакытта оста фотограф та, рәссам да булган укытучы-методист Гомәр Мөбарәкшинның, музейны бизәүче, аңа ямь-нур кертүче осталардан Зөлфәт Җиһаншинның, абыйлы-энеле Рамил һәм Дамир Шәриповларның, гомумән, бөтен педагогик коллективның, аның җитәкчесенең намуслы, фидакарь хезмәтләренә югары бәя бирәсе килә. Хәер, мәктәптә булганда Татарстан Президенты Минтимер әфәнде Шәймиев бу хакта аларның үзләренә дә иң җылы сүзләрен әйтте инде. Тикмәгә генә республика күләмендә «Елның иң яхшы мәктәбе» дигән мактаулы исем йөртми бит әлеге мәктәп!

Музейны оештыруга, экспедицияләрне әзерләүгә һәм матди яктан тәэмин итүгә, мәктәп каршында «Батырлар аллеясы» булдыруга һәм анда сугыш батырлары Нух Идрисов белән Сабир Әхтәмов, Социалистик Хезмәт каһарманы Әхмәтша Җиһаншин кебек атаклы якташларның һәйкәл-бюстларын торгызуга үзләреннән зур өлеш керткән «Таң» күмәк хуҗалыгының төрле еллардагы җитәкчеләре – Мөбарәкҗан Шакирҗан улы Гыйлаев, Мансур Миндрахман улы Баһманов, Раиф Галиулла улы Газизуллин, Рифкать Суфьян улы Ганиев иптәшләрнең һәркайсы олы хөрмәткә лаек!..

...Мәктәптә «Батырлык дәресе» бара. Районның барлык төбәкләреннән җыелганнар бирегә. Залларны иңләп, «Туган ягым – батырлар төбәге» җыры (Р. Гатауллин көе, Ш.Әхмәтсафа шигыре) яңгырый:

Туган ягым – батырлар төбәге,
Җиңү яулау – һәркем теләге!..
Яу кырында булсын, эштә булсын –
Илемнең без ныклы терәге!..

Заманында шушы мәктәптә белем-тәрбия алган талантлы җырчы, Татарстанның атказанган артисты, М.Җәлил премиясе лауреаты, Смоленск шәһәрендә үткәрелгән иҗади бәйгедә, татар җырларын җырлап, беренче урынга һәм «Алтын медаль»гә лаек булган Нурәхмәт Мөхәммәтҗанов аеруча зур рухлану белән башкара аны. Бу дәртле җырны мәктәп укучылары бердәм күтәреп ала. Ни әйтсәң дә, үз төбәкләре-

нә махсус багышлап чыгарылган җыр бит ул! Әйдә, күңелләр күгендә салават күпередәй булып балкысын, йөрәкләрне шифалы яңгырдай иркәләсен, табигать балаларын һәрчак изге-якты эшләргә илһамландырсын, алмашка килүче яшь буын аңында горурлык, шәфкатьлелек хисләре уятсын бу җыр!

## ХӘТЕР САКЧЫЛАРЫ ЯХУТ ТАРИХИ МИЗГЕЛЛӘРНЕ МӘҢГЕЛӘШТЕРҮЧЕЛӘР

...Мәркәзебез Казаннан «Курай» радиосы даими алып бара торган «Хәтер яктысы» дигән тапшыруларга кызыклы шәхесләр еш чакырыла. Чираттагы әңгәмәбездә катнашу өчен, студиягә Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, җөмһүриятебез журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясе лауреаты, «Бәллүр каләм» иҗади бәйгесендә беренче булып төп призны яулаган тынгысыз эзтабар Нургали Хөсәен улы Булатовны дәштек. Хезмәттәш дусларның: «Аның төгәллегенә карап, хәтта сәгатьне дә дөресләргә була!» – дип әйтүләре хак икән. Нәкъ билгеләнгән вакытка студиягә килеп җитте өлкән каләмдәшебез-остазыбыз. Кулында – «Ватаным Татарстан» газетасының әле генә «табадан төшкән» өр-яңа саны. Хәтер һәм Кайгы көненә (22 июнь) багышланган ул санда Нургали абыйның «Изге ядкарьләр» дигән күләмле язмасы да басылган иде.

– Әтием турында яздым әле,– диде ул.– Һаман да төшләремә керә. Акбүз атка атланган килеш керә, рухы шаттыр, мөгаен!..

Аннары Нургали абый күңелендә кайнаган кайбер уй-фикерләре белән уртаклашты:

– ...Әтисез үсүнең ни дәрәҗәдә кыенлыгын моны үз җилкәсендә, үз язмышында татыганнар гына белә. Шуңа күрә сугыш дигән афәтнең күпме кешенең башына җиткәнлеген, никадәр авырлыклар китергәнлеген һәрдаим сөйләп, искәртеп торасым килә. Юкса хәтерләр саега, күңелләр коргаксый бара. Яу кырында һәлак булганнарга, шул мәхшәрдән исән кайтканнарга, тылдагы «шинельсез солдатлар»га – тол хатыннарга, сугыш чоры балаларына карата битараф булуны, гаделсезлекне һич кенә дә күтәрә алмыйм!..

Бу сүзләрдә Нургали абыйның тоткан кыйбласы, рухи нык-

лыгы, ихласлыгы бик ачык чагыла. Әйе, бихисап билгесез каһарманнарны, аларның якты исемнәрен, кылган батырлыкларын газета-журналлар, радио-телевидение тапшырулары аша халкыбызның күңел түренә җиткерүдә армый-талмый, үзенә генә хас үҗәтлек белән фидакарьләрчә эшләүче, республикабыз күләмендә киң билгеле, үткен каләмле, туры сүзле, якты күңелле, көчле шәхесләрнең берсе ул.

Бу юлы да Нургали абый «Хәтер яктысы» тапшыруында сугыш һәм тыл батырлары, яшьтәш-чордашлары турында сөйләде. Бер уңайдан ул тыңлаучыларны газиз әтисенең Мари Элдагы Сослангер урманнарыннан – Резерв фронтының әзерлек лагереннан, Ленинград өлкәсендәге Синявино сазлыкларыннан җибәргән кош теледәй хатлары белән дә таныштырып үтте. Шәмәхә карандаш белән язылган өчпочмаклы ул хатлар Нургали абыйның әнисенә – явыз дошманны тизрәк җиңү хакына тылда ат урынына җигелеп эшләүче Нәгыймә апага адресланганнар. Сугышка хәтле Теләче районының Алан авылында «Марс-2» күмәк хуҗалыгы рәисе булып эшләгән һәм броне була торып та фронтка үзе теләп китеп барган Хөсәен абый Булатов, яу кырында авыр яраланып, госпитальгә эләгә. Аягында гангрена башлангач, хәләл җефетенә соңгы хатын юллый: *«Нәгыймәм! Аякны өченче тапкыр төптән үк кисеп карыйбыз, диләр. Исән калмасам, бәхил булыгыз...»*

Күңеле дөрес сизенгән икән Ватан солдатының. 1943 елның июлендә Хөсәен абый Ленинград өлкәсенең Пикалево шәһәре госпиталендә вафат була...

«Хәтер яктысы» тапшыруында бу юлы Нургали абыйның яшьтәше – Чиләбе шәһәреннән килгән данлыклы тальянчы, һәвәскәр башкаручыларның Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия фестивальләре лауреаты, мәшһүр музыкант Ф.Туишев исемендәге гармунчылар бәйгесендә һәм атаклы композитор Ф.Әхмәтовка багышланган халык иҗаты фестивалендә җиңүче Вазыйх абый Шәрәфетдинов та катнашкан иде. Аның да әтисе – Сәйфетдин агай Шәрәфетдинов – Буа районының Яңа Чәчкап авылыннан фронтка китеп бара һәм 1942 елның мартында яу кырында, Украинада батырларча һәлак була...

Әтиләрен чиксез сагыну белән искә алып һәм Ватан-Ана солдатларының изге рухлары алдында баш иеп, Вазыйх абый алар яраткан көйләрне, җырларны тирәнтен дулкынланып, эчке бер тетрәнү хисләре белән башкарды. Шул минутларда мин Нургали абыйның имәндәй нык-таза гәүдәсе-

нең җиңелчә калтырануын, күзләрендә яшь бөртекләре җемелдәшүен һәм кечкенә бала башыдай йодрыкларының, калын иреннәренең кысылганын күрдем. Әтиләренең җылы кочагыннан каерып тартып алган, әниләрен тол калдырган, күпме балаларны ятим иткән «йөзе кара» сугышка, фашизмга чиксез нәфрәт билгесе итеп кабул иттем мин бу халәтне...

Әтиләре дигәннән, Нургали абый әтисе каберен Бөек Җиңүнең 20 еллыгын билгеләп үткән истәлекле чорда эзләп таба. Дөресрәге, аңа бу эштә Ленинград өлкәсенең Бокситогорск районындагы Новая урта мәктәбе эзтабарлары булыша. Алар үзләренең туган җирләрен дошманнан азат итү өчен барган изге көрәштә кайнар канын түккән, газиз гомерен биргән Хөсәен Булат улы Булатовны – татар халкының гайрәтле, батыр улын тирәнтен хөрмәтләп, аның гаиләсен үзләренә кунакка чакыралар. Әмма ерактагы ул җиргә – йөрәккә бик тә якын урынга! – һәркем дә бара алмый шул. Юллар озын, катлаулы, өстәвенә күпме акча чыгымнары кирәк... Шуннан соң гаиләдәгеләр, үзара киңәшләшеп, әтиләре күмелгән төбәккә Нургали абыйны җибәрәләр.

Новая авылындагы Туганнар каберлегендә булганда, Нургали абыйның нинди хисләр кичергәнлеген бер Аллаһы Тәгалә белән ул үзе генә белгәндер. Мәһабәт обелисктагы «Рядовой Булатов Х.Б.» дигән юлларны укыганнан соң, Нургали абый, аның алдында тезләнеп, әнисе өйрәткән догаларны укый һәм шул каберлектәге изге туфракны йөрәк турысындагы кесәсенә кадерләп салып, әтисе каршында ант бирә:

– Синең данлы исемеңне, фамилияңне моңарчы һәр җирдә горур йөрттек, Әтиебез! Тыныч бул – киләчәктә дә шулай булыр, Аллаһы боерса! Нәселебезгә тап төшерерлек, йөзебезне кызартырлык бер кыңгыр эш тә башкармабыз. Оныкларыңа да, дәү бабагызның изге әманәте шул, диярмен...

Чыннан да, Хөсәен абый белән Нәгыймә апаның һәр баласы тормышта үз урыннарын тапкан. Нәсимәләре авылның уңган колхозчысы булса, Тимершәехләре тырыш игенчеләрдән саналды. Тикмәгә генә аңа «Татарстан Республикасының атказанган механизаторы» дигән мактаулы исем бирелмәде. Икесе дә туып-үскән җирләрендә кешеләрне сокландырып, сөендереп яшиләр. Шанлы нәсел агачын тагын да нурландырып, күзләрне-күңелләрне иркәләп, бер-бер артлы оныклар да үсеп килә...

Инде Нургали абыйның үзенә килсәк, аның да әтисе ал-

дында йөзе ак, намусы пакь. Нинди генә авырлыклар килсә дә, ул үзенең солдат Хөсәен Булатов улы икәнлеген беркайчан да хәтереннән чыгармады һәм тормыш сынауларын да җиңеп чыкты. Һәр эшне күңел биреп башкару сәләте, кешеләр йөрәгенә юл таба алу, хезмәтне оештыра белү осталыгы, мөгаен, күбрәк әтисеннән күчкәндер.

Нечкә күңелле, кешелекле бу шәхес гомере буе барча тереклеккә, җан ияләренә, адәм балаларына гел изгелек-игелек кылып кына яшәүче сирәк затларның берсе. Туган авылында китапханә мөдире булып эшләгәндә дә, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда да, 15 ел буе «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында һәм соңгы 25 ел дәвамында «Ватаным Татарстан» газетасында җаваплы вазифалар башкарганда да, кыйбласын үзгәртмичә, шул күркәм сыйфатларына тугры булып кала белде ул.

Җаваплы вазифа, яраткан эше дигәннән, Нургали абый Матбугат океанында үзе гомер буе омтылган матурлык һәм батырлык утрауларын эзләп тапты. Шуңа күрә аның һәр язганы – матурлыкка һәм батырлыкка мәдхия. Аларда бары тик чын дөреслек тантана итә.

Соңгы елларда ул татар генераллары һәм адмиралларына кагылышлы дистәләрчә очерклар язып бастырды. Аларга багышлап 2000 елда «Идел-Пресс» нәшриятында «Йолдызлы йолдызлар» дигән китап та чыгарды. Халкыбызның горурлыгы вә мактанычы булган шул затлы шәхесләр турында үзе туплаган бай мәгълүматларны Татар энциклопедиясе институтына хәзерләп тапшырды. Мәскәүдә, Россия Федерациясенең Кораллы көчләре Генераль штабында да аны яхшы беләләр. Россия Федерациясенең Хәрби фәннәр академиясе президенты, РФ Табигать фәннәре академиясе академигы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, армия генералы, хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы Мәхмүт Әхмәтдин улы Гәрәев, генерал-полковник Рәсим Сөләйман улы Акчурин, хатыны Эльмираның бертуган абыйсы – генерал-майор-инженер, техник фәннәр докторы, профессор Рафаэль Мидхәт улы Йосыпов, вице-адмирал, хәрби фәннәр докторы Марс Җамал улы Искәндәров, Татарстан Республикасы хәрби комиссары – генерал-майор Рим Шагали улы Мостаев һәм башка бик күпләр белән дустанә-тыгыз элемтәдә тора ул. 1993 елның 19–21 февра-

ле көннәрендә Мәскәүдә үткән татар генераллары һәм адмираллары җыенына да Татарстан журналистлары арасыннан иң беренче булып Нургали Булатов һәм аның якташы Рашат Низамиев чакырулы иде. Шуннан соң ике арада элемтәләр тагын да җанлана-ныгый төште...

* * *

Сүзебез яңадан Нургали абыйның әтисе күмелгән Туганнар каберлегенә әйләнеп кайтты. Ул анда кат-кат булган икән инде...

– ...Әтиемне югалту ачысының түзеп булмаслык дәрәҗәдә үзәгемне өзгәнен әнә шул каберлек янында аеруча ачык тоям-сизәм мин. Меңләгән-миллионлаган күзәнәгем белән... Сагыш һәм Кайгы кайчысы йөрәгемне-бәгыремне кат-кат телгәли шул мизгелләрдә... Сугыш утын кабызучыларга карата сурәтләп биргесез көчле нәфрәтем вулкан булып кайный күңелемдә! Миллионлаган җаннарны кыйган шул зилзиләтайфун исән калганнарны да аямады бит. Аның зәхмәтле шаукымы әле һаман да үзен нык сиздереп тора...

Шулай да гаделлек тантана итәр көннәр дә бар икән әле дөньяда! Күп миллионлаган кешеләрне чиксез шатландырып, Халыкара хәрби трибунал фашист илбасарларга, япон башкисәрләренә – хәшәрәт җаннарга! – тиешле җәзаларын бирде. Нюрнберг, Токио процесслары турында әйтүем...

Нургали абый белән безнең әңгәмәбез турыдан-туры әнә шул чорда җиһанны тетрәткән тарихи вакыйгаларга барып тоташты...

* * *

Нюрнберг процессы... Моннан ярты гасыр чамасы элек – 1945 елның 20 ноябрендә – Германиянең Нюрнберг шәһәрендә (нацизм һәм фашизм туган җирдә) Юстиция сараенда башлана ул. Халыкара хәрби трибунал алдына фашистлар Германиясенең иң югары дәрәҗәле дәүләт һәм хәрби эшлеклеләре – Кешелек дөньясының иң явыз дошманнары бастырыла. Әлеге процесс бер елга якын дәвам итә һәм 1946 елның 1 октябрендә фашистларның башлыкларына гадел хөкем карары чыгару белән тәгәлләнә.

Нюрнберг процессы гаять зур тарихи әһәмияткә ия. Дөнья халыклары беренче тапкыр биредә, төп гаепләнүчеләр бе-

лән бергә, фашизмның үзен хөкем итәләр, аның ерткычлыквәхшилек асылын, бихисап халыкларны һәм дәүләтләрне физик яктан юк итү, абсолют хакимлеккә дәгъва кылу проектларын фаш итәләр.

Болар белән без «Правда» газетасының элеккеге корреспонденты – күренекле язучы Б.Н.Полевойның «В конце концов. Нюрнбергские дневники» (М., 1969), шул чорда Халыкара хәрби трибунал составына керүче совет делегациясенең җаваплы сәркатибе А.И.Полторакның «Нюрнбергский эпилог» (М., 1983) дип исемләнгән китаплары һәм процесс барышына кагылышлы күптомлы документаль язмалар аша яхшы таныш.

Алардан күренгәнчә, әлеге тарихи процесс барышында 403 суд утырышы була, гаепләнүчеләр сөйли, 116 шаһиттан сорау алына, 143 язма мәгълүмат һәм 5 меңнән артык документ карала. Процесс стенограммасының русча тексты гына да 20 мең 228 бит, ягъни 39 том тәшкил итә!.. Шулай итеп, тиңдәше булмаган әлеге суд процессында язу өчен гомуми авырлыгы 200 тонна булган кәгазь, 27 мең метр кинотасма һәм 7 мең фотопластинка кулланыла.

Халыкара хәрби трибунал, фашист башкисәрләр кылган җинаятьләрне Гаделлек бизмәненә салып үлчәгәч, гаепләнүчеләрнең 12сен үлем җәзасына – асарга хөкем итә. Менә алар кемнәр: Геринг, Риббентроп, Кейтель, Розенберг, Франк, Фрик, Кальтенбруннер, Штрейхер, Йодль, Заукель, Зейсс-Инкварт һәм Борман. (Сүз уңаенда шунысын да әйтик: хөкем карары укылгач, Геринг төрмә камерасында үзүзен агулап үтерә; ә Борманны читтән торып кына хөкем итәләр – чөнки ул 1945 елның апрелендә үк Германиядән качып китәргә өлгергән була.– *Ш.М.*)

Төп гаепләнүчеләргә хөкем карары 1946 елның 16 октябренә каршы төндә тормышка ашырыла. Хәрби җинаятьчеләрне асу АКШ армиясе сержанты Джон Вудка йөкләнә. Ул әлеге авыр эшне бик тиз – сәгать ярым эчендә башкарып чыга.

Биредә шул күренешнең шаһиты булган данлыклы якташыбыз – «Правда» газетасы фотокорреспонденты, Минзәләдә туып үскән Виктор Антонович Тёмин истәлекләреннән аерым өзекләр белән таныштырып үтәсебез килә (аның татарчага тәрҗемә ителгән язмалары «Социалистик Татарстан» газетасында 1973 елның 16 май санында дөнья күрде):

«...Берлин вакыты белән, кичен, нәкъ 8 сәгатьтә, без, дүрт бөек державадан – Советлар Союзы, АКШ, Англия, Фран-

циядән икешәр кеше, ягъни сигез корреспондент, суд бинасына җыелдык. Бирегә Баварияне министр-президенты доктор Вильгельм Хегнер һәм Нюрнберг шәһәренең баш прокуроры доктор Фридрих Лейснер да килгән иде...

Бергәләп төрмәне карап чыгабыз. Аннары ишегалды, дәресрәге, төрмә бакчасы аркылы яшеллеккә күмелгән бер бинага таба үтәбез.

Шунда бүген җинаятьчеләр җәзаларын алачаклар.

Бинага килеп керәбез. Ишек каршында ук караңгы яшел төскә буялган өч дар агачы тора. Чуен блокларда ике йөз килограммнан артык йөк күтәрә алырлык өр-яңа маниль баулар. Эшафотның ике метрдан артык биеклектәге нигезе брезент белән капланган. Җәзаланган кеше 2 метр 65 сантиметр тирәнлектәге чокырга төшеп китәчәк...

Хөкем карары раслануы турында игълан ителгәннән соң, гаепләнүчеләрнең кулларына богаулар кидерделәр.

0 сәгать 55 минутта безне, сигез журналистны, җәза бирү урынына китерделәр. Һәм без эшафотка каршы, 3–4 метр чамасы арада, билгеләнгән урыннарга басабыз. Комиссия членнары, медицина экспертлары, Америка охранасы офицерлары керәләр. Һәр союздаш илдән: СССР, АКШ, Англия, Франциядән бишәр кеше катнаша – генерал, врач, тәрҗемәче һәм ике корреспондент (СССРдан ТАСС корреспонденты Б.Афанасьев һәм «Правда» корреспонденты – мин). Калганнар эшафоттан сул якта махсус билгеләнгән урыннарын алалар. Эшафотта дар агачы янына Американың ике солдаты: тәрҗемәче һәм палач баса.

1 сәгать 11 минутта, җитәкләп, Йоахим фон Риббентропны (Германиянең тышкы эшләр министрын.– *Ш.М.*) алып керәләр. Агарынган, алпан-тилпән килә, бер-ике секунд күзләрен ярым йомып тора, гүя аны рухи төшенкелек тәмам биләп алган. Богауларын чишәләр һәм кулларын артка бәйләп куялар.

– Исемегез? – дип сорыйлар инглизчә һәм немецча.

– Йоахим Риббентроп...

Баскычтан дар агачына менгерәләр, махсус каешлар белән аякларын бәйлиләр һәм соңгы сүзен әйтергә кушалар.

Риббентроп Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында тынычлык һәм союз булуын теләве турында сөйли.

Шулкадәр хәрби җинаятьләр һәм кешелек дөньясына каршы коточкыч кара гамәлләр планлаштыруда гаепле булган бу кеше әле һаман бөек дипломат булып кылана бит, дип

уйлыйм мин Риббентропны тыңлаганда. Европа илләрендә күпләп үтерү һәм талау – аның да эше бит...

Пастор кыска гына дога укый. Палач Риббентропның башына кара калпак кигезә һәм муенына элмәк сала. Күз ачып йомганчы, палач рычагка баса. Сәгать бер тулып 15 минут.

Бер тулып 17 минутта куллары богаулы Кейтельны (Вермахт Верховный Башкомандованиесенең штаб начальнигын.– *Ш.М.*) кертәләр. Генерал-фельдмаршал Вильгельм Кейтельны мин беренче тапкыр 1945 елның 8 маенда – Берлин янындагы Карлхорстта, Гитлер Германиясенең берсүзсез капитуляция ясавы турындагы Актка кул куйганда күргән идем. Ләкин ул чагында Кейтель хурлык юлының эшафотка илтәчәген белмәгәндер әле.

1 сәгать 37 минут. Кальтенбруннерны алып керәләр. Бу ерткыч рейхсфюрер Генрих Гиммлерның уң кулы булган, күзләре уйнап тора, куллары буып ташлардай зур. Доктор дәрәҗәсендәге фашист, Австриядә «СС» оештыручы, аннары – Куркынычсызлык полициясе начальнигы. Полиция генералы Эрнст Кальтенбруннер – гитлерчы үтерүчеләрнең иң башлысы, иң үткене.

Салкын канлы палач аның башына да калпак кидерә...

Һәр асылган кешедән соң дар агачында баулар алмашына...

2 сәгать 46 минут 30 секунд. Барысы да тәмам. Американың ике солдаты кара одеял ябылган носилкада Герман Герингның (Германия Хәрби-һава көчләре башкомандующие, рейхсмаршал.– *Ш.М.*) мәетен алып чыгалар. Хәбәрчеләргә аның йөзен ачып күрсәтәләр һәм җәзалап үтерелгәннәр янына куялар.

Шулай итеп, төп хәрби җинаятьчеләргә карата Халыкара хәрби трибуналның хөкем карары гамәлгә ашырылды. Без төрмә баскычына чыгабыз һәм, җиңеләеп, төнге саф һаваны иснибез...»

Виктор Антонович сөйләгәннәргә өстәп, тагын шуларны белдерәсе килә: җәзалаучыларның үле гәүдәләрен, махсус фотограф рәсемгә төшереп алганнан соң, Мюнхендагы крематорийга алып барып яндыралар һәм көлләрен самолет бортыннан җилгә очыралар. Калган җинаятьчеләр – Гесс, Функ, Редер, Ширах, Шпеер, Нейрат, Дёниц – Халыкара хәрби трибунал карары нигезендә төрле срокта төрмәгә ябылуга хөкем ителәләр...

* * *

Мөмкинлектән файдаланып, без «Хәтер яктысы» тапшыруы аша, тыңлаучыларыбызны атаклы якташыбыз Виктор Тёмин һәм аңа турыдан-туры бәйле гаҗәеп вакыйгалар белән дә якыннанрак таныштырып үттек. Чыннан да, исән чакта ук легендар шәхес булган Виктор Антонович! Алдына нинди генә максат куйса да, аны ахыргача үтәмичә торып, беркайчан да тынычланмаган. Гомумән, тынгысызлык, искиткеч дәрәҗәдә җитезлек-оперативлык, төп вакыйгаларның нәкъ үзәгендә кайнарга омтылу аның өчен тормыш-яшәү кагыйдәсе булып әверелгән.

Шул уңайдан берничә мисал. Безнең гаскәрләр Берлин урамнарына бәреп кереп, инде рейхстаг янында көчле сугышлар алып баралар. Озак та үтми, рейхстаг гөмбәзендә Җиңү байрагы җилферди башлый! Шушы тарихи мизгелне мәңгеләштереп калдыру өчен, В.Тёмин, кичекмәстән хәрби очкычка утырып, Берлин күгенә күтәрелә. Дошманның өзлексез уты, снарядлар шартлавы астында ул, үтә салкын канлылык күрсәтеп, байтак объектларны, шул исәптән җиңелгән-җимерелгән рейхстагны да фотога кат-кат төшерә. Анлары, очкычларының фюзеляжын снаряд ярчыклары берничә урыннан тишеп үткәч, алар җиргә төшәргә мәҗбүр булалар. Виктор Антонович, күктә башкарган эше белән генә канәгатьләнеп калмыйча, шәһәрне штурмлаучы танкларның берсенә утырып, яңадан рейхстаг янына китә. Совет сугышчылары элгән Җиңү байрагы фашизм өнендә әнә ничек горур җилферди! Җирдән, танк янәшәсеннән төшереп алынган шул фоторәсем арада иң уңышлысы була. Һәм аны тиз арада «Правда» газетасында бастыру өчен фоторепортер Тёмин Советлар Союзы Маршалы Жуковка мөрәҗәгать итә. Фронт командующие аңа Варшавага кадәр бару өчен шәхси очкычын биреп тора. «Аннан исә башка самолет белән Мәскәүгә очарсыз!» – ди Георгий Константинович. Әмма Виктор Антонович, булганы белән генә канәгатьләнмичә, әлеге очкычны башкалага кадәр үк алып китә. Мондый башбаштаклыкның ахыры бик күңелсез тәгалләнәчәген бөтен күзәнәкләре белән сизсә дә, Тёмин, үз карьерасын вә гомерен корбан итү бәрабәренә булса да, рейхстаг өстендә Җиңү байрагы балкыганын беренче булып «Правда» газетасы аша бөтен дөньяга күрсәтәсе килә! Һәм Виктор Антонович шул изге теләгенә ирешә дә! Икенче көнне иртән-иртүк Маршал Жуков очкычында Бер-

линга «Правда» газетасының өр-яңа санын (600 данәдә!) алып кайта ул. Шул чакта гына Георгий Константинович, әлеге «әрсез» фотохәбәрчене иң каты җәзага тарту уеннан кире кайтып, аны... тәвәккәллеге һәм оперативлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкли!..

1945 елның 9 маена каршы төндә Берлинда, Карлсхорстта, җиңелгән фашистик Германия вәкилләре берсүзсез капитуляция Актына кул куйганда да, 1945 елның 2 сентябрендә Токио култыгында АКШның «Миссури» линкорында япон милитаристлары үзләренең җиңелүләрен таныганда да, дөнья фотохәбәрчеләренең иң алгы сафында булып, шул кабатланмас мизгелләрне Тарих диварына мәңгелеккә беркеткән Виктор Тёминның шанлы исеме киләчәктә дә, Тәвәккәллек вә Куркусызлык символы булып, телләрдән телләргә күчеп йөрер әле. Чыннан да, нинди генә кыен шартларда да, килеп туган авырлыкларны җиңү юлын үзенә генә хас үҗәтлек, тапкырлык белән тиз таба алу талантына ия булган ул. Мисал эзләп ерак китәсе юк. Япония вәкилләренең берсүзсез капитуляция Актына кул кую вакыйгасын массакүләм чараларда киң чагылдыру өчен «Миссури» линкорына дөньяның төрле илләреннән ике йөзгә якын журналист килә. «Правда» газетасы фотохәбәрчесе В.Тёмин да шулар арасында. Әмма аңа ни сәбәптәндер урынны түрдән бирергә ниятләмиләр. Дөресрәге, яхшы урыннар америкалылар тарафыннан төрле агентлыкларга, шактый зур күләмле долларлар хисабына, алдан ук сатылган.

Шулай да Виктор Антонович аптырап калмый. Япония капитуляциясен кабул итү Актына СССР исеменнән кул куярга тиешле генерал-лейтенант К.Н.Деревянконы күреп алып, аңа бер-ике сүз белән хәлне тиз арада аңлатып бирә. «Минем арттан калмагыз!» – ди Тёминга генерал. Аннары ул Виктор Антоновичны союзниклар гаскәрләренең башкомандующие – генерал Д.Макартур белән якыннан таныштыра. «Бу – Сталинның махсус хәбәрчесе!» – ди Деревянко Тёмин турында Макартурга. Шуннан соң Виктор Антоновичны, америкалылардан алдарак, Актка кул кую өстәле каршына ук бастыралар. Төрле илләрнең журналистлары совет фоторепортерының тапкырлыгына хәйран калалар.

В.Тёминның «Миссури» линкорында төшергән һәм «Правда» газетасында лаеклы урынын алган тарихи фотосы исә, иң уңышлы рәсем буларак, бөтендөнья матбугатын иңләп чыга...

1946 елның октябрендә Нюрнбергта фашистларны хөкем иткән вакытта да, Виктор Антонович үзенең элекке гадәтләренә тугры булып кала. Биредә дә иң уңышлы кадрларны ул төшерә. Кеше ышанмаслык эшләр башкарырга сәләтле бу фоторепортер еш кына «үткен кылыч йөзе өстендә бии». Әйтик, аның үлемгә хөкем ителгән хәрби җинаятьчеләрнең соңгы минутларын – гәрчә югары җитәкчелек тарафыннан катгый кисәтелсә дә! – оста яшерелгән фотоаппараты ярдәмендә башкаларга сиздерми генә төшереп алуы үзе генә дә ни тора?! Дөрес, әлеге фотоларны ул чорда тиз генә дөньяга чыгару мөмкинлеге булмый – нык тыела. Әмма Виктор Антонович өметен өзми. Гомер кояшы баер алдыннан гына ул тарихи шул фоторәсемнәрне үзенең китабында да файдалану җаен тапты. Һәм, шулай итеп, сугыштан соң туган төрле буын вәкилләренә моннан алты дистә ел чамасы элек хәрби җинаятьчеләргә карата башкарылган гадел хөкем карарының ничек үтәлешен бөтен тулылыгы, чын дөреслеге белән күрсәтә алды...

«Тёмин феномены» озак еллар дәвамында әле бик күпләрне кызыксындырыр. Виктор Антоновичның биографиясе һәм географиясе һәркемне сокландырырлык. Минзәләдәге «Туган як тарихы» музеенда төбәк эзтабарлары, аның шәхесен зурлап, искиткеч бай материаллар туплаганнар...

– Хәзер безнең арада, исәннәр арасында, Виктор Антонович Тёминга охшаган кызыклы шәхесләр бармы? – дигән сорау бирде тапшыруыбызны алып баручы «Курай» радиосы хезмәткәре Сәрия ханым Тукаева.

– Ходайга мең шөкер, андый олуг затлар янәшәбездә яши әле,– дидем мин дә үз чиратымда.– Үзебезнең милләттәшләребез арасыннан иң беренче булып элеккеге хәрби журналист, хәзерге вакытта Татарстанның халык рәссамы буларак киң билгеле Мәхмүт ага Усмановны зурлап телгә аласым килә!..

Татарстанның Кукмара районы Адай авылы егете ул. 3 нче Армия газетасы фотохәбәрчесе һәм рәссамы буларак, һәрвакыт иң кайнар урыннарга – алгы сызыкка ашкына, сугышчан иптәшләре белән Берлинга кадәр барып җитә. Алай гынамы әле?! Мәхмүт Усман улы фашистларның өнен – рейхстагны штурмлауда да турыдан-туры катнаша һәм, аның түбәсенә – гөмбәзенә менеп, җимерелгән Берлинның аяныч-мескен халәтен, безнең каһарманнарның үлемсез батырлыкларын эскиз-рәсемнәрендә чагылдырып калдырырга

омтыла. Шул чакта аның кулын дошман ядрәсе яралый – әмма рәссам-офицер үзенең яраткан шөгылен дәвам итә!..

Бәхеткә, Мәхмүт аганың шул чорда ясаган рәсемнәренең бер өлеше үзендә (калганнары – төрле музейларда) сакланып калган икән. Фоторәсемнәре дә... Соңгыларын рәссам, чит-ят күзләргә күрсәтмичә, үз остаханәсендә дистәләрчә еллар «тозлап» яткырган (аларның шактый зур өлешен без «Казан» журналының Мәхмүт ага Усмановның киң кырлы иҗатына багышланган махсус кушма санында (№ 1–2, 1996 ел) бастырып та чыгардык.– *Ш.М.*). Ни генә әйтсәң дә, ул фоторәсемнәрдә – сугышның шомлы сурәте. Аларның һәркайсыннан рәхим-шәфкатьсез явыз үлем ыржаеп карап тора кебек. Германиянең җимерелгән шәһәр-авылларын, завод-фабрикаларын, юлларын-күперләрен, дошманның тар-мар ителгән, ташлап калдырылган бихисап техникасын, сугыш коралларын, үлекләрне күреп, тирән тетрәнү хисләре кичердем мин. Моның үзенә күрә тагын бер сәбәбе бар: 1972–1973 елларда мин дә – Алман җирендәге «Советская Армия» газетасының хәрби хәбәрчесе буларак – Мәхмүт ага Усманов йөргән эзләрдән үткәнмен икән ләбаса! Хәзер инде ул урыннар искиткеч матурланган, төзекләндерелгән, гөлчәчәккә, яшеллеккә күмелгән... Сугыш чоры рәсемнәре белән хәзергеләрен чагыштырып карагач, Тынычлыкның никадәр кадерле-тансык икәнлеген ачык тоясың, сиземлисең. Шуңа күрә дә Чечнядагы кебек бер мәгънәсез сугышка – кан коешка, үзара үтерешкә карата чиксез нәфрәт, ризасызлык хисләре күңелләрдә мартен мичендәге чуендай кайный да инде!..

«Дөньяны бары тик Тынычлык яшәтә, яшәртә!» – Мәхмүт ага үзенең картиналары, фоторәсемнәре аша кешеләргә әнә шул изге хакыйкатьне төшендерергә омтыла. Гомумән, сугыш һәм тынычлык темасы – аның күпьеллык иҗатының төп кыйбласы. Җиңү таңы атканнан соң, 1946 елда Казанга кайтып, бүгенге көнгәчә (инде менә ярты гасырдан артык!) һәр чын кеше күңелендәге рухи балкышны данлап, янәшә-тирәбездәге искиткеч гүзәл-сихри табигатебезне тирәнтен аңлап, илһамланып яши ул. Рейхстагны «буйсындырган» тәвәккәл рәссам-каһарман сәнгать үрләренә дә ышанычлы төстә кыю күтәрелә. Инде дөньякүләм билгеле мәшһүр рәссамга әверелеп бара ул. Хәзер Мәхмүт ага Усмановның шедеврларын Татарстан, Россия һәм элекке СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче халыклар гына түгел, Америка, Германия,

Италия, Финляндия, Франция, Швеция, Япония кебек чит мәмләкәтләрнең сәнгать сөючеләре дә яхшы беләләр, аның олуг таланты алдында башларын ияләр...

Үзенең бихисап картиналарының берсендә сурәтләнгән салават күпере кебек, күңелләрне – күңелләр белән, буыннарны буыннар белән тоташтыра тылсымчы-рәссам. Бу – аның илаһи бәхете, киләчәктә дә гомер бакый дәвам итәр тормыш җыры...

* * *

...Күренекле зыялыбыз – ару-талуны белми торган эзтабар әдибебез Шамил ага Рәкыйпов та Виктор Тёмин токымыннан! Моңарга өстәп тагын аның турында, эчке бер горурлык хисе белән: «Үзебезнең татар Смирновы!» – дип тә әйтәләр. Чөнки ул – үзенең киң колачлы эзләнүләре белән бик күпләргә яхшы билгеле Сергей Смирновның рухташы, тиңдәше!..

Мөхтәрәм Шамил Җиһанша улы, дистәләрчә еллар дәвамында эзтабарлык эше белән аеруча нәтиҗәле шөгыльләнеп, моңарчы билгесез булган бик күп каһарманнарыбызга мәңгелек яшәү – үлемсезлек бүләк итте. Очучы хатын-кызларыбыздан беренчеләрдән булып Советлар Союзы Герое дигән данлы исемгә лаек булган милләттәшләребез Мәгубә Сыртланова белән Ләйлә (Ольга) Санфирова, Алтын Йолдызлы партизаннардан Иван Кабушкин белән Гатаулла Минаев (Сергей Орлов), рейхстаг гөмбәзенә беренче булып Җиңү байрагын кадаган татар егете Гази Заһитов һәм башка бик күпләр турында хәтерләрдән мәңге җуелмаслык тарихи-документаль әсәрләр тудырды, батырларыбызга иң асыл сүзләрдән мәһабәт һәйкәл койды ул.

Хәзер исә без Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Шамил ага Рәкыйповның татарлардан иң беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Батыршинга һәм аның дусты – украин егете, Алтын Йолдыз кавалеры Иван Чернопяткога багышланган «Таңнар һаман матурмы?» дигән күләмле лирик-драматик әсәренә (К., 1970) бераз тукталып үтәргә уйлыйбыз. Кыйсса бик тә гыйбрәтле.

...1938 елның җәендә Приморье краеның Хасан күле янында япон самурайларына каршы көрәшкән ике дус һәм аларның 19 нчы застава начальнигы – Советлар Союзы Ге-

рое Петр Терешкин, шактый вакытлар үткәннән соң, 1947 ел азагында Токиога чакырылалар. Шаһитлар сыйфатында...

Мәгълүм булганча, Япония башкаласында, элеккеге Хәрби министрлык бинасында – 1946 елның 3 маеннан 1948 елның 12 ноябренә хәтле – суд процессы бара. Халыкара хәрби трибунал, Нюрнбергтагы кебек үк, сугыш уты кабызучыларны – бу юлы исә японнарның төп хәрби җинаятьчеләрен хөкем итә. «Токио процессы» буларак тарихка кереп калган әлеге судта хөкемдарлар булып унбер ил – АКШ, СССР, Бөекбритания, Кытай, Франция, Австралия, Канада, Яңа Зеландия, Нидерланд, Һиндстан һәм Филиппин мәмләкәтләре вәкилләре катнаша. Хәрби трибунал, утыз ай ярым вакыт эчендә барлыгы 818 тапкыр ачык суд утырышлары үткәреп, меңләгән документлар белән таныша, бихисап шаһитларның сөйләүләрен тыңлый. Суд стенограммасы тексты гына да 48 мең 412 бит тәшкил итә, хөкем карары исә 1200 биткә теркәлә.

Халыкара хәрби трибунал Япониянең югары даирәләрендә эшләүчеләрдән – тышкы эшләр министры Мацуока, премьер-министрлар Тодзио, Хирота, Хиранума һәм Койсо, хәрби министрлар Араки һәм Итагаки, Квантун армиясенең элеккеге командующие Умэдзу, әлеге ил императорының Хәрби-диңгез эшләре буенча киңәшчесе, Баш диңгез штабы начальнигы Нагано, японнарның Берлиндагы илчесе Осима, «японизм» расистлык теориясе авторларының берсе Окава...– барлыгы 28 хәрби җинаятьченең Кешелек дөньясына карата кылган кара гамәлләрен тикшерә. Ахырдан шуларның 7се асарга хөкем ителә, 16сына гомерлек төрмә җәзасы бирелә.

Болар хакында тулы мәгълүматлар М.Ю.Рагинский белән С.Я.Розенблитның «Международный процесс над главными японскими военными преступниками» (М.–Л., 1950), Л.Н.Смирнов белән Е.Б.Зайцевның «Суд в Токио» (М., 1980) дигән китапларында аеруча киң яктыртыла...

Инде Хәрби трибунал утырышларына яңадан әйләнеп кайтыйк. Анда подполковник П.Терешкин, майорлардан Г.Батыршин, И.Чернопятко суд процессында, үтемле-дәлилле чыгышлар ясап, япон хәрби сугыш чукмарлары эшләгән җинаятьләрне кыю фаш итәләр...

«Инде бурычыбыз үтәлде, җинаятьчеләр, ниһаять, тиешле җәзаларын алдылар!» – дип, Токиодан Владивостокка кү-

тәренке күңел белән сөенә-сөенә очканда, ике дус утырган очкыч һавада һәлакәткә очрый. Шулай итеп, Г.Батыршин белән И.Чернопятконы һәм башка пассажирларны Тын океан үз кочагына тартып ала. (Икенче рейстагы очкычка утыру сәбәпле, П.Терешкин исән кала. Һәм ул төп япон хәрби җинаятьчеләренең 1948 елның 23 декабренә каршы төндә Токионың Сугамо төрмәсе ишегалдында асып үтерелүләрен беренчеләрдән булып радио аша ишетә.– *Ш.М.)*

* * *

«Хәтер яктысы» радиотапшыруы ахырында без Шамил ага Рәкыйповның каһарманнарыбызга багышланган әсәреннән өзек тә укып күрсәттек:

*«Әйтегезче, әйтегезче миңа: алсу таңнар һаман шундый матурмы? Тук башаклы басулар өстендә элеккегечә җилкенеп тургайлар сайрыймы, бакчаларда җимешләр кызарып пешәме, көн-төн гөрләп-гүләп торган шахталар, завод-фабрикалар яныннан ыжгырып поездлар үтәме – тормыш шулай дәвам итсен өчен, кызлар элеккегечә үк сөйкемле һәм тырыш киленнәр үңганмы, егетләр хәзер дә батыр, ирләр хәзер дә гайрәтлеме?*

*Шулайдыр, шулай булмаска мөмкин түгел!*

*Ашаган ризыкның чын тәмен, чиста пакь өй эченең ямен, мәхәббәтнең гүзәллеген, дуслыкның эчкерсезлеген, бирелгән антның какшамаслыгын – тормышның чиксез матурлыгын өстән-өстән генә аңлаучылар булса, андыйларга минем хакта сөйләгез, мин җырлый алмый калган җырны җырлагыз!..»*

* * *

Әнә шундый рухта, каһарманнарыбызга мәдхия җырлап, бихисап җаннарны уятып, күңелләрне кузгатып төгәлләнде «Хәтер яктысы» радиотапшыруының чираттагысы... Аның барышында без һәммәбез дә шул вакыйгалар эчендә кайнагандай булдык, кадерле кешеләребезне янәдән искә төшердек...

Әйе, Кояш кебек Хәтер утын, Хәтер яктысын берни дә сүндерә алмый. Җыр-моң белән дә шулай – барлык киртәләрне, каршылыкларны җимереп, дөньяга көчле ташкындай ургылып чыга ул!..

Хәтер һәм Моң – игезәк туганнар кебек! Алар – мәңгелек! Дөньяны Хак Сүз, Моң, Иман һәм Хәтер яшәтә...

# ҮЗЕ ДӘ – КАҺАРМАННАР ТОКЫМЫННАН!..

...Картаюны белми торган нәселдән ул Шаһинур,–
Һәркемгә кыла яхшылык, күзләрендә яши нур!
Узган яуның корбаннары тәрәзәңне шакыйдыр:
«Безне кабат терелткәнгә, Рәхмәт Сиңа, Шаһинур!..»

*Илдар Юзеев,*
*Татарстанның халык шагыйре*

Әлеге язмамны мин Хәтер һәм Кайгы көнендә... төгәлрәк итеп әйтсәк, 22 июнь таңында, иртәнге сәгать 4 тә башладым. Әйе, әйе, җан өшеткеч сугыш башланып киткән дәһшәтле-утлы мизгелләрдә... Ак көчләр белән кара көчләрнең, капма-каршы басып, яшәүгә лаек булуны раслау мәйданында бил алыша, көч сынаша башлаган вакытында... Сүзем – якын дустым, эзтабар әдип Шаһинур Мостафин турында. Хәтер сагында һәрчак уяу торучы, Үткән белән Киләчәкне тоташтырырлык тылсымлы рухи күпер сала белүче тынгысыз замандашым турында...

...Аның белән без – сабакташлар... Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә бер чорда укыдык, бер тулай торакта яшәдек. Шул вакытта ук Шаһинур үзенең искиткеч киң күңеллелеге, ифрат ягымлылыгы, һәркемгә «Дустым!» дип кенә дәшүе белән бик күпләрдән аерылып тора иде. Болар өстенә тышкы кыяфәте дә үзенә тарта: озынча буй, таза гәүдә, бөдрә чәч, сөйкемле йөз. Һәрвакытта диярлек елмаеп күрешү, сүз кату, эндәшү вә сөйләшү. Хәтта әдәби бәхәсләр вакытында да без, «кайнар татарлар», каты-саллы сүзләр ычкындырганда да, ул әдәп дигән рамкадан чыкмады.

Шаһинур бик матур итеп җырлый иде. Группабыз җитәкчесе – «чәчәк телле» галимә Флера ханым Сафиуллина һәм бер төркем студентлар белән аның, солист буларак, Уфаларга хәтле барып, күпләрне сокландырып, гашыйк итеп кайтканы әле дә хәтеремдә...

Әйе, әйе!

Университетта Татарстанның халык артисткасы Гәүһәр ханым Камалова оештырган Татар театр студиясенә дә бик теләп йөрде Шаһинур. Башкортстанда яшәүче атаклы шагыйрь һәм драматург Әнгам Атнабаевның «Ул кайтты» драмасында төп рольне (үз әтисе язмышына охшашлы Тимербулат образын) нәкъ тормыштагыча, ышандырырлык итеп уйнагач һәм бу спектакльне Татарстан телевидениесе аша халыкка да күрсәткәч, аны, имтиханнарсыз гына, Казан театр училищесының I курсына да кабул иткәннәр иде хәтта. Әмма ике җирдә уку җитди кыенлыклар тудыргач, Шаһинур училищедан

китәргә мәҗбүр булды. Шулай да ул җырлавыннан һәм спектакльләрдә уйнавыннан һич кенә дә тукталмады. Г.Камал театры сәхнәсендә массовкаларда да еш уйнады студент егет. Бөтен җаны-тәне белән әдәбиятка-сәнгатькә гашыйк иде шәриктәшем...

Университетта яхшы билгеләренә генә укыды ул. Аннары, гаилә хәлләре таләп иткәч, III курстан читтән торып уку бүлегенә күчте. Башта – Мамадыш, аннары Кукмара районнары газеталарында эшләде, өйләнеп җибәрде. Имтиханнар бирергә килгәндә, Шаһинур гел безнең тулай торакта яши иде – шуңа күрә без аның тормышыннан һәрвакыт хәбәрдар булдык. Танылган тел-әдәбият галимнәре Флера Садретдин кызы Сафиуллина, Нил Гафур улы Юзиев житәкчелегендә «Шигъри синтаксис һәм шагыйрь индивидуальлеге» дигән катлаулы темага язылган диплом эшен дә бишле билгесенә яклап, тагын бер мәртәбә безне сокландырды ул. Аңарчы да Шаһинурның шушы темага вузара фәнни-гамәли конференцияләрдә уңышлы чыгышлар ясаганы бар иде...

Филолог дипломы алып чыккан югары белемле белгечләр буларак, төрлебез төрле тармакларда, төрле җирләрдә эшләсәк тә, җай туган саен, без Шаһинур белән очрашып-аралашып тордык. Соңгы елларда бигрәк тә... Шунысы аеруча мөһим: авырлыклар килгәндә, Шаһинурга һәрчак таянырга, барысы турында да ачылып сөйләргә-сөйләшергә була. Хәер, әңгәмәдәшен ихлас ихтирам итеп, аны йөрәге-җаны белән аңларга тырышып тыңлаучы нурлы йөзле, ягымлы бу ир-егетне үз итми мөмкин түгел. Ул шундук синең якын фикердәшең булып әверелә. Аңа, үзең дә сизмичә, күңел серләреңне сөйли башлыйсың...

Мин үзем дә гомерем буе Шаһинур дустымны гел күз уңында тоттым. Ул кылган изге гамәлләрнең, күпкырлы эшчәнлегенең шаһиты булдым.

Яхшылык эшләр, игелек кылыр өчен махсус килгәндер кебек Шаһинур бу дөньяга. Тәңре, кешеләрнең күңелләрен күрү, кемнәргәдер ярдәм итү, булышу йөзеннән, Җиргә аның кебек инсаннарны да вакыт-вакыт җибәреп торадыр, күрәсең.

Әле Җирдә күпме изге җаннар
Рухи салкынлыктан өшиләр...
Күңелемдә күпме Җылылык бар –
Барысын Сезгә бирәм, Кешеләр! –

дип тикмәгә генә язмагандыр Шаһинур. Бу – аның рухын ачып салучы программ-шигыре, ачкыч-шигыре. Әйе, Шаһинурга ышанырга була. Киң вә якты күңелле бу инсан сине беркайчан да язмыш иркендә калдырмас, кыен чакта шундук ярдәм кулын сузар. Шатлыгың,

уңышларың булса, үзенекедәй күреп, ихластан сөенер. Сөенә белү – үзе үк кеше күңеленең бәһаләп бетергесез асыл сыйфатларының берсе ул. Сөенә белүчеләр күбрәк кирәк бу дөньяда! Шул чагында яшәүнең яме-кадере тагын да арта төшәр иде...

Шаһинурның кешеләр белән эшли белү, оештыру осталыгын иң элек Кукмарада күрдек. Район газетасы редакциясе каршында «Аһәңле сүз» клубы, аннары «Салават күпере» дигән әдәби берләшмә оештырып, төбәк талантларын барлауга һәм аларны республика күләмендә танытуга үзеннән лаеклы өлеш кертте ул. Нәтиҗәле эшчәнлеге белән күпләгән күңелләрне сөендергән әлеге берләшмәдән Рәшит Бәшәров, Рәшит Миннегалиев, Рәниф Шәрипов, Газинур Морат, Вәгыйз Хәсәнов, Михаил Михайлов, Александр Герасимов, Рузилә Закирова, Заһид Мәхмүди, Рифә Рахман, Фирдания Тимерханова-Нугаева, Халисә Нигъмәтуллина, Шәмсия Хәлимова, Нурзидә Нотфуллина (Нурзилә), Вячеслав Кириллов, Илдар Хәйруллин кебек үзенчәлекле каләм әһелләре үсеп чыкты. 1979 елның ноябрендә Кукмарада яшь һәм башлап язучыларның V республика-зона конференциясе дә уздырылып, шулар арасыннан иң өметлеләре Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка да тәкъдим ителде. Моңа ничек сөенмисең?!

Тиктормас-эзләнүчән шәхес буларак, Шаһинур, иксез-чиксез илебезнең төрле почмакларына сибелгән кукмаралы якташларыбызны барлап, алар турында матбугат битләрендә «Синең горурлыгың, Кукмара!» дигән рубрика астында дистәләрчә очерк-зарисовкалар бастырып чыгарды. Аннары, шуларга нигезләп, район газетасы редакциясе һәм типография урнашкан бинада, бертуган энеләре – рәссамнар Мансур һәм Наил белән бергә, Туган як тарихы музеен ачып җибәрде. Бераздан Шаһинур, район җитәкчеләре янына барып, данлыклы якташларны Кукмарага чакырып кайтару, аларны туган җирләрендә хөрмәтләү, инде мәрхүм булган зур шәхесләрнең якты истәлекләрен мәңгеләштерү, шанлы исемнәрен урамнарга, мәктәпләргә бирү, аларга бюст-һәйкәлләр кую мәсьәләләрен дә күтәрде. Шаһинурның бу эшлекле тәкъдимен хакимияттәгеләр дә хуплап каршыладылар. Нәтиҗәдә шул елларда, Татарстан тарихында беренчеләрдән булып, Кукмара төбәгеннән чыккан атаклы шәхесләрнең район үзәгендә, зурлап, мәртәбәле җыеннары үткәрелде. Күрсәгез иде шул чакта туган якларын өзелеп сагынып кайткан кешеләрнең күзләрендәге рәхмәтле рухи балкышны!..

Дулкынландыргыч очрашуларның матур бер нәтиҗәсе буларак, Кукмарада «Якташлык җәмгыяте»нең нигезе салынды; тупланган бихисап материалларга, экспонатларга таянып, район үзәгендә – борынгы күркәм йортларның берсендә – Төбәк тарихын өйрәнү музее

ачылды; урамнарга, мәктәпләргә, сквер-аллеяларга күренекле шәхесләрнең данлы исемнәре бирелде; үзләрен аеруча таныткан каһарманнарга, хезмәт батырларына бюст-һәйкәлләр куелды...

Әлбәттә инде, әлеге мөһим эшләрнең һәркайсының уртасында Шаһинур үзе кайнады. Ни әйтсәң дә... «Инициатива – наказуема!» дигәндәй, үзең башлап әйткән сүзне яисә тәкъдим иткән эшне җиренә җиткереп үтәп күрсәтергә дә кирәк бит әле! Шөкер, йөзенә кызыллык китермәде Шаһинур. Кешеләр рәхмәт әйтерлек итеп башкарып чыкты ул тотынган һәрбер эшен. Хезмәтләре республика күләмендә дә киң яңгыраш тапты. «Синең горурлыгың, Кукмара!» дигән очерклар сериясе һәм публицистик язмалары өчен Шаһинур Мостафинга, республика районнарында эшләүче каләмдәшләре арасында беренчеләрдән булып, 1982 елда Татарстан Журналистлар союзының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе бирелде.

1986 елда ул Кукмара район газетасының беренче мөхәррире, Бөек Ватан сугышы каһарманы Сәмигулла Кәримуллин исемендәге премиягә дә лаек булды.

Монысының үзенә күрә бер тарихы бар. Исәннәрнең – кадерләрен, үлгәннәрнең каберләрен белергә ихластан омтылучы Шаһинур, яу кырыннан кайтмый калган каһарманнарның эзләреннән йөри башлагач та, журналист-политрук С.Кәримуллинның үткән тормыш юлын һәм сугыш чорын өйрәнүне үзенә төп бурычларның берсе итеп куя. Һәм максатына ирешә дә! Ул иң элек Сәмигулла Гарифулла улының Кукмарадагы, Казан һәм Братск калаларындагы туганнарын һәм бердәнбер улы Рафаэльне эзләп таба, СССР Оборона министрлыгының Подольск шәһәрендәге (Мәскәү өлкәсе) Үзәк архивында атналар дәвамында баш күтәрми эшли. Эзләнүләре бушка китми. Гвардияче политрук С.Г.Кәримуллинның 1942 елның 31 мартында Смоленск өлкәсенең Сычевка шәһәре янында, дошманның ут өермәсен күкрәге белән томалап, батырларча һәлак булуы турында мөһим мәгълүматлар табыла...

Сугышка кадәр күренекле язучы Шәйхи ага Маннурның якын дусты булган һәм аны һәркайсыбызга яхшы таныш «Гайҗан бабай» поэмасын язарга рухландырган Сәмигулла Кәримуллин турында (әдип бу шәхес турында үзенең «Агымсуларга карап» дигән автобиографик әсәрендә дә кат-кат әйтеп үтә) берсеннән-берсе кызыклы сәхифәләрне ачты Шаһинур һәм үз укучыларына җиткерде. Аннары ул танылган скульптор Альфред Абдрашитовтан әлеге журналист-политрукның бюстын да эшләтеп алып, аны Кукмара район музеена куйдыруны оештырды. Тора-бара Кукмара район газетасы каршында, елның иң нәтиҗәле эшләүче журналистларын һәм хәбәрчеләрен

бүләкләү өчен, С.Кәримуллин исемендәге махсус премия һәм әлеге каһарманның сурәте төшкән лауреат дипломы да булдырылды...

Кеше кадерен, аның рухын-күңелен тирәнтен аңлый белүче, Кукмара районының республика-ил күләмендә танылган «Яңа тормыш» арендачылар берлеге рәисе – Татарстан Республикасының атказанган агрономы, Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, «Почет Билгесе» ордены кавалеры Рәфыйк Габдерәүф улы Рәүфов бик хаклы әйткәнчә, «Кукмаралыларның үзләреннән дә кукмаралырак ул Шаһинур!» Аның бу сүзләрен, бергә сөйләшеп утырганда, танылган галим-мөгаллим, әдәби тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор Фоат Галимулла улы Галимуллин да ихластан җөпләде.

Әйе, атаклы әдип М.Горький сүзләрен бераз үзгәртеп әйтсәк, физик яктан Шаһинур Мамадышта туса да, рухи яктан, күргәнебезчә, Кукмарада ныграк формалашкан (хәер, Шаһинур үзе дә бу хакта, ике якны да тигезләргә тырышып: «Иллегә – илле!» – дип әйтергә ярата. Ягъни мәсәлән, аңа Мамадыш та, Кукмара да бертигез дәрәҗәдә якын-кадерле-газиз! Игезләр кебек булган һәр ике төбәккә дә, көченнән-сәләтеннән килгәнчә, игелекле хезмәт күрсәтергә тырыша ул).

12 елдан артык гомерен Кукмарага багышлаганнан соң, 1983 елның апрелендә Шаһинур гаиләсе (хәләл җефете Дамирә, улы Рушан, кызы Гөлназ) белән Казанга күчеп килде. Татарстан Мәдәният министрлыгы эшкә чакыргач. Шундук үзен халык иҗаты һәм мәдәниагарту эшләре буенча республика фәнни-методик үзәгенә баш мөхәррир итеп билгеләделәр. Үзәк директоры – сабакташы Марат Хәйруллин тәкъдиме буенча. Биредә дә сынатмады ул. Биш ел дәвамында, татар һәм рус телләрендә «Халык сәхнәсе», «На меридианах культуры» дигән газеталар чыгарып, үзешчән сәнгать көчләренең репертуарларын баетырдай махсус сценарийлар, методик кулланмалар эшләп-бастырып, иҗади мохитнең үзәгендә кайнады. Шуңа күрә исеме дә һәрчак мактаулылар рәтендә йөрде Шаһинурның...

Аннары аны 1988 елның июлендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең ул чактагы рәисе – күренекле драматург һәм прозаик Туфан ага Миңнуллин үзләренә эшкә чакырды. СССР Язучылар берлеге Әдәбият фондының Татарстан бүлеге директоры итеп билгеләделәр каләмдәшебезне. Биредә дә Шаһинур әлеге җаваплы-авыр хезмәтне, элек-электән килгән күркәм гадәтләренә тугры калып, җан җылысын, күңел яктысын биреп башкарды. Литфондның Татарстан бүлеге ул чорда СССР һәм РСФСР күләмендә, Мәскәү һәм Ленинградтан кала, 80гә якын бүлек арасында иң алдынгылар сафында

булды. Әйе, әйе! Татарстан язучылары Әдәбият фондының соңгы ике дистә ел дәвамындагы алыштыргысыз баш бухгалтеры Диләфрүз ханым Вахитова һәм «Аккош күле» иҗат йорты бухгалтеры – СССР Әдәбият фонды отличнигы Вера Васильевна Рожкова бик хаклы әйткәнчә, күпләгән язучыларны һәм аларның гаиләләрен сөендереп-канатландырып яшәгән «Алтын чор» иде ул!..

Шаһинур Мостафин, хезмәттәге уңышлары өчен, Халыкара Әдәбият фонды идарәсенә әгъза итеп сайланды, СССР язучыларының IX (соңгы) съездында һәм Евразия Халыкара Язучылар берлекләре бердәмлеген оештыру съездында, танылган бер төркем әдипләр белән бергә, Татарстаннан делегат булып та катнашты...

Шул елларда Шаһинур, тәҗрибәле өлкән дуслары белән бергә, бөек мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге җәмгыятьне оештыруда үзеннән зур өлеш кертте, әлеге оешманың вице-президентларының берсе булды. Аннары аны «Мамадыш якташлыгы» җәмгыятенең вице-президенты итеп сайладылар. Шәйхи ага Маннурның (1905–1980) иҗат мирасын өйрәнү-саклау, якты истәлеген мәңгеләштерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен (ул әлеге комиссиянең сәркатибе санала) Шаһинур дустыбыз ошбу күренекле шагыйрь һәм әдип исемендәге мәртәбәле премиягә дә лаек булды. (Бу премия 1982 елда Мамадыш районы хакимияте, Ш.Маннурның туган төбәге саналган «Чулпан» күмәк хуҗалыгы һәм Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан булдырылган иде.)

1992 елның сентябреннән башлап 1999 елның сентябренәчә Шаһинурның тынгысыз эшчәнлеге татар халкының төп журналы саналган «Казан утлары» белән бергә тыгыз үрелеп барды. Абруйлы журнал мөхәррирләренең берсе буларак, ул, әлеге зур тарихлы, кызыклы-мавыктыргыч энциклопедик басманың мөмкин кадәр күбрәк таралуы, аңарда дөнья күрүче тормышчан әсәрләрнең, уйландырырлык язмаларның һәр укучы күңеленә барып җитүе өчен, бар көчен-сәләтен, осталыгын эшкә җикте...

1999 елның сентябреннән Шаһинур Мостафин яңадан Татарстан Язучылар берлеге аппаратында эшли башлады. Республикабыз әдипләренең яңа җитәкчесе Фоат Галимуллинның иҗат эшләре буенча урынбасары булып. Аңа йөкләнгән вазифалар байтак. Берлектәге иҗат остаханәләре, Татарстандагы әдәби берләшмәләр эшчәнлеген даими игътибар үзәгендә тоту, өметле каләм ияләрен Татарстан Язучылар берлегенә кабул итү өчен Коллегиягә тиешле документларны әзерләү һәм идарә утырышларын үткәрүдә рәискә булышу, «Хәтер яктысы» кичәләрен, әдипләрнең юбилейларын үткәрү, аларга мактаулы исемнәр бирдертү өчен, булачак лауреатлар өчен

кирәкле документларны тутыру, күрше өлкәләрдә, республикаларда яшәүче милләттәшләребез арасыннан яшь талантларны барлау һәм аларга һәрьяклап булышлык итү...– һәммәсе дә аның җилкәсендә...

Хезмәтен, бар күңелен, көчен-сәләтен биреп башкаргач, Татарстан язучыларының XIV корылтаенда (31 май, 2002 ел,) каләмдәшләре Шаһинур Мостафинга тагын зур ышаныч күрсәттеләр. Идарәгә тәкъдим ителеп, иң күп тавыш җыйган әдипләр арасында Шаһинурның исем-фамилиясе беренче бишлектә иде... Яңадан, «рәис урынбасары» «камытын киеп», үзенә тапшырылган йөкне тарта башлады ул...

Йөрәге кушканча, Ш.Мостафин сугыш кырларында ятып калган билгесез каһарманнарны эзләү, аларның кылган батырлыкларын, якты истәлекләрен киләчәк буыннар хәтеренә җиткерү юнәлешендә дә нәтиҗәле эшли. Эзтабарларның республика күләмендәге «Хәтер яктысы» берләшмәсе рәисе буларак, ул һәр елны үзенең чираттагы ялын шушы изге максатка багышлый. Әйе, әйе! Соңгы елларда гына да аның җитәкчелегендәге экспедиция әгъзалары, хәрби архивларда кат-кат эшләп, Балтыйк буе һәм Кавказ республикаларында, Брянск, Волгоград, Донецк, Кировоград, Орел, Ленинград, Львов, Мәскәү, Псков өлкәләрендә, Карелиядә һәм Германиядә булып, Бөек Ватан сугышының моңарчы билгесез булган батырлары турында бай мәгълүматлар туплап кайттылар. (Германия дигәннән, бу илдә совет гаскәрләре төркемендә зенитчы-артиллерист һәм армия газетасының хәрби хәбәрчесе булып хезмәт иткәндә дә, Шаһинур каһарманнарыбызны барлау белән нәтиҗәле шөгыльләнде.)

Кагыйдә буларак, экспедиция булып үткән урыннарда, шәһәр һәм авылларда данлыклы якташларыбыз исемнәрен йөртүче урамнар һәм скверлар барлыкка килә, документаль фильмнар төшерелә, каһарманнарга һәйкәлләр торгызыла, истәлек билгеләре куела. Эзләнүләр барышында табылган яңа мәгълүматлар, ачылган яңа батырлыклар, яңа исемнәр газета-журнал язмалары, радио һәм телевидение тапшырулары аша халыкка даими җиткерелеп барыла.

«Батырлар эзеннән...» дип исемләнгән тапшыруларны Татарстан телевидениесе һәм радиосы аша даими яңгыратучы Ш.Мостафин сугышта 8 улын югалткан ана Фатыйха апа Әхмәдиевага Мамадыш шәһәре үзәгендә ап-ак һәйкәл куйдыруда да башлап йөрде. Шаһинурның «Сигез бизәкле сөлге» дигән документаль повестеның төп герое булган Фатыйха апага куелган ул һәйкәл бер үк вакытта сугышта газиз балаларын, якыннарын югалткан барлык милләт аналарының – тыл батырларының мәңге басылмас олы сагыш-кайгыларын уртаклашу билгесе дә иде!..

Һәйкәл дигәннән, Ш.Мостафин үзе эзләп тапкан каһарманнардан 24 кешегә шундый һәйкәлләр куйдырды инде.

Легендар Александр Матросовның мөселман егете Шакирҗан Мөхәммәтҗанов икәнлеген ачыклау һәм аның чын исемен, кылган батырлыкларын тарихта калдыру өчен дә Шаһинур үзеннән лаеклы өлеш кертте. Моның белән генә чикләнеп калмыйча, ул Подольск шәһәрендәге Үзәк архивта кат-кат эшләп, тагын 24 милләттәшебезнең-республикадашыбызның шундый ук батырлык үрнәге кылуларын ачыклады. Элекке СССР күләмендә исә андый каһарманнарның – матросовчы-шакирҗановчыларның! – саны 432гә җитте...

Хаксызга рәнҗетелгән каһарманнарны аклау буенча да бик нәтиҗәле эшли Шаһинур. Шуңа бер генә мисал китереп үтәсем килә.

Татарстан Республикасының Кукмара районындагы Битләнгер (Аксыбы) авылында гомер кичерүче 1919 елгы Зәки ага Җәләлиевка, заманында әсирлектә булуы сәбәпле, сугыш ветераны таныклыгы һәм пенсия бирелмәвен белгәч тә, Шаһинур, мондый гаделсезлекне бетерү өчен, ныклап эшкә тотына. Эзләнә торгач, Зәки аганың Кызыл Армия сафларында – 136 нчы укчы дивизиянең 541 нче полкында хезмәт итүе һәм 1941 елның октябрендә, нык яраланып, аңсыз хәлдә дошман кулына төшүе ачыклана. Әсирләрне фашистлар шахталарда төрле авыр эшләрне башкарырга мәҗбүр итәләр. Аннары көчле сак астында 1943 елның августында Югославиягә озаталар. 1944 елның апрелендә Зәки Җәләлиев, Татарстанның Дөбъяз (хәзер – Биектау.– *Р.С.*) районы Олы Кавал авылы егете Габделхак Галиуллин һәм тагын бер казах, ике рус әсире белән концлагерьдан качып, Югославия партизаннарына килеп кушыла. Зәки Җәләли улы, шулай итеп, партизаннарның 33 нче дивизиясенә караган 2 нче Масловицкая бригадасындагы рус ротасы сугышчысы булып китә. Фашистларга каршы күп кенә сугышчан операцияләрдә катнашып, 1944 елның 11 октябрендә Новый Град каласы янында тагын авыр яралана ул. Якташы Габделхак Галиуллин исә шунда батырларча һәлак була...

Боларны Шаһинур, төрле архивлар белән элемтәгә кереп, алай гына да түгел, Югославиянең Мәскәүдәге илчелегенә һәм Белградтагы Архив институтына хатлар язып, тиешенчә ачыклый.

Дөреслек ахыргача тантана итсен өчен, ул 1990 елның маенда Югославия партизаннарының Орел һәм Брянск шәһәрләрендә үтүче Бөтенсоюз очрашуына Зәки ага Җәләлиевны махсус алып бара. Өлкән партизанның аягы сынган чак дип тә тормыйлар. «Юлда чакта үзеңне күтәреп кенә йөртербез!» – дип, ярдәмгә Зәки аганың улы

Рифкатьне, аның якын туганы – әлеге төбәкнең эзтабарлар төркеме башлыгы, танылган мөгаллим Рифат Җәләлиевны, истәлекле очрашу мизгелләрен мәңгеләштерү өчен Казан телестудиясеннән документаль фильмнар төшерү остасы Камил Арифуллов белән Түбән Өскебаш урта мәктәбенең «Батырлык» кинофотостудиясе җитәкчесе Гомәр Мөбарәкшинны да үзе белән ала Шаһинур...

Әлеге «визит» Зәки ага файдасына тәмамлана. Биредә ул үзенең партизан дусты Борис Сергеевич Гусевны (Брянск) очрата һәм аны шул ук елның июнь аенда Аксыбы Сабан туена чакыра. Олы кунак аксыбылыларга Зәки аганың партизанлык иткән чордагы батырлыклары турында сөйли, көчле алкышлар астында аңа «Югославия партизаны – СССР гражданины» дигән медаль дә тапшыра! Әйе, әйе! Тагын бер елдан соң – 1991 елның 11 августында – Югославиянең Мәскәүдәге илчелегеннән һәм әлеге җөмһүриятнең үзеннән Радойка Фехимович-Джуракич һәм Зоран Фехимович кебек ханым-әфәнделәр – рәсми вәкилләр – Аксыбыга килеп, Зәки ага Җәләлиевка бөтен халык алдында, үз хөкүмәтләре исеменнән, кайнар рәхмәт сүзләрен җиткерәләр, бүләкләр бирәләр...

Шуннан соң инде Зәки ага Җәләлиев тулысынча «аклана», аңа «Ватан сугышында катнашучы» таныклыгы бирелә, пенсия акчасы да түләнә башлый.

Саный китсәң, күп инде мондый гыйбрәтле хәлләр, тетрәндерерлек язмышлар...

Заманында Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт ага Мәһдиев атаклы фоторәссам – Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт ага Шакирҗанов турында: «Милләткә Мидхәтләр кирәк!» – дип язган иде. Чөнки әлеге олпат шәхес бик күп зыялыларыбызның күркәм гамәлләрен, сурәтләрен киләчәк буыннар хакына мәңгеләштерде. Шаһинур да, каһарманнарыбыз онытылмасын өчен, шундый ук изге эшне башкара. Балтач районында яшәп иҗат итүче талантлы каләмдәшебез – үзен оста публицист та, әдәби тәнкыйтьче итеп тә таныткан Рәфыйк Шәрәфиев бик хаклы язганча, *«Газинурлар батырлыгын җырлау өчен милләткә Шаһинурлар да кирәк!»*

– Шаһинур Мостафинның язучылык кыйммәте-хикмәте, чын сүзе нидә? – дигән сорауга:

– Бөек Ватан сугышының моңарчы билгесез булган каһарманнарын эзләп табуда, яу батырларының исемнәрен киләчәк буыннар өчен мәңгеләштерүдә! – дип, өздереп җавап бирергә була. Дөресрәге, әлеге «мәңгеләштерүне» дәвам итүдә! Чөнки Сергей Смирнов, Гази Кашшаф, Самат Шакир, Рафаэль Мостафин, Шамил Рәкыйпов

кебек фидакарь әдипләрдән соң бу постка, язучы-эзтабар булып, ул басты! Ифрат изге вә игелекле эштә Шаһинур...

Ш.Мостафинның иҗатын яшьлек елларыннан ук күзәтеп килгән һәм аны заманында Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим иткән халык шагыйре Шәүкәт ага Галиев бик хаклы язганча: «Бик кирәк безгә мондый язучы: хәтер саекмасын, күңелләр коргаксымасын өчен кирәк! Шаһинур сүзе, гомере бүленгән – «Кайтмый калганнар турында җыр» яза. Язучы тормышның, яшәү дигән мирасның нинди корбаннар бәрабәренә яуланганын яхшы белә. Үткәннәр хәтере тынгы бирми Шаһинурга – иҗат дәртен, илһамын шушы изге максатка багышлый тынгысыз эзтабар... Язганнарының зур күпчелеге халык бәхете өчен гомерләрен кызганмаган шәхесләр турында... Яхшылыкка, матурлыкка, ярдәмчеллеккә, олы җанлылыкка, рухи ныклыкка өнди аның әсәрләре. Кешеләрне ярата Шаһинур!»

Шулай бер ачылып сөйләшеп утырганда, эзтабар әдип болай дигән иде:

– ...Кайчагында үземне дә сугышта булган күк тоям... Хәер, әтием белән бергә яу кырларында дошманның ут өермәләрен томаларга, юкка чыгарырга бергә барганбыз бит. Аның кан тамырларында без дә – туачак балалары – җиде егет, дүрт кыз да булгандыр бит!

Хикмәтле сүзләр...

Фәлсәфи уйлар...

Боларны әйтә алсаң вә шулай уйлансаң гына, моннан ярты гасыр элек булып үткән дәһшәтле афәт-фаҗига турында, бигрәк тә аның каһарманнары турында язарга мөмкиндер...

Каһарманнар арасында аның иң якын кешесе дә бар. Әтисе – сугыш кырыннан дөм сукыр килеш кайткан талантлы музыкант, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән яу батыры, туып үскән җирендәге тырышлыгы «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бәяләнгән Әхмәтсафа Мостафа улы. Әнисе – күмәк хуҗалыкта гомере буе маңгай тирен түгеп, намус белән эшләгән «Герой-Ана» – Гөлзәйнәп Ибраһим кызы. Йә, әйтегез, мондый тамырлардан кем шытар-калкыр да, бу ата-анадан кем туар?! Иң беренче нәүбәттә, әлбәттә, әйбәт кеше! Яхшы инсан! Җылы җанлы адәм!!!

Шуңа күрә ишле-тату бу гаиләдән кешелекле, изге-якты күңелле, талантлы-эшчән инсаннар чыккан. Исемнәре дә мәгънәле, матур: Шаһинур, Саҗидә, Дәлилә, Габденур, Мансур, Илсөяр, Илсур, игезәкләр Илдус белән Илгиз, Илгизә, Наил... Араларында атказанган мәдәният хезмәткәрләре, матбугатта, телевидениедә, сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләүчеләр дә, КамАЗ заводларында, төзелештә, кошчылык фабрикасында, техника буенча үзләрен таныткан осталар да

бар. Һәммәсе диярлек әдәбият-сәнгатькә гашыйклар... Ата-ана күңелендәге тылсымлы моң әнә шулай балаларына да күчкән!..

Минем әлеге күркәм гаилә яши торган төбәктә – Мамадыш районының Арташ авылында да булганым бар. Нибары җитмеш йортлы ошбу авыл – кечкенә булса да – төш кенә! Үзендә дәүләт һәм хөкүмәт эшлеклеләрен, югары дәрәҗәдәге офицерларны, галимнәр һәм язучыларны, танылган музыкантларны һәм җырчыларны, атказанган игенчеләр һәм терлекчеләрне, хәтта Социалистик Хезмәт Герое белән СССР Верховный Советы депутатын да үстереп биргән хикмәтле авыл бу! Тауларга ышыкланып, урманнар кочагына сыенып утырган Арташ үзенең ил-дөнья күләмендә танылган уллары-кызлары белән хаклы рәвештә горурлана ала... «Азатлык» радиосының Мәскәүдәге хәбәрчесе – танылган язучы һәм журналист Нәзифә Кәримова үзе генә дә ни тора! Дөньяны иңләүче Нәзифәнең тавышы – бер үк вакытта Арташ тавышы да ул!..

Шаһинур да менә шундый үзенчәлекле мохиттә туып үскән. Заманында бөек Тукай белән аралашкан данлыклы авылдашы Борһан ага Сәлаховның, чичән буларак, урам буйлап, теге яки бу кешегә атап, шигырь сөйләп йөрүе аңа да тәэсир итми калмый. «Арташ Тукае»на ияреп, үзе дә шигырьләр яза башлый ул. Нәсерләр, хикәяләр дә иҗат итә, рәсемнәр дә ясый. Аннары аларны республика күләмендә 1961 елда яңадан чыга башлаган «Яшь ленинчы» газетасына юллый. «Беренче беленнәр» баштарак «төерле» булсалар да, соңыннан алар Бакый Урманче, Хәсән Туфан, Шәүкәт Галиев кебек танылган шәхесләрнең дә игътибарын үзләренә җәлеп итәләр. Нәтиҗәдә Шаһинур 1965 елда шигырьләре буенча республика күләмендә җиңүче дип табылса, 1966 елда аңа «Уяна таңы илемнең...» дигән лирик хикәясе өчен беренче урын бирелә!..

Шуннан соң да Шаһинур үзенең әсәрләре белән иҗади бәйгеләрдә еш катнаша һәм җиңү арты җиңүләр яулый... Аннары яшь шагыйрь мәктәптә «Башлап язучылар түгәрәге»н оештырып җибәрә. (Тора-бара бу түгәрәктән киләчәктә СССР һәм Татарстан Язучылар берлекләре әгъзалары булачак талантлы иҗади шәхесләр үсеп чыга!)

Өйләрендәге унбер бала арасында Шаһинур – иң өлкәне. Фронтовик әтисе сугышта алган яраларыннан бик иртә вафат булгач, газиз вә кадерле әнисенең төп таянычы була ул. Мәктәптә укыган чорында Шаһинур, матди яктан хәлне аз гына булса да җиңеләйтү максатыннан чыгып, кичләрен авыл клубында киномеханик ярдәмчесе булып та эшли. Эне-сеңелләренең һәркайсына тормышта үз юлларын, үз урыннарын табуда ныклап булыша. Хәзер дә алар

турында даими кайгыртып тора... Менә шуңа күрә дә барлык туганнары Шаһинурны, әтиләре урынына күреп тә, иң олы абыйлары буларак та, тирән хөрмәт итәләр, аңа зур ышаныч белән карыйлар...

Ә ышаныч илаһи кодрәткә ия! Кешегә ул тау-ташларны күчерерлек рухи көч бирә. Тирә-юньдәгеләрнең шундый ышанычын аклау өчен, шәм кебек, үзе күләгәдә калып булса да, берөзлексез янаяна, бар дөньяны яктыртырга, нурларга омтыла Шаһинур. Хәер, каләмдәшләре арасында аның кушаматы да Шәм бит әле!..

Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафинның баш хәрефләрен генә калдырып укы – «ШӘМ» килеп чыга. Исем-фамилия, ата исеме инициалларыннан «ШӘМ» сүзе чыккан кешеләр алай ук бик күп түгелдер. Чыннан да, үз исемең, атаң-бабаң исемнәреннән янган вә балкып киткән «ШӘМ» бит бу!

Ә менә үзләре гомер буена шәм булып янганнар һәм яктылык сипкәннәр, кемнәрнеңдер караңгы төнен, әңгер-меңгерне, сукмак юлын нурлы иткәннәр аз, бик аз. Шундый кешеләр искә килсә, танылган көрәшче-трибун шагыйрь – Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге мәртәбәле премиясе лауреаты Рәшит Әхмәтҗановның: «Бер шырпыны Кояш итеп кабыздык!» – дигән шигъри юлларын кабатлыйсың...

Башкалар өчен шәм булып балкый алган бик аз гына санлы шундый инсаннарны да кояш кебек кабул кыласың. Шул азларның берсе Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафин – ШӘМ!

Аның шәп аты-кушаматы ул ШӘМ!..

Шаһинур Мостафинның тагы бер асыл сыйфаты бар: ул ифрат ярдәмчел кеше. Өстендәге киемен генә түгел, Татарстанның халык шагыйре, остазы һәм якын дусты Илдар ага Юзеев әйткәнчә, «...кешеләр өчен җанын да бүлеп бирергә әзер торучы мөлаем ир-егет ул!» Шаһинур турында шундый ук рухтагы җылы сүзләрне абруйлы, игътибарлы вә ихтирамлы каләмдәшләребездән Ә.Еники, М.Кәрим, Л.Ихсанова, Г.Ахунов, М.Хөсәен, М.Насыйбуллин, И.Салахов, Ә.Баян, Т.Миңнуллин, Р.Фәйзуллин, Н.Хисамов, Ф.Галимуллин, Х.Сарьян, Ә.Габиди, Б.Камалов, Р.Хисмәтулла, Ш.Маннапов, Ә.Гадел, Н.Булатов, З.Хәнәфиев, Н.Кәримова, М.Вәлиев, Р.Шәрипов, Р.Газизов, М.Каюмов һ. б. матбугат битләре аша да әйттеләр инде. Чыннан да, әле Татарстан язучыларының Әдәбият фондында директор булып эшләгәндә дә, күпме мохтаҗ әдипләргә, шагыйрьләргә, яшь иҗатчыларга һәм рухи, һәм матди яктан булышты ул. «Казан утлары» журналы редакциясенә эшкә күчкәч тә, аларны ярдәменнән ташламады. Ахыр чиктә акчага бик мохтаҗ язучыларга үз әсәрләренең гонорарларыннан (каләм хакыннан) да өлеш чыгара иде ул. Кире кайтарып бирмәү

шарты белән!.. Әйе, әйе! Йә, әйтегез, кемдә бар бу?! Җанын бүлеп бирүчеләрдә генә... Шуңамы аның икенче кушаматы да «Малый Литфонд» иде бит! Ә кушаматлар бик күпне сөйли алар...

«Халык мәхәббәте лауреаты» дигән үзгә исеме дә бар Шаһинурның. Шулай дигәч тә... Татарстан язучыларының 1999 елның 28 маенда үткән XIII корылтаендагы бер күренеш кылт итеп хәтергә төшә.

Корылтай башлангач та, Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев танылган әдипләрдән берничә кешегә мактаулы исемнәр бирү турындагы Указын игълан итте. Чорыбызның абруйлы шәхесләреннән «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллинга – Татарстан Республикасының халык шагыйре, күп кенә популяр җырларның авторы, күренекле шагыйрә Резеда Вәлиевага Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исемнәр бирелде. Чират Шаһинур Мостафинга җиткәч (ул, татар әдәбиятын үстерүдәге шәхси казанышлары өчен, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре дигән исемгә лаек булган иде), зал, гомердә булмаганча, озакка сузылган көчле алкышларга күмелде. Моңа Илбашы үзе дә бераз аптырады кебек. Һәм ул ахырдан, Шаһинурны кулындагы чәчәк бәйләме белән бергә кочагына алып, залдагыларга карап елмайды:

– Рәхмәт үзегезгә! Каләмдәшегез Шаһинур Мостафинны бик яратасыз икән!..

Залда тагын алкышлар давылы уйнап алды...

Мондый хәлне безнең бераз элегрәк тә – 1998 елның 12 февралендә Татарстан язучыларының Г.Тукай исемендәге клубында Шаһинур дустыбызның 50 яшьлек юбилеен үткәргәндә күргәнебез бар иде...

Сәламәт акыллы, сәламәт тәнле, сәламәт эшләр башкарган һәм кешеләргә һәрвакыт рәхимле, бәрәкәтле вә сәламле булган инсан бит ул Шаһинур. Аурупалылар: «Бәхетнең яртысы – гаилә, калганы – эш, дәрәҗә, байлык»,– диләр. Гаилә дигәненә кагылып үтсәк, уңды ул гаиләсеннән. Уңарга нигезе дә бар: аның Дамирәсе Чистай районыннан, данлыклы Гаяз Исхакыйны һәм башка күренекле шәхесләрне биргән Яуширмә авылыннан!

Татарстан башкаласының Идел буе районындагы төзек-матур йортларның берсендә – имән урманы кырыенда – үзләренә бирелгән өч бүлмәле фатирда сөекле хәләл җефете, улы-килене, кызы-кияве һәм оныклары белән гөрләшеп-чөкердәшеп, аларны аңлап вә санлап яши Шаһинур. Шулай яшәү үзе зур бәхет түгелмени?! Аларның киң күңелле гаиләсеннән, кунакчыл фатирыннан кешеләр өзелгәне юк. Җөмһүриятебезнең төрле районнарыннан, чит төбәкләрдән дә киңәш-ярдәм

сорап еш килэлэр бирегэ. Шаһинур исэ, йокы-ялын да онытып, аларга һэрчак булышырга, язмышларын җиңелэйтергэ омтыла...

Язу-иҗат эшлэре белэн ул күбрэк төнлэ шөгыльлэнэ. Өйдэгелэрнең һэммэсе татлы йокыга талгач. Төнге сэгать 11 дэн иртэнге сэгать 3 кэ кадэр эзтабар эдип утырган бүлмэ тэрэзэсендэ ут яна. Хэтер утыннан кабынган Иҗат уты!..

Язмышыннан һич кенэ дэ зарланмый Шаһинур дустым. «Бары тик саулыктан-сэламэтлектэн, тигезлектэн вэ иминлектэн, эзлэнү вэ иҗат дэртеннэн генэ аермасын Ходай!» – ди ул...

* * *

...Әйткэнемчэ, бүген – Хэтер һэм Кайгы көне. Бүлмэм түрендэге радиоалгычтан моңлы көй агыла. Уйландыра. Әйе, кешелэрдэге иң бөек инстинкт – яшэү телэге. Һэркем үзенең алда бер үлэсен белэ, эмма ул шул соңгы ноктаны ничек тэ булса арткарак этэрэ, ерак көннэргэ калдыра. Икенчелэбрэк эйтсэк, һэр адэм затының, җан иясенең мөмкин кадэр... мөмкин кадэр... мөмкин кадэр озаграк яшисе килэ!.. Аның монысы да яшэү телэгенең бер чагылышы...

Эмма... Сугыш сугыш инде ул! Берни белэн дэ хисаплашып тормый ул орыш, кан-яшь коеш...

Әйе...

Үлгэч кайтулар юк...

Үлгэч, кеше, хэтерсезлек баткаклыгына суырылып, акрын гына онытылу томаннары астында кала бара...

Юк, хэтер, мэңгелек шэм булып, балаларга, алардан – оныкларга, э алардан ерак оныкларга яктырып барсын иде. Бигрэк тэ иле, халкы, туган җире өчен зур эш майтарган инсаннар турындагы хэтер...

Хэтер дигэннэн... Хэтер сагында һаман да сизгер тора Шаһинур дустым. Эзлэнүлэре эзсез калмый аның. 2000 елда Бөек Җиңүнең 55 еллыгы уңаеннан Татарстан китап нэшриятында татар һэм рус теллэрендэ дөнья күргэн «Батырлар Китабы» – «Книга Героев»-ның баш консультанты, кереш сүз авторы һэм мөхэррире дэ булды Ш.Мостафин.

Хэзер «Батырлар Китабы»ның икенче томын эзерлэү белэн мэшгуль эзтабар-эдип. Әлеге томда сугышчан Дан орденнарының тулы (һэр өч дэрэҗэсенэ дэ лаек булган) кавалерлары турында – татар һэм рус теллэрендэ – архивлардан эзлэп алынган төгэл мэгълүматлар бирелэчэк, фоторэсемнэре урнаштырылачак...

Ш.Мостафин «Хэтер Китабы» редакциясе белэн дэ эшлеклетыгыз элемтэдэ тора, моңарчы билгесез булган каһарманнарны бар-

лауда үзеннән лаеклы өлеш кертә. Бер үк вакытта Казан каласындагы патриот-шагыйрь Муса Җәлил музей-фатиры хезмәткәрләре белән «Кызыл ромашка» клубын да оештырып җибәреп, «Идел-Урал» легионы сугышчыларына, җәлилчеләргә, макизарларга кагылышлы кызыклы очрашулар да үткәрә...

Шаһинурның фидакарь хезмәтенә лаеклы бәя биреп, матбугатта күпсанлы язмалар басылып чыкты. Аның үзендә сакланган хатлар да бихисап. Менә шуларның берсе (аны рейхстагка Җиңү Байрагын элүче каһарман милләттәшебез Гази Заһитов турында дөньяга иң беренче булып өн-хәбәр салган һәм үзе дә чын хакыйкать байракчысы булып саналган күренекле эзтабар әдибебез – Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, батырларны барлау өлкәсендә «Гран-при» иясе Шамил ага Рәкыйпов язган):

*«Хөрмәтле каләмдәшем Шаһинур!*

*Адәми затның исеме җисеменә муафыйк була. Менә Синең дә исемең – Шаһи=Нур. Ягъни Нурлар Шаһы!..*

*...Кукмарадагы беренче очрашуыбызга 30 елдан артык гомер узган. Шуннан бирле Син безнең барлык сөйләшүебезгә тугры калдың: халкыбыз каһарманнарының Бөек Ватан сугышындагы баһадирлыгын хәтерләребезгә беркетү буенча изге гамәлне уңышлы дәвам итәсең. Шундый уңган шәкертемнең остазы булуым белән чиксез горурланам мин!..*

*Сиңа ихластан «Кызлар-йолдызлар» исемле яңа китабымны бүләк итәм. Тарихыбызда 23 Герое булган бердәнбер полк – хатын-кызлардан гына торган очучылар полкы турындагы китап ул!*

*Егетләребез дә бик батыр. Әнә тигезсез дауда очкычы яна башлагач, тирән сазлыкка чумып, дистәләрчә еллар билгесезлектә яткан Фәрдетдин Сәхәбетдиновның гайрәт-кыюлыгын алты дистә елдан соң, якты йолдыздай итеп, күккә күтәрдең. Афәрин, Шаһи=Нур!.. Илдәкөндә батырлар данына игътибар кими төшүгә – безнең тиешле җавап бу!..*

*Үтә тырышлыгың, миңа бүләк итеп биргән бәян-повестең өчен олуг рәхмәт Сиңа – күңелләрне күтәрдең!..*

*7 декабрь, 2002 ел».*

Мөхтәрәм Шамил аганың шушы хатын укыганнан соң, уйланып алдым: «Шаһинур» дигән исем үзе дә, салават күперендәге җиде төстәй, бер-берсен кабатламый торган җиде хәрефтән тора икән бит! Ә җиде төснең җыелмасы, Шаһинур «Сигез бизәкле Сөлге» дигән кыйссасында хаклы язганча, ак төс, ягъни яктылык – нур хасил итә!

Әйе, исеме җисеменә бик тә туры килгән Шаһинурның: Хәтер сагында торучы яктылык – нур ул! Шуңа күрә ошбу китабына да эзтабар әдип, тирәнтен уйланып, «Хәтер яктысы» дигән бик тә мәгънәле, матур исем кушкан...

Үзенең 55 яшьлек юбилеен (ике «5»лелек эшчәнлеген!) билгеләп үткән елда – 2003 сәнәдә – чордашыбыз Шаһинур Мостафинга тантаналы шартларда мәртәбәле «Бәллүр каләм» тапшырылды. Батырларны, билгесез каһарманнарны эзләү-барлау өлкәсендәге күпьеллык намуслы фидакарь хезмәте әнә шулай югары бәяләнде аның.

*...Көрәшмәсәң дә Син яу кырларында,*
*Колагыңда – гел сугышлар шавы...*
*Ил өчен газиз җаннарын биргән*
*Батыр нәселдән яралган җаның! –*

дип язды аның турында якташы, шагыйрь Сәяф Шәйхи үзенең «Еллар кайтавазы» дигән китабында (Казан, «Матбугат йорты» нәшрияты, 2003 ел, 110 бит).

Ак вә Хак сүзләр!

Әйе, билгесезлек томаннарын тарату, караңгылыкны яктырту өчен безгә, Шаһинур Мостафин кебек, тирә-юньгә нур сибүче, көчле рухлы, тынгысыз шәхесләр бик тә кирәк! Бигрәк тә хәзерге кебек катлаулы, зилзиләле-давыллы, болгавыр заманда...

*РАФАЭЛЬ СИБАТ,*
*язучы, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты.*
*Киров өлкәсе, Нократ Аланы районы, Түбән Шөн авылы.*
*22 июнь, 2003*



# ЭЧТӘЛЕК

Батырларны барлар чак!.. (*Кереш сүз урынына*) . . . . . . . . . . . . . . . 3
Ядрәләрне эреткән йөрәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Сигез бизәкле Сөлге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
«Яшисе килә!» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Кайтавазлы балкыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Җәлилче-макизар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Яңа гасырга очыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Маресьевчылар арабызда яши... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Бер оя бөркетләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Буш нигезләр ни сөйли?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Без җиңәргә килдек бу Җиргә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Хәтер сакчылары яхут тарихи мизгелләрне мәңгеләштерүчеләр . . . . . . 160
Үзе дә – каһарманнар токымыннан!.. *(Рафаэль Сибат язмасы)* . . . . . . 175

Китапта авторның шәхси архивында сакланган һәм *Камил Арифуллов*, *Альберт Биктимеров*, *Рафаэль Гайзетдинов*, *Гомәр Мөбәрәкшин*, *Альянс Сабиров*, *Мидхәт Шакирҗанов*, *Әсрар Шакирҗанов* төшергән фотосурәтләр, *Эрот Зарипов*, *Равил Нигъмәтуллин* эшләгән рәсемнәр файдаланылды. Ш.Мостафинның туграсын *Нәҗип Нәккаш* иҗат итте.




Документально-публицистическое издание

*Шагинур Мустафин*
*(Мустафин Шагинур Сапиевич)*

СВЕТ ПАМЯТИ

(н а  т а т а р с к о м  я з ы к е)

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 21.05.2004. Форматы $84\times108^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 10,08+ф.0,21+вкл. 2,52.
Шартлы буяу-оттиск 13,86. Нәшер-хисап табагы 10,73+фор.0,36+вкл.2,55.
Тиражы 5000 экз. Заказ Э—350.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.